КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни ЖӨМГА

№ 7
1 сентябрь
1995 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

БҮГЕНГЕ САНДА:

2 *Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ.* Белемле кешенең җәмгыятькә кирәксезлеге авыллардан югары уку йортларына килүне кискен киметте.

6 *Рафаэль НАСЫЙБУЛЛИН.* Татар киносы әлегә дөньяга күзе ачыла башлаган сабый баланы хәтерләтә.

8 *Ренат ЕНИКЕЕВ.* Соңгы вакытта татар сәхнәсе зәвыксыз, милли йөзе булмаган җырлар белән тулды.

10 *Рудольф НУРИЕВ.* Безнең татар тамырындагы кан тизрәк агадыр сыман, һәрдаим кайнап чыгарга әзердер сыман тоела.

12 *Ил САТТАР.* Үзебезнең милли фикерләү культурасын көннән-көн югалта барабыз, ярым урысча уйлый, ярым урысча сөйләшә башладык без.

16 *Зәйтүнә ЗӘЙНУЛЛИНА.* Табигать, халык тарихы, туган тел кебек үк, безнең исемнәребез дә яклауга мохтаҗ.

Тел ачылыр — яңа көн тугач,
Тел ачылыр — җанга моң тулгач...

بسم الله الرحمن الرحيم

РЕСПУБЛИКА КӨНЕ УҢАЕННАН

Президент М.ШӘЙМИЕВНЕҢ Татарстан халкын котлавы

Кадерле ватандашлар! Кадерле дуслар!

30 августта без Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итүнең 5 еллыгын билгеләп үтәбез. Тарих өчен бу мизгел генә, ә безнең өчен соңгы биш ел бик мөһим сәяси вакыйгаларга бай вакыт булды.

Суверенитет безгә нәрсә бирде соң? Иң элек — сәяси тотрыклылык, милләтара һәм гражданнар арасында татулык бирде. Кайберәүләргә суверенитет республикада конфликтларга, Русиянең таркалуына, Татарстанның башка регионнардан аерылуына, читләшүенә китерер кебек тоелды. Элеккеге Советлар Союзы җимерелү нәтиҗәсендә туган дәүләтләрнең кайберләре нәкъ шундый язмышка дучар булсалар да, шөкер, без андый хәлләрдән котыла алдык. Безнең тотрыклылыкның сәбәбе Декларациябез нигезенә салынган принципларның цивилизацияле булуында. Суверенитетны без барлык Татарстан халкы исеменнән игълан иттек, ике дәүләт теле булдырдык һәм күп милләтле халкыбызның тигез хокуклылыкка бердәм омтылышына ирештек.

Суверенитет турында Декларация республикада иҗтимагый тормышны демократияләштерүнең, дәүләт институтларын ныгытуның нигезен тәшкил итте. Соңгы биш елда халкыбызның узаңы үсте, икътисади, социаль һәм мәдәни үсеш юлларын мөстәкыйль сайлауга омтылышы ныгыды. Татарстанның үзенә хас булган сәяси йөзе барлыкка килде, халкыбызда Ватанны сөю, республикабыз белән горурлану хисләре туды, һәм ул хисләр көннән-көн ныгый бара.

Бу елларда без иҗтимагый тормышның иң четерекле мәсьәләләрен дә хокукый юл белән хәл итеп булганлыгын үз тәҗрибәбездә исбатладык. Дәүләт суверенитеты турында Декларация республика Конституциясен кабул итүгә, Русия Федерациясе белән ике яклы Шартнамә төзүгә дә төп нигез булды. Кайбер кешеләр Шартнамә төзелгәч, республиканың суверенитеты юкка чыкты, дип расларга маташтылар. Русиянең үзендә дә аның әһәмиятен киметергә, Шартнамәдән баш тартырга чакырган, Русия Федерациясен губерналарга бүләргә өндәгән тавышлар шактый күп яңгырый. Без бүген ышанычлы төстә: нәкъ менә суверенитет безне сөйләшүләр аша федерация һәм республика дәүләт органнарының үзара вәкаләтләр алмашуына китерде, Шартнамәгә, дәүләтара килешүләр пакетына кул куярга мөмкинлек бирде, дип әйтә алабыз. Ә Шартнамә һәм килешүләр үз чиратында Татарстанның Русия Федерациясе белән мөнәсәбәтләренең ныклы юридик нигезенә әверелде. Алай гына да түгел, Шартнамә Русиянең үзе өчен дә чын демократик федерация юлыннан баруына гарантия булып хезмәт итә.

Бүген Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләрендә һәм башка чит илләрдә дә «Татарстан моделе» турында күп сөйлиләр. Узган биш елны, конфликтлы хәлләрдән чыгу юлларын күз алдыннан кичергәндә, без ул модельнең авырлык белән туганын танырга тиешбез. СССР таркалганнан соң, бигрәк тә яңа туган бәйсез дәүләтләрдә үзара мөнәсәбәтләр шактый катлаулы һәм низаглы булды. Абхазиядә, Днестр буенда, Карабахта, Таҗикстанда, Кырымда киеренкелек әлегә тикле кимеми. Ичкериядә кораллы бәрелешне җайга салу зур читенлек белән бара. Мондый шартларда без үзебезнең тотрыклылыкны кайгырту белән беррәттән, дөньядагы низагларны киметү юнәлешендә үз тәҗрибәбезне башкалар белән уртаклашырга тиешбез.

Суверенитетка таянып, без икътисади реформалар уздыруда үз юлыбызны сайладык. Татарстан хөкүмәтене
базарга «йомшак юл белән керү» сәясе
тен тәнкыйтьләүчеләр шактый табыл
ды. Ләкин еллар узган саен безнең юл
ның дөреслеген тормыш үзе раслый
Гомуми җимереклек хөкем сөргәндә д
без авыл хуҗалыгы тармагын ныгыт
алдык, ә бу исә халыкны иң мөһи
азык-төлек продуктлары белән тотрык
лы тәэмин итүгә мөмкинлек тудыра
Промышленность продукциясе җитеш
терүнең кимүе бездә тулаем Русия бе
лән чагыштырганда азрак темп беле
барды, ә бу елның икенче яртысынна
бездә җитештерү акрынла
арта башлады. Социаль як
лау программасын гамәлг
кертү нәтиҗәсендә халык к
чеш чоры авырлыгын чагыш
тырмача җиңелрәк кичер
Ләкин без башкарыла торга
эшләребезгә куанып, кул ку
шырып утырмыйбыз. Респуб
лика алдында конверсия, эш
сезлек, торак төзелеше, хез
мәт хакын вакытында түлә
һәм башка проблемалар шак
тый кискен тора. Безгә рес
публиканың икътисади һә
социаль үсеш программасы
эшләп бетереп, кабул итәс
бар. Ул Татарстанда эшлән
гән товарларның конкуренци
ягә сәләтен күтәрү, аларны
эчке һәм тышкы базарга күб
рәк чыгару стратегиясен д
активлаштырачак.

Суверенитет безгә доньяга
чыгарга, бөтенкешелек циви
лизациясе белән турыдан-ту
ры аралашырга мөмкинле
бирде. Үз чиратында башк
илләр дә Татарстанны, аны
сәясәтен, икътисадын, мәдә
ниятен таный башладылар
Болар безгә яңа технология
ләр, потенциаль инвесторлар
ышанычлы хезмәттәшләр табарга һә
акрынлап чит ил базарларына үтеп ке
рергә юллар ача.

Иң читен сәяси хәлләрдә дә Татар
стан Республикасының дәүләт сувере
нитеты турында Декларациясе ышаны
члы юл күрсәткече булды һәм шула
булып кала да. Аның потенциалы чик
тән тыш зур. Еллар узар, һәм без киле
чәктә дә тормышның иң мөһим мәсьә
ләләрен хәл иткәндә үзебезнең сәясәт
не шушы тарихи документка таяны
алып барачакбыз!

Хөрмәтле ватандашлар! Кадерле дус
лар!

Бу тарихи, истәлекле көндә — Рес
публикабыз көнендә — мин сезне Тата
рстан дәүләт суверенитеты игълан итү
нең биш еллыгы белән котлыйм! Сезг
яңадан-яңа уңышлар, нык сәламәтле
һәм тормышыгызда иминлек телим!

МИН ӘЙТТЕМ

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ,
журналист

«Белемлелеккә — даң» димәсләрме?

Мәдәни үзәгебез Казан һәм аның урамнарында хаталы татарча язулар турында матбугаттан укыган саен, мин бер-ике вакыйганы искә төшерәм. Бер елны башкаладагы Сабан туйларының берсен, төсле сурәт белән, «Турист» журналының тышлыгына чыгарганнар иде. Татарча түбәтәйле, ак яулыклы халык, бәйрәмчә көләч йөзләр алдында бик эре хәрефләр белән язылган шигарь балкый: «Коммунизм төзүче совет халкына...»

Язуның дәвамы журнал тышына сыймаган. Ә коммунизмны тезеп-тезеп кенә алдыбызга китерәсе иде дә, барып чыкмады, аны төзергә дә кирәк булды. Тик без бу хакта дөрес итеп язарга да өйрәнә алмадык, марксизм-ленинизмны һәм «КПССның данлы юлы»н өйрәтүгә корылган мәктәпләр безгә хаталы шигарь язарлык кына белем бирде. Ә томана килеш теләсә нинди исемдә яхшы җәмгыять төзеп булмый.

Бүтән бер елны Казанның «Каенлык»тагы Сабан туенда «КПССка — даң!» дип язылган галәмәт зур һава шарының бәйге өстендә эленеп торуын үзем күргән идем. Бик «укымышлы» түрәләребезнең татарча барыбер аңламаячакларына исәп тотып, юри шулай язганнармы аны, әллә «н»га «койрык» куйсаң гына татарча була дип уйлаганнармы — белмәссең. Бәлки шулай күрәзәлекләрен күрсәтүләре булгандыр, чөнки КПССыбызны тора-бара барыбер «даңгылдаттылар». Тик менә сүзләрне сәер итеп «татарчалаштыру» гадәте һаман яши. Быел, Җиңүнең 50
еллыгына багышлап, Бал...
уртасында бик кыйммәтле м...
мориал эшләнде, Советл...
Союзы Геройларының бюс...
лары куелды. Әмма бер я...
таш Геройның фамилиясе...
көмеш сыман хәрефләр белә...
«Рәһимов» дип язып куйл...
лар. Монда тагын Советл...
Союзы Герое «Гильметдин...
Гәйфетдин Гильметдин улы...
бар. Үз исем-фамилияләрен...
бу кадәр мәсхәрәләнеп, рәс...
урыннарга, хәтта укучы бал...
ның дәфтәр тышларына бөт...
нләй чит, әллә нинди корам...
телдә язылуына тагын кайс...
халык түзеп тора икән?

— Шушы хәлне газит...
язгыз әле, — дип, аптыр...
улы тәкъдим әйтте район х...
кимияте башлыгы урынбас...
ры, шагыйрь Гарифҗан М...
хәммәтшин. — Күптән түг...
Смәел урта мәктәбендә б...
лып кайттым. Анда мәкт...
коридорындагы язуларны к...
рсәң... Бездә исем-фамилиял...
рне ничек кенә язып бетерм...
ләр инде.

(Ахыры 5 нче биттә).

Җидегән

вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

5 6 7 1 2 3 4

Бәйрәмнәрнең беренче тантанасы

29 августта М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында Татарстан Дәүләт Советы һәм Министрлар Кабинетының дәүләт мөстәкыйльлегебез турындагы Декларация кабул ителүгә 5 ел тулуга багышланган берләштерелгән тантаналы утырышы булды. Анда ТР халык депутатлары, РФ Федераль җыелышы депутатлары, министрлык һәм ведомство җитәкчеләре, район һәм берләшкән совет рәисләре, район һәм шәһәр хакимияте башлыклары, әдәбият һәм сәнгать әһелләре, матбугат, җәмәгать оешмалары вәкилләре, хезмәт алдынгылары, ветераннар, җөмһүриятебез кунаклары катнашты.

Тантаналы җыелышны кереш сүз белән Татарстан Президенты М.Шәймиев ачты. Доклад белән республика Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачев чыкты.

Тәбрикләү өчен сүз Русия Федерациясе Премьер-министры В.Черномырдинга бирелде. Әүвәл ул мөстәкыйльлек юлыннан баручы Татарстан халкына РФ Президенты Б.Ельцинның котлавын ирештерде.

Бәйрәм тантанасында шулай ук Азнакай берләштерелгән Советы рәисе, шәһәр һәм район хакимияте башлыгы Ә.Исхаков, Башкортстан Президенты М.Рәхимов, Татарстанның халык язучысы Г.Ахунов, Чувашстан вице-президенты Ә.Әбләкимов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, академик И.Таһиров, Марий Эл Республикасының Дәүләт секретаре Н.Рыбаков, Чаллыдагы 36 нчы мәктәпнең урыс теле һәм әдәбияты укытучысы, чуваш җәмгыяте рәисе урынбасары Л.Михейкина, Удмуртия хөкүмәте рәисе урынбасары В.Гусев чыгыш ясады.

Берләштерелгән утырышта Декларациянең 5 еллыгы уңаеннан резолюция кабул ителде.

Утырышны Татарстан Премьер-министры Ф.Мөхәммәтшин алып барды.

Бәйрәм тантанасы Татарстан сәнгать осталарының зур концерты белән тәмамланды.

Икенче көнне Татарстан башкаласында, җөмһүриятебез шәһәрләре һәм районнарында бәйрәм тантаналары дәвам итте. Казан ипподромында ат чабышлары, баш театрыбыз каршындагы мәйданда гаилә бәйрәме, кичке дискобал, Кабан күлендә спорт ярышлары, Сул һәм Уң Болак урамнарында тантаналы тамаша, зур стадионда тантаналарның таҗы — мәдәни-спорт бәйрәме, базарларда ярминкәләр һ.б. чаралар үткәрелде. Ирек мәйданында милли хәрәкәт оешмаларының җыены булды. Анда Чаллы, Түбән Кама, Зеленодол һ.б. шәһәрләрдән килгән кунаклар катнашты, дистәгә якын милләт вәкиле, шулай ук җыр осталары чыгыш ясады.

Үткәннәр якынайта

Казанда рәсми визит белән Төркия дәүләт архивларының генераль директоры, профессор Исмәт Бинарк булды. Архив эшләрен башкару буенча ике дәүләт арасында хезмәттәшлек турында килешү төзелде.

Килешүгә Төркия дәүләт архивларының генераль директоры профессор Исмәт Бинарк һәм Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы архив идарәсе башлыгы, «Гасырлар авазы» журналының баш мөхәррире Дамир Шәрәфетдинов кул куйды. Кул куюда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, академик И.Таһиров һәм Татарстан тарихчы-архивчылар җәмгыяте рәисе Б.Солтанбеков катнашты.

Мондый килешүгә кул кую Төркия архивларында Татарстан халыклары тарихы буенча яңа документлар өйрәнергә һәм Татарстан Республикасы архив саклагычларындагы төрек тарихы буенча моңарчы мәгълүм булмаган документлар белән танышырга ярдәм итәр. Аларның күчермәләрен дә алырга мөмкин булыр.

Килешү буенча архив фондларын өйрәнү өчен белгечләр алмашу, берләштерелгән күргәзмәләр оештыру, архив эшен өйрәнү буенча әдәбият нәшер итү дә күздә тотыла.

Дәүләт архивларының генераль директоры Исмәт Бинарк — китап белеме һәм архив эшләре буенча дөнья күләмендә танылган белгеч, шушы мәсьәләләр буенча күп кенә китаплар һәм фәнни мәкаләләр авторы. Ул шулай ук Төркиянең элекке Советлар Союзындагы төрки республикалар белән мәдәни бәйләнешләр урнаштыруга да күп көч куйган кеше.

Хөрмәтле кунак Казан ханы Олуг Мөхәммәтнең 1421 елда төрек солтанына язган хатының төп нөсхәсен бүләк итеп алып килгән. Ул хат озын, зур кәгазьгә язылган, пөхтәләп матур тартмага салынган. Шуның өстенә ул XV—XIX гасырлардагы татар тарихына караган документларның күчермәләре, Идел-Урал буенда яшәгән башкорт, удмурт, чуваш, татар тарихына караган документлар, Госманлы дәүләте белән Казан ханлыгы арасындагы мөнәсәбәтләргә нисбәтле архив документлары, Төркиядән читтә яшәүче төркиләр турындагы документлар библиографиясенең күчермәләре тупланган төпләмә-томнар бүләк итте.

Котлыйлар, димәк, санлыйлар

Борис ЕЛЬЦИН: *«Татарстан халыклары мәдәниятенең югары дәрәҗәсе, иҗат коллективларының осталыгы шушы елның июнендә Мәскәүдә үткәрелгән Татарстан көннәре вакытында Русиянең бөтен халкында зур тәэсир калдырды».*

Виктор ЧЕРНОМЫРДИН: *«Без сезнең Декларация тирәсендә күпме кайнар бәхәсләр, ә кайчак ямьсез дискуссияләр булганлыгын яхшы хәтерлибез. Хәтта әлеге гамәлнең Русия Федерациясен таркату, Русиянең бөтенлеген юкка чыгару юлы икәнлеге турында пәйгамбәрлек кылулар да булды. Әмма мондый хәл килеп чыкмады».*

Владимир ШУМЕЙКО: *«... Татарстан бөек Русияне яңартуга үзеннән зур өлеш кертер дигән ышаныч белдерәм».*

Җомгадан — җомгага

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Президент М.Шәймиев Лениногорски шәһәренең 40 еллыгына һәм «Лениногорскнефть» НГДУсының 50 еллыгына багышланган бәйрәм тантанасында катнашты.

Татарстан Премьер-министры Фәрит Мөхәммәтшин рәислегендә җинаятьчелеккә һәм коррупциягә каршы көрәш комиссиясенең утырышы булды.

Татарстан Республикасы Премьер-министры Ф.Мөхәммәтшин Мәскәүдә Россия Федерациясе хөкүмәте Рәисе В.Черномырдин белән очрашты.

Лениногорски, Кайбыч, Зөй, Кама Тамагы, Биектау, Әлмәт, Тукай, Чирмешән, Мамадыш районы хезмәтчәннәре дәүләткә ашлык тапшыру заказын үтәделәр.

ТР Президентының Тышкы элемтәләр департаменты башлыгы Т.Акулов җитәкчелегендәге делегация Кандагар шәһәрендә «Талибан» шурасы әгъзалары белән очрашты.

Драматург Туфан Миңнуллинга 60 яшь тулу уңаеннан аның туган ягы Кама Тамагы районында тантаналы кичәләр, концертлар булып узды.

Казанда Казансу елгасы аша яңа төзелгән өченче күпердән машиналар йөри башлады.

Татарстан дәүләт мөстәкыйльлеге турындагы Декларация кабул ителүгә 5 ел тулу алдыннан РФ Президенты Б.Ельцин Мәскәү Кремлендә ТР Президенты М.Шәймиев белән очрашты.

РФ Премьер-министры В.Черномырдин, Казанга килгәч, Татарстан промышленностена кагылышлы мәсьәләләргә багышланган очрашу-киңәшмәдә катнашты.

БТИҮ рәис-координаторы М.Мөлеков, Җөмһүрият көнә уңаеннан үткәрелгән тантаналы җыелышта В.Черномырдин авызыннан «Русиянең бердәмлеге һәм бөтенлеге», «Татарстанның Русия Федерациясе субъекты» булуына ишарәләгән сүзләр ишеткәннән соң, протест белдерү рәвешендә тамаша залыннан чыгып китте.

Гәрәй РӘХИМ

Рәхмәт сүзе

РФ Хөкүмәте рәисе Казанда Җөмһүрият көне уңаеннан оештырылган тантаналарда катнашты.

Ул бит илнең чын хуҗасы,
Иңендә Рәсәй нужасы
(Бу киемнең юк тузасы!),
Сәяхәттә йөреп тора,
Йөзе гел телевизорда.
Вакланмый, эре кылана —
Карамый ул кырын да
Җыен шырдин-бырдинга...
... Рәхмәт Черномырдинга!

Үзен-үзе ватмый, сүтми,
Юкка-барга исе китми.
Колагын да ул селкетми —
Җыен шырдин-бырдинга —
Рәхмәт Черномырдинга!

Ельцинны да килештерә,
Думага да тибештерә —
Ваклашып тормый бер дә.
Җавапны бик оста бирә
Җыен шырдин-бырдинга —
Рәхмәт Черномырдинга!

Татарны да ят итмәде,
Кунактан хурлап китмәде.
Алтын таү бүләк итмәде,
Тик утыртып ук сүкмәде...
Инде шул дамы җитмәде
Бездәй шырдин-бырдинга?..
... Рәхмәт Черномырдинга!..

29 август, 1995 ел.

Котлыйбыз!

28 августта Кремльдә Премьер-министр Ф.Мөхәммәтшин күренекле балалар шагыйре, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, Х.К. Андерсен исемендәге Халыкара бүләк иясе Шәүкәт Галиевкә «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән билге һәм Мактау грамотасы тапшырды. «Мәдәни җомга» гәзите бу уңайдан өлкән шагыйребезгә нык сәламәтлек, бәхет һәм яңадан-яңа иҗади уңышлар теләп кала.

Борынгы акчалар күргәзмәсе

1 сентябрьдә Татарстан Дәүләт музее һәм «Инга-Арт» антиквар салоны хезмәткәрләре тырышлыгы белән борынгы акчалар күргәзмәсе ачыла.

Төрле чорлар һәм илләр тарихын чагылдырган акчалар берничә стендта урын алачак. Күргәзмәдә 30га якын илдә чыккан металл акчалар күрсәтелә. Биредә шулай ук нумизматика буенча китаплар да сатып алырга мөмкин.

Иң матур чәчәкле йорт кемнеке?

Чаллыда «Иң матур чәчәкле балкон» дигән конкурс үткәрелде. Анда 72 гаилә катнашты. Иң матур, иң гүзәл чәчәкле балкон Р.Яковлеваларныкы дип табылды.

Бу конкурс — шәһәр бәйрәме кысасында үткәрелгән чараларның берсе генә. Бу көннәрдә Чаллының балконнары гына түгел, урам, парклары да шау чәчәктә утыра.

Хуш киләсең, татар-мөселман календаре-96!

Аллага шөкер, татар-мөселман календаренең 1996 елгы басмасы да дөнья күрде. Ул — һәрбер мөэмин-мөселман өчен тугры юлдаш, якын киңәшче һәм ышанычлы дус. Ник дигәндә, бу календарьның барча сәхифәләре дә үзенә күрә бер хәзинә, зур энциклопедия. Әгәр сез шушы хәзинәгә ия булырга телисез икән, «Мәдәни җомга» гәзитенә түбәндәге номер белән шылтырата аласыз: 32-06-76. Фикер-тәкъдимнәре булган кешеләргә ошбу адрес буенча мәктүп язып җибәрү мөмкинлеге дә бар: 420107, Казан шәһәре, а/я 95.



Үз-үзеңне яклый алырга кирәк

Бүген журналистика иң куркыныч шогыльгә әйләнде. Еркен Серсембаевта күнегүләр ясаганда андагы журналистларның берсенең дә үз-үзен яклый алмаячагына мин аермачык инандым. Хәзергә генә. Чөнки каскадер, кул сугышы буенча инструктор, актер булган Еркен кулына барып эләккән иң йомшак, иң көчсез кеше дә спортчыга әйләнә. Казаннан Мәскәүгә ул хәрби сәнгать мәктәбе оештыру нияте белән килгән. Кул сугышына Еркен десант гаскәрләрендә чакта өйрәнгән, шунда ук «инструктор» исеме дә алган. Ирекле көрәш һәм бокс белән дә шөгыльләнгән.

Еркен үзенең мәктәбендә кешеләрне гадәттән тыш шартларда сакланырга өйрәтә. Әгәр шундый хәл килеп чыга икән, кеше тиешенчә каршылык күрсәтә алырга тиеш. Моның өчен каратэ мәктәбен тулысынча үтү дә мәҗбүри түгел. Мең төрле алымның берсен генә яхшылап өйрәнсәң дә була, дип саный Еркен.

Хәзер журналистларны һәм эшкуарларны күпләп атып үтерәләр. Монда да байтак нәрсә кешенең үзеннән тора, дип исәпли Еркен. Беркемнең дә тиз генә үләсе килми, шуңа күрә, дошманнан алдарак хәрәкәт итсәң, исән кала аласың...

Мәскәүгә Еркен күп серияле «Ермак» дигән фильмны төшергән җирдән килгән. Анда гаҗәп көчле актерлар — Ирина Алферова, Петр Вильяминовлар уйный. Еркен исә үзе фильмда Күчем хан һәм төрек морзасы булып катнаша. Өстәвенә, ул бөтен трюкларны, сугышларны да үзе куйган.

Кыскасы, барлык журналистларны Еркен мәктәбенә чакыра, ә анда топ ике нәрсә — зур теләк һәм ныклы тәртип сорала.

«Московская правда».

Ислам яшьләре лагере

Санкт-Петербургның урман-күлләргә бай «Смолячково» дигән бистәсендә август аенда ике атна дәвамында Ислам яшьләре лагере эшләде.

Быел бу лагерьны Согуд Гарәбстанының дин эшләре министрлыгы, Санкт-Петербургның һәм Ленинград өлкәсе мөселманнарының «Әл-Фатыйх» дини берләшмәсе оештырган иде.

Лагерьда Санкт-Петербургның «Әл-Фатыйх» мәдрәсәсе шәкертләре, «Ватан» татар җәмгыятенең якшәмбе Шәрык лицее һәм «Нур» татар җәмгыяте якшәмбе мәктәбе укучылары Ислам дине нигезләрен дә өйрәнделәр, ял да иттеләр.

Дәресләрне Согуд Гарәбстаныннан һәм Сүриядән килгән тәҗрибәле мөгаллимнәр алып барды. Укучылар Коръән, шәригать кануннарын үзләштерүдән тыш, гарәп теленнән дә гыйлемнәрен арттырдылар.

Биредә ял итүчеләр футбол, волейбол буенча спорт ярышлары да үткәрделәр. Билгеле инде, мөэмин-мөселман буларак, бер укучы да биш вакыт намазын калдырмады.

Укырга — Ливиягә

Татарстан яшьләренә Ливия университетында белем алу мөмкинлеге бар. Бу бәхеткә гарәп телендә яхшы укый-яза белгән алты кеше ирешәчәк. Конкурс Казандагы гарәп мәдәнияте үзәгендә үткәрелә.

Ырынбур — Мәккә «күпере»

Ырынбурда Согуд Гарәбстанының Мәккә шәһәрендә урнашкан Бөтендөнья Ислам Лигасы вәкилләре булып китте. Көньяк Русиядә яшәүче мөселманнарның тормышы белән танышу максаты белән килгән гарәп дин әһелләре Ырынбур, Орски, Яңа Троицки һәм Каргалы мәчетләрендә гыйбадәт кылып, аларга матди ярдәм күрсәттеләр.

Лиганың генераль директоры урынбасары Мөхәммәт Насыйр әл-Габуди әйтүенә караганда, киләчәктә Мәккә белән Ырынбур арасында үзара дуслык элемтәләре тагын да ныгыячак.

Биек тауга менү җиңелме?

Дөнья тәгәрмәче алга да, артка да әйләнә, ди. Әнә, Хатыйп Хәбибуллин да, белеме белән укытучы булса да, хәзер зур күмәк хуҗалыкның директорына әйләнде. «Биектау» күмәк хуҗалыгы бу көннәрдә урып-җыю белән мәшгуль. Яшь директорга ял-тынгылык юк. Иртәнге сәгать дүрттә Хатыйп инде аяк өстендә.

— Тегесе юк, бусы юк, дип, авызыңны күтәреп әйбер сорый торган заман түгел, — ди Хатыйп. — Бер яктан, рәхмәт, район хакимияте ярдәм итсә, икенче яктан, еш кына тәвәккәлләп юкны бар итәргә туры килә. Авыл хуҗалыгында эшләү катлаулы да, мәшәкатьле дә инде. Кемгә булса да эшләргә кирәк ич!

Бу хуҗалыкта быел арыш әйбәт уңыш бирде — гектарыннан 25 әр центнер алдылар.

— Шулай да, кыш җиңел булмаячак, — ди Хатыйп. — Әмма, Аллаһы боерса, бик тырышсак, сынатмабыз, дип уйлашабыз хуҗалыктагы белгечләр белән.

Амин, шулай булсын!

Әсрар ШАКИРҖАНОВ.

● Хуҗалык рәисе Хатыйп Хәбибуллин.

Игътибар: конкурс!

Чаллыяр киләчәккә карый

Чаллы шәһәр банкы, «Бизне
центр» кече предприятиес
«Астейс» Англия-Русия урт
предприятиесе, чикләнгән җава
лылыклы «Кече литражлы авт
мобильләр заводы» җәмгыя
һәм «Форт-Диалог» акционерл
җәмгыяте 1996 елның 1 августы
кадәр «Чаллыяр — киләчәккә к
раш» дигән иҗади бәйге игъл
итә. Анда Русия, республика, ш
һәр басмалары, радио һәм т
левидение, мәгълүмат агентлы
лары редакцияләре, журнали
лар, язучылар, аерым автор
катнаша ала. Бәйгедә аеруча а
тив катнашкан иҗатчыларга к
зыксындыру бүләкләре бирел
чәк. Язмалар матбугатта басыл
рга яисә теләсә кайсы массакүл
мәгълүмат чаралары тарафынн
эфирдан бирелергә мөмкин. Ко
курска 1995 елның 1 августынн
алып 1996 елның 1 августына
дәрге чорда дөнья күргән я
эфир аша яңгыраган язмалар г
на кабул ителә.

Иҗади бәйгедә катнашучыл
үз язмаларын, чыганакны күр
теп, гәзит һәм журнал битләре
нән кисеп алу, видео-аудио ма
риаллар рәвешендә тапшырал
Аларны «Чаллыяр — киләчә
караш» конкурсына» дип түбән
ге адрес белән җибәрергә кирәк

Татарстан Республикасы, Ча
лыяр шәһәре, Хәсән Туфан пр
спекты, 23 нче йорт, «Чаллы
— киләчәккә караш» иҗат кон
рсының оештыру комитетына.

Бәйгегә җибәрелгән язма
рецензияләнми һәм кире кайтар
лмый. Конкурска жюри һәм ое
тыру комитеты йомгак ясаяч
Конкурс йомгаклары редакц
ләр, журналистлар, язучылар,
дакцияләрнең авторлар коллек
влары, телевидение һәм радио
дакцияләре арасында аерым я
лачак.

Редакцияләр арасында бере
урынны алучыга «Ока» автомо
ле, икенче урынга — компьют
өченче урынга — видеомагни
фон бүләк ителә.

Журналистлар, язучылар, ре
кцияләрнең авторлар коллект
ларына да шул ук бүләкләр т
шырыла: беренче урынга — «О
автомобиле, икенче урынга —
мпьютер, өченче урынга — вид
магнитофон.

Җиңү яулаган телевидение һ
радио журналистларын да н
шундый ук бүләкләр көтә.

Оештыру комитеты тараф
нан биш кызыксындыру преми
билгеләнә.

Белешмәләр өчен телефон
53-81-39.

Моңнар кайта Бардага

Татарстанның атказанган
гать эшлеклесе, композитор
җырчы Мәсгут Имашевка 65 я
аның иҗат эшчәнлегенә 40 ел
ды. Шушы уңайдан аның ту
ягы Пермь өлкәсенең Барда
онында иҗат кичәләре булып
ды. Шундый ук кичәне Каза
уздыру да күздә тотыла. Ул
ноябрьдә М.Җәлил исемен
Татар дәүләт академия опера
балет театры бинасында була

*«Татар-Информ» мәгълүматла
башка чыганаклар һәм
автор хәбәрләре файдаланыл*

«Белемлелеккә — даң» димәсләрме?

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Һәй, Гарифҗан дус, дип әйтәсе килә миңа, онытгынмыни соң, инде мәрхүм булган партия райкомы секретаре безгә үз фамилиясен татарча язуны тыеп килде. «Беренче» шундый үрнәк күрсәткәч, мәктәпнең бер татар теле укытучысы гына ни эшли ала? Дөньябыз тәмам чуалып, җәмгыятебез таркалып барган бу исерек һәм җинаятьчел заманда без табып күрсәткән хәреф хаталары кемгә кирәк? Чапаевның наданлыгын Колчакның гыйлемлегеннән күпкә өстен куйган илдә яшибез ич. Нәкъ шул җирлектә «Укыган кеше — чукынган кеше» дигән мәкалебез дә туган. Бездә «интеллигент» — күптән инде сүгенү, мәсхәрәләү сүзе, аны дөнья күтә белмәгән булдыксызларга әйтәләр. «Укырга, укырга һәм укырга» дип васыять әйткән Ленин чыгышлары да интеллигентларны хурлау сүзләре белән тулып ята, ул да ил белән идарә итүне укымышлыларга, язучыларга янсә тел-әдәбият укытучыларына түгел, кухаркаларга тапшырырга хыяллана. Һәм байтакка тапшырдылар да. Тирә-ягыбызга күз салыйк әле:

Эш башында кемнәр хакимлек итә. Нигездә, мәктәпне «өч»легә тәмамлаучылар түгелме? Ә «өч»легә тарта алмаганнарның байтагы коммерция белән шөгыльләнеп байлык җыя. Әмма мондый хәлне большевиклар хакимлек иткән чорда гына башланды дип уйлау дөрес булмас. Рус илендә белемлелек һәм акыл элек-электән алай дәрәҗәле булмаган. Килмешәк патшаларга һәм аларның тар маңгайлы куштанна рына җирле халык укымышлысы нәрсәгә? Ломоносовның томана түрәләр камалышындагы тормышын күз алдына китерик. Пушкин, Лермонтовлар да титан талантлары белән ул җәмгыятькә ят булганнар. Әле дә шулай дәвам итә. Пушкин үз әсәрләрен киләчәктә «кыргый тунгус һәм дала улы калмык» та укыр дип юкка өметләнгән бугай, әлегә үз милләттәшләре дә аннан ераклаша гына баралар. Әдәбият тарихы «Җитлекмәгән егет» исемле атаклы комедия авторы Денис Фонвизин белән булган гадәти хәлне хәтерли. Язучының ел буе курортларда дәваланып чит илдән кайтып килеше икән. Көз башының бер төнендә Киевкә килеп төшәләр. Коеп яуган яңгыр астында күпме капканы шакысалар да, ганиләне җыбырга кертүче табылмый. Чөнки бирдә нинидер коляска авторын ишеткән кеше дә юк. Менә чираттагы ишекне кагалар. Ганиләне озата йөрүче малайның башына бу юлы бер акыл килә: Фонвизиннарны Потемкинның туганнары дип таныштыра. Менә шуннан соң капкалар бик тиз ачыла. «Россиягә кайтып җитүебезгә менә хәзер ышанырга да була», — ди Фонвизин. Белә бит: бу илдә акыллы язучыларга караганда түрәләрне, «сәер кенәз»ләрне (Потемкин хакында Пушкин сүзләре — Р.Ш.) өстен күрәләр һәм таныйлар.

Дөнья әдәбиятының гаҗәеп зур белгече, мәрхүм Хатип Госман, үз эшчәнлегенең соңгы елларында, иң сәләтле яшьләрнең әдәби иҗатка түгел, техник иҗатка, бүтән төрле белгечлеккә генә килүен борчылып сөйли, халык арасыннан яңа Такташлар чыкмавын шуннан күрә иде. Әдәбиятка һәм мәдәнияткә мөнәсәбәтебез гел шушылай дәвам итсә, халык аларга ихтыяҗ белдермәсә (районнардагы бердәнбер китап кибетләренең дә ябылуын бүтәнчә ничек аңларга?), киләчәктә яңа Такташлар, Илдар Юзеевлар дип әйтмим, халык арасыннан урта кул шагыйрь һәм әдипләр дә үсеп чыкмаска мөмкин. Менә шуннан соң рухи үсешебезне, татар теленең киләчәген күз алдына китереп карыйк без.

Хатип Госман фикеренә кабат кайтып, төптәнрәк уйлансак, шуны күрәбез: рухыбыз белән Такташлардан шул кадәр ераклаштык, аның шагыйрьлегенә тиң булырлык бөек иҗатны, зур талантны инженерларда, зоотехникларда да очратканыбыз юк һәм рухи-мәдәни ярлылану шартларында бу мөмкин дә түгел. Чөнки болар бер-берсенә нык бәйле. Болгар-татар халкы үз шәһәрләренә канализация корып, ихтыяҗына чуен коен, менә дигән күн, бизәнү әйберләре эшләп яшәгән чорларда гына дөньяга Кол Гали кебек бөек шәхесләрне бирә, «Идегәй» кебек мәшһүр дастаннарны тудыра алган. Ә безнең югары белем бирү системасы, кешене иҗатка өйрәтүдән бигрәк, сәяси трамплинга, җитәкче постка омтылу чарасына әйләнеп калды. Кайсы институт дипломы шуңа мөмкинлек бирә, шул бүтәннәрдән өстен санала. Ә менә югары белемле тел һәм әдәбият укытучыларын, гадәттә, күмәк хуҗалык рәисе дип әйтмим, кая ул, мәктәп директоры итеп куймыйлар. Андыйлар, әгәр үсәргә омтылсалар, алган дипломнарына өстәмә тестә, югары партия мәктәбенә генә булса да керергә тиеш булдылар һәм нәкъ шулай эшләделәр дә.

Тел белгечләренә һәркайда шушындый мөнәсәбәтне күрә торып, татар исем-фамилияләрен үз телендә хатасыз яза алмаучыларга һәм моны ялгыш дип, наданлык билгесе дип санамаучыларга ник гаҗәпләнәбез әле соң без? Соңгы вакытта татарча мәктәпләр, гимназияләр, балалар бакчалары, газит-журналлар арта дип тә үз-үзебезне артыграк юатабыз, аннан зур нәтиҗәләр чыгуын юкка көтәбез бугай әле. Менә «Мәдәни җомга» да «Татарстан хәбәрләре»нең мәете өстендә генә туды. Тукай «Туган тел»енең торгынлык дигән чорда җырланмый торган бер строфасын, Гаяз Исхакый ише бер-ике язучының югала язган берничә әсәрен халыкка кайтардык та, татар теле һәм әдәбиятының киләчәк язмышына киң юл ачтык, дип уйлаучылар да бардыр әле. Ә шушы ук чорда югалтуларыбыз азмы? 60-70 нче елларның балалары әлеге дә баягы шул Пушкинны һәм Лермонтовны, ике Толстойны, Шолоховны, Горькийны, Гогольны гына түгел, Шишков, Бубеннов, Фадеевларны, француз Гюгоны, инглиз Шекспирны, казах Ауэзовны, латыш Лацисны, кыргыз Айтматовны, бөтен дөнья әдәбиятының дистәләрчә авторларын үз телләрендә укып, бик күп кинофильмнарын татарчага тәрҗемә ителгәнен күреп үстеләр — ул чакта татар телен, мәгърифәтлелегебезне әнә шулар да саклашты. Тел байлыгы ягыннан Фатих Хөсниләргә тиң оста тәрҗемәчеләребез барлыкка килгән иде. Инде тәрҗемә әдәбиятның берсе дә юк һәм булыр дип өметләнү дә урынсыз. Бу исәптән, үз әдәбиятыбыз китаплары да элеккe кадәр чыкмаячак, мәдәниятебез дә һаман үз-үзен чикләүгә бара. Күптән түгел районыбызга Казандагы Калинин исемендәге мәдәният сараеның халык театры режиссеры Нурсөя Камалиева кайткан иде (ул татар хатын-кызларыннан югары белемле беренче профессиональ режиссер мәрхүмә Кәшифә Тумашева белән бер авылдан). Ишетсәң, исләрең китәр: иҗади бәйгеләрдә бүләкле урыннар алып килгән бу театр коллективы әлеге яңарыш елларында бер яңа спектакль чыгара алмаган. Сәбәбе — финанс кыенлыгы. Музыкантка, рәссамга түләргә, бүтән кирәк-ярагына акчалары юк. «Менә элек куйган «Ай булмаса, йолдыз бар»ны яңартып авылларга чыктык, шуның белән бераз акча эшли алсак, Нәбирә Гыйматдинованың бик әйбәт бер әсәрен сәхнәләштерергә хыялланабыз», — ди Нурсөя. Әмма җитәрлек акча җыя алырлар микән, спектакльләр, бик әйбәт уйналуга карамастан, ярымбуш мәдәният сарайларында үтә бит. Режиссер, аптырагач, колхоз рәисләре янына барып егыла, ә аларның үз хәлләре дә мөшкел. Җитмәсә, быел иген дә уңмады. Без әдәбиятка да, мәдәният һәм мәгърифәткә дә — бөтенесен бер чыганактан — рәсми хакимияттән генә көтәбез, ә аның көче, акчасы җитми һәм җитмәячәк. Теләге, омтылышы җитәрме — анысын әйтү кыенрак. Финанс эшендә белгеч булмаган кешеләр дә күреп торабыз — акча әйләнешенең бик зур өлеше эшмәкәрләр кулында. Әмма бу акчаның беразын халыкның аң-белемен, мәдәниятен үстерүгә, китап һәм журналлар чыгаруга тота торган Кашаповларыбыз бик аз әле. Мондый шартларда белемлелеккә таба барабызмы, әллә аннан кайтып килешебезме — әйтүе кыен. Соңгысы дөрес булмагае. Мәҗбүри урта белем гамәлдән чыккач, иркенлек тоюдан акылсыз файдаланып, унбер сыйныфны тәмамлаучыларыбыз да нык азаер. Мәктәп коллективлары үзләре дә ата-аналарны кат-кат җыеп, бер мәсьәлә хакында сүз кузгата башладылар: кызыгызны яисә улыгызны тугызынчы класстан соң да укытырга уйлыйсызмы? Нигәдер, «юк, укытып тормабыз», дигәнне ишетәселәре килә аларның. Тормышның тотрыксызлыгы, киләчәкнең билгесезлеге, белемле кешенең җәмгыятькә кирәксезлеге, җинаятьчелек һәм кыйммәтчелек авыллардан югары уку йортларына китүчеләрне хәзер үк кискен киметте һәм бу тагын кайчанга дәвам итәр?! Ә безнең артык урыслашкан шәһәрләргә чын татар зыялыларын, милли мәктәпләргә тел-әдәбият укытучыларын, язучы һәм шагыйрьләрне моңа кадәр нигездә авыллар биреп килде. Бу чыганак та саккач, милләт һәм миллилек ни хәлдә калыр?

Бервакыт «Останкино» телеканалыннан сөйләгәндә кемдер шундый чагыштыру китерде: Русиядә институт профессоры белән гади милиционерның хезмәт хакы бердәй икән. Ул айлардан соң аерма милиционер файдасына үзгәргәндер дә инде. Хәзер мәдәнияттән һәм мәгърифәттән кысылган акчаларны бүген булмаса иртәгә җинаятьчелек, рухи җимереклелек белән көрәшкә күбрәк итеп тотарга барыбер туры киләчәк.

Гражданнар сугышы чорының кайдандыр укылган «кызык» бер вакыйгасы күңелгә килә. Илдә ачлык, җинаять, чир — беркемдә дә китап, аң-белем кайгысы юк. Мәшһүр Сергей Есенин да үз шигырьләрен беркайда бастыра алмыйча бәргәләнә. Җитмәсә, гадәттәгечә, эш башында бөек шагыйрьнең талантсыз көндәшләре утыра. Шул чакта Ленин хөкүмәтенең хәрби эшләр башлыгы — мәгълүм Троцкий бу шигырьләрне үз комиссариаты типографиясендә бастыра. Нигә, нинди максат белән — бу яхшылыкның серен беркем белми. Бәлки, бу хәл сугышчан большевик Троцкийның шагыйрьгә: «Синең иҗат җимешләрең дә, җаның да минем уч төбемдә, теләсәм — ачам, теләсәм — йомам», дип әйтүе булгандыр. Инде татарның шагыйрьләре, зыялылары, милләткә аң-белем бирүчеләре кемнең уч төбендә? Ачарлармы, йомарлармы аны? Әллә милли дип урынлы да, урынсыз да мактала торган кайсыдыр бер Сабан туебыз өстенә купшы гына һава шары җибәребез дә, «Белемлелеккә — даң!» — дип язып куярбызмы?

Балтач.

Эрот ЗАРИПОВ рәсеме.

● **Бабай янында.**

ГАЗЕТА ҺӘМ УКУЧЫ

Бүрене бүреккә салмыйк, дип, үзебез бүрегә әйләникме?

Заһид Мәхмүдинең «Бүрене бүреккә салмагыз» дигән мәкаләсе миңа аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте. Ул үзенең язмасында ачыктан-ачык фәхешханәләр ачу кирәклеге турында яза. Имештер, аларны ачкан сурәттә берничә мәсьәлә хәл ителә. Имештер, хәзер тәннәрен сатып көн күрүче кызлар арта, алар арасында 13-14 яшьлекләр күбәя бара. СПИДны йоктырмау өчен дә тәтәйләр янына барырга кирәк икән. Гарипләр, ялгызлар, авырулар да шул фахишәләр белән күңел ачып, дөньяларын нурлый.

Безгә фәхешханәләр ачу турында уйланырга түгел, әхлагыбызны, гореф-гадәтләребезне, телебезне яңадан халыкка кайтару турында уйларга кирәк. Эчүчелек, бозыклык, азгынлык болай да күп, ә син шуларны законлаштырмакчы буласың. Оятсыз! Син бит юньле ата-ана баласыдыр, табигать кочагында үскәнсеңдер. Фахишәләр болай да күп, әле тагын фәхешханә ачтырып, иң беренче үзең шунда чапмакчы. Бу язмаңны укыгач, хатының, балаларың ни әйтте?!

Ә.ИБӘТУЛЛИНА,
70 яшь.
Казан шәһәре.

ДӨНЬЯ КИНОСЫНА — 100 ЕЛ

Рафаэль НАСЫЙБУЛЛИН,
Татарстан Республикасының дәүләт кинематография комитеты рәисе

Мөстәкыйльлек көзгесе

Татар киносы турында сүз чыкканда кайберәүләр, безнең үз кинобыз булганмыни, дип гаҗәпкә калалар. Әйе, татар киносы бар. Һәм ул бүгенге көндә үзенең 71 еллыгын билгеләп үтә. Ә тарихы аның шактый гыйбрәтле. 1924 елны без татар киносының туган көне дип саныйбыз. Аңа нигез салучыларның исемнәре яхшы мәгълүм. Алар — Каюм Поздняков, Әмир Фаикъ һәм Валерий Илюмжановлар. Кино сәнгатенә ихлас күңелдән бирелгән бу шәхесләр татар дөньясына гына түгел, элекке Советлар Союзы туфрагында яшәүче күпмилләтле тамашачылар мәхәббәтен яулап алырдай «Булат батыр», «Койрыклы йолдыз», «Чыңгызхан уллары», «Галим Һәйдәмәк» кебек беренче телсез фильмнар белән бергә шактый гына күләмдә документаль тасмалар да төшергәннәр. Гомумән, егерме дүртенче еллардан алып утызынчы еллар уртасына кадәр татар киносы гына түгел, ә бәлки, әдәбияты һәм театр сәнгате дә чәчәк аткан. Тик Сталинның кара милли сәясәте, бетмәс-төкәнмәс репрессияләр, милли белгечләрне күпләп үтертү татар мәдәниятен юкка чыгу куркыныч астында калдырды. Ә бит ул елларда кино сәнгате әһелләренең бер дигән ассоциациясе барлыкка килгән иде. Бу оешма өч ел эчендә искиткеч зур эшләр башкара алды. Әмма өстән килгән фәрман автоном җөмһүрияттәге кино сәнгатен сызып ташлаган, без озак еллар Русиянең, союздаш җөмһүриятләренең студияләре эшләп чыгарган фильмнарны карарга мәҗбүр булдык. Шул ук вакытта безнең язучыларыбыз берсеннән-берсе мавыктыргыч һәм кызыклы әсәрләр яза торды. Чөнки аларның күбесе безнең кайчан да булса милли бәйсезлек яулап алачагыбызга һәм дә милли киноны яңадан торгыза алуыбызга тамчы да шикләнмәде. Бүген Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Мәхмүт Галәү, Ибраһим Гази, Гомәр Бәширов, Нурихан Фәттах кебек олуг әдипләребезнең кайбер әсәрләре буенча бер дигән нәфис фильмнар төшерергә була бит. Хәзер безнең менә дигән киносценарийларыбыз да җитәрлек. Алар — шагыйрь Гәрәй Рәхим белән кинорежиссер Булат Мансуров иҗат иткән «Болгар дастаны», шагыйрь Рөстәм Мингалим белән драматург Ризван Хәмиднең «Идегәе», былтыр гына Мәскәүдә укып кайткан Хәмис Яһудинның «Оҗмах газабында үткән өч көн»е, Марат Садыйковның «Яшьлегемнең яшел канатлары» һәм башка әсәрләр.

Ләкин, дөресен әйтергә кирәк, егерменче елларда ук милли кино сәнгатебез булса да, без бу өлкәдә елләне алга китә алмадык. Уйлап карагыз әле, хәзергә кадәр Татарстанның «Татарфильм» студиясе дә юк бит. Документаль тасмалар һәм мультфильмнар төшерә торган студия дә матур хыял гына булып кала. Кыскасы, татар киносы зур сынаулар аша алга барырга мәҗбүр. Шуның белән бергә, безнең тәҗрибәле милли белгечләребез дә бик аз. Күбесе читтә яши һәм иҗат итә. Дөрес, алар милли рух, милли мәнфәгатьләр белән яшиләр. Ләкин аларны Татарстанга кайтару мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә. Һаман да шул фатир, акча мәсьәләсенә килеп төртеләсең. Шулай да без өч-дүрт ел эчендә дистәләгән документаль фильмнар иҗат итә алдык. Акрын-акрын гына булса да, үзебезнең кинодраматургларыбызны, кинорежиссерларыбызны әзерлибез. Берничә ел эчендә генә дә Татарстан Кинематография комитеты тарафыннан иллегә якын тасма төшерелде. Милләтебезнең данлыклы уллары сериясенә кергән «Моң», «Күңел җылысы», «Таулардай биек», «Күңел чишмәләре», «Җир үзе», Салих Сәйдәшев, Рөстәм Яхин турындагы фильмнар әнә шундыйлардан. Аларны әзерләүдә һәм төшерүдә язучылар Гариф Ахунов, Әхмәт Гадел, Нәбирә Гыйматдинова, режиссерлар Айбулат Абдуллин, Владимир Игнатюк, Наил Шәмсетдинов һәм башкалар тырышлык күрсәттеләр. Чоры бик болгавыр булса да, милли театрга, басмаларга багышланган тасмалар да иҗат ителә. Шушы елларда, мәсәлән, борынгы шәһәрләребез сериясеннән «Алабуга», «Болгар», «Биләр — көлдән күтәрелгән кала» дигән тасмалар дөнья күрде. Чаллыда шәһәр хакимияте башлыгы Р.Алтынбаев ярдәме белән «Ак бүре» студиясе ачтык. Бу остаханәдә төшерелгән «Иманга кайту» һәм «Аңга килү» дигән фильмнар Татарстанда гына түгел, чит илләрдә дә шактый зур бәя алды. Милли кинобыз республика тормышын мөмкин кадәр тулырак яктыртырга омтыла. «Татар конгрессы», «Татарстан: гасырлар һәм еллар», «ЮНЕСКО конференциясе», «Татар китабының 270 еллыгы», «Сүнмәс ут», «Хәтер» һәм башкалар моңа матур мисал булып тора. Шуның белән бергә, без ун минутлык «Ватан» киножурналын да чыгарып барабыз. Бүген исә беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев, күренекле композитор Фасил Әхмәт, Татарстанның халык язучысы Гомәр ага Бәширов һәм Татарстан дәүләт музее турында да документаль фильмнар табадан төшәргә тора.

Татарстан киносы үзенең тауарын шактый киң даирә сатып алучыларга тәкъдим итә. Без уңышлы тасмаларны видеокассеталарга күчереп барабыз. Дистәдән артык мультфильмны татар теленә тәрҗемә иттек. Бу эшкә танылган артистларыбыз бик теләп катнашты. Һәм аларның тырышлыгы белән мультфильмнар татарча сөйләшә башлады. Бу мультфильмнарны татар тамашачысы телеэкраннарда күп тапкырлар күрде инде. Сүз уңаеннан шуны әйтеп үтәсем килә, бу көннәрдә беренче татар мультфильмы — «Таңбатыр»ны да тамашачы хөкеменә чыгарачакбыз. Әлбәттә, бүгенге авыр шартларда Русиядә һәм БДБ илләрендә яшәүче бөтен татар гаиләләрен дә милли видеокассеталар белән тиз арада гына тәэмин итеп булмас. Алла боерса, без тора-бара татар тамашачысын дубляж белән генә түгел, үз мультфильмнарыбыз, үз нәфис фильмнарыбыз белән дә тәэмин итә алырбыз. Моның өчен вакыт һәм тырышлык кына кирәк. Киләчәктә татар кинематографлары халык авыз иҗатына, халык һөнәрләренә, милли бәйрәмнәргә, туй йолаларына, гореф-гадәтләргә багышланган тасмалар санын да ишәйтергә уйлый.

Безгә Русия Кинематография комитеты белән хезмәттәшлек итү турында шартнамә төзү белән генә чикләнеп калырга ярамый. БДБ илләре белән дә шундый шартнамә төзегән очракта, без милли кино сәнгатен шактый алга җибәрә алыр идек. Бу очракта безгә төрле төбәкләрдән заказлар да килеп торыр иде. Ап-ачык ки, әлеге дәүләткүләм мөһим эштә Татарстан кинематографлары гына түгел, аннан читтә яшәүче милләттәшләребез дә зур тырышлык куярга тиештер.

Үз кино сәнгате булган халык — зыялы халык ул. Мондый милләт һичбернинди тышкы басымга да бирешмәячәк. Кино күңелдәге иң тирән тойгыларны уята, хиснең иң тирән коеларына төшә ала. Кино — ул милләтпәрвәр кешеләр тәрбияләүдә сәнгатьнең иң мөһим бер төре булырга тиештер. Үз җиребездә мондый гаҗәеп көчле сәнгать төрен булдыра һәм үстерә алмаган тәкъдирдә җөмһүриятебез бик күпне югалтыр, дип уйлыйм.

Әйдәгез, аны үстерүдә, алга җибәрүдә тырышлык, иҗтиһат күрсәтик. Татар киносы әлегә дөньяга күзе ачыла башлаган сабый баланы хәтерләтә. Бу бала безгә бик тә кирәк. Чөнки милләтнең тамырлары тирән, мәдәни поездның вагоннары хәтсез күп, андагы иҗади йөкнең тоннажы да бихисап зур. Бу зур мирасны фәкать кино сәнгате генә күтәрә ала торгандыр.

Бүгенге көндә Татарстандагы кино сәнгатенең структурасы түбәндәгедән гыйбарәт: Кинематография комитеты, «Татарфильм» студиясе, Кинокомбинат, Кинохроника студиясе, «Татарвидео», Кино сәнгате йорты, кинотеатрлар, «Татаркинопрокат», киночелтәрләр, киносервис хәдимлеге, Дәүләт кино оркестры, ял базасы. Аларның күбесе әлегә оешу хәлендә генә дисәм, һич ялгыш булмас. Киләчәктә бу тармакларда зур эш майтарылыр әле дигән ышанычым бар. Шунысы сөенечле, җөмһүриятебез икътисади авырлыклар кичерсә дә, мөхтәрәм Президентыбыз һәм хөкүмәтебез милли кинематографларның эшчәнлеген күз уңында тотып, аларның һәр уңышы өчен куанып торалар. Мондый ихлас теләктәшлек безнең күңелләрдә җаваплылык хисен арттыра, өмет чаткысын кабызып җибәрә.

Татар киносы акрын-акрын гына тәрәккый итә. Инде менә «Гипрокино» белән килешү төзелде. «Татарфильм» студиясе проекты эшләнә. Санкт-Петербургның «Экран» берләшмәсе исә безгә киностудия һәм кинокомплекс проектын эшләп бирергә алынды. Киләчәктә чит илләрдә ясала торган тасмадан ким булмаган тасма ясау өчен «КазНИИтехфотопроект» белән килешү төзедек. Бу хыял тормышка ашса, без елына 10 миллион погон метр кино тасмасы үзләштерү мөмкинлегенә ирешәчәкбез. Киностудия павильоннары да бүгенге көн таләбенә генә түгел, киләчәк өчен дә яраштырылып эшләнергә тиеш.

Дөньяда япа-ялгыз яшәп булмаган кебек, һәр дәүләт, һәр оешма үз казанында гына кайнап тәрәккый итә алмый. Боларның барысын да истә тотып, без төрки илләр кинематографиясе дәүләт советын булдырдык. Монда Әзәрбәйҗан, Башкортстан, Казакъстан, Кыргызстан, Каракалпакстан, Төркмәнстан, Татарстан, Үзбәкстан һәм башка илләр катнаша.

Киләчәктә милли киноактерлар, кинорежиссерлар булдыру максатыннан чыгып, Казан дәүләт сәнгать һәм мәдәният академиясе белән уңышлы гына хезмәттәшлек итә башладык.

Кино сәнгатенә бүген базар мөнәсәбәтләре дә шактый тискәре йогынты ясый. Экраннарда чит илдә эшләнгән коммерция фильмнары — секс, фахишлек, көчләү, явызлык урын алды. Моңа каршы Татарстан кинематографиясе тәкъдиме белән коммерцияле видеотасмаларны һәм кинофильмнарны күрсәтүне тәртипкә салу буенча карар кабул ителде.

Без үзебезнең тар сукмактан киң юлга чыгачагыбызга һәм җиңәчәгебезгә нык ышанабыз. Чөнки татар халкында бүген дә Каюм Поздняков, Әмир Фаикъ кебек талантлы шәхесләребез бар. Халкыбызның иҗат чишмәләре саекмаган, ул — мәңгелек.

Рәдиф ГАТАШ



Робагыйлар дәфтәре

1.ӘЛЛӘ ДӨНЬЯДА БЕР ЯШӘП КИТКӘНМЕН?..

Әйтерләрме?..

Әйтерләрме: «Каһәрле шул елларда
Бар дөньясы гүя акыл җуйганда,
Денле итте безне бит шигырь-вәхи,
Чын аятьләр онытылып торганда!

Лутилар бар

Лут пәйгамбәр чорыннан - - гөнаһлары...
Ник күбәя шуларның тарафдары?
Фәрештәнә дә тиярләр... йә, раббем:
Шул гөнаһтан коткар без-татарларны?!

Яшерен, «гөнаһлы» сөюебез өчен тост

Әдәп-әхлак «ирке» канат җәйгәндә,
Ихлас җанны бик азлар санлаганда,
Безнең сөю - - пәйгамбәрлектер, Гаташ,
Табигый хис - - күлкәгә саналганда?!

Гөнаһым — үз башыма

Гаепле - - мин: гел аны хурлап тордым,
Барын яшереп синнән, югын арттырдым...
Көткәнгәме ирештем?.. Юк. Сиңа аны
Кызыклырак күрсәттем — яраттырдым!

Аерылгач бер уй

Юк кына бәхәстән безнең аерылу,
Кызулык беләй як-якка каерылу...
Шуны аңлап, яну - - минем язмыштыр,
Синең бәхетеңме — битараф Ай булу?!

Соклану

Җаның - - юктыр, йә ул — таштыр, билләһи!
Җаны бар күптән яратыр, билләһи:
Күккә ашкан «аһ»ыма исең китми,
Ну, дим, мишәрдә характер, билләһи!

Үземне юату

Тормыш - - кыйбат, назлар - - арзанайганда,
Сафлык тәмам онытылып баргында,
Гаташ җанын аңламавың гаҗәпме? —
Тынычландым, юрап дөнья яманга...

Үткәндәме... үтмәгәндәме?

Күрешүләр көтмәдем мин - - бәндә,
Күрештерден, Уфам, көтмәгәндә.
Үткәндәме булып кайттык? Әллә
Яңа юлга бактык - - үтмәгәнгә?!

Үз нәфсемә, башкага түгел

Рәхсәтсез-канатсыз сиңа очалмыйм!
Ичмасам тиргәнеп гамьнән бушаныйм.
Бу халәттә кемгә нәләт? Нәфсемә...
Бәладән башаяк! — башкадан үч алмыйм.

Өндә ни күрәчәкмен?

Төш күрәм: даным ирешкән һәр җиргә:
Сезнең атаклы авылга... Сембергә...
Хәтта син дә җырларыма баш идең! —
Тәгаен, бу — өнемдә сүгелергә...

Үз шигыреңне көтеп

Ә синдә күпме илһамдыр — яшьлектән,
Ул - - ачкычтыр сер-сихерле «ящик»тән.
Тиңсез шагыйрә бул! Ә мин — укучың
Булырмын, җир яңгыраткан — шатлыктан!

Ничәнче кат яшәү бу?

Әллә дөньяда бер яшәп киткәнмен?
Һәммәсен бер күргәндәй хис итәмен...
Хәтта сөю — таныш... Мең еллар элек
Синең өчен үлмәдемме, иркәм, мин?!

Тагын исердем...

Күңел яшьлегемдә барын кичердем,
Җиткәндер, дидем, картлыгы хисемнең, —
Башка китеп елмаюың шербәте,
Бал сүзеңнән, үсмердәй, ник исердем?

Җанның үз кайгысы

Тыпырчына тере җаным учыңда! —
Әллә кайларга очарга очына...
Ул: мең елдан җирен сагынып кайтса,
Очрата алмам сине, дип, борчыла.

Хиснең чишмә башын уйлап

Исемең онытканмын: Гөл йә Ал ханым...
Истә — синнән хистә сабак алганым.
Сөя белми, надан, дип бер кугач син,
Бу көнгәчә юк «аттестат» алганым!

«Мемуар» яза калсаң...

Күпме гыйшкымны фаш итте язганым,
Тәнкыйтькә дә азык бирә «азганым»...
«Яр» дигәннәр яклап бер сүз дәшмәдә, —
Соңгы өметем син: аклап яз, җаным!

Хәзер мин елыйм

Әй, еладың син бер... кем җырлаганда?
Борынгыларның моңын тыңлаганда.
... Яшьләреңнең тоям тозын иренемдә —
Син киткәч тә... шул мәлне уйлаганда.

Җыр да заманча

Байлыкка алмаштың шагыйрьне, димме?!
Әллә мактыйммы миллионер иреңне?
Куркам, бүген җыр да инде башкадыр:
Фәкыйрь хатының сөю дан китерерме?!

Үз-үземә аптырыйм

Гомер узган саен күрәм: начар мин!
Язгыгым белеп - - язмыштан качалмыйм.
Бер дивана гариб мин, һөнәр белмәс...
Кемнәргә гыйшкым ачмадым! — нахал мин...

Күпме сынарсың, дим...

Үтми ник сине сөюем газабы?
Бәлки, җиңеллек китерер азагы?
Тәңремдер — син! Ул да шулай бирә бит
Яраткан колына - - зуррак җәзаны...

Бәхетемнән аермагыз

Сукыр теләге ике күз... Ә мин - - шат,
Сукыр итсә дә илледә мәхәббәт - -
Тик җитәкләп йөртсен генә гөл ярым,
Шул бәхетемнән көнләмәгез, җәмәгать!

Шагыйрьләр язмышы

«Булмаганны сөйләп, җендәй, чүлләрдә
Яши», ди шагыйрь турында Коръән дә.
... Ә «булачак» юлында күпме шагыйрь
Башы китәр — әйтмәгән пәйгамбәр дә.

Йомгакмы, уймы...

Булдың, Гаташ, Хәйямнар бакчасында,
Робагыйлар яңгырашы җанында...
Әһле каләм ни әйтер, дип уйлау юк,
Яратмый яр, дисең, таш атса шунда?!

Бөекләрнең шигырь мәктәбендә рәдиф-шәкерт булгач

Горурлан: «фәннән чыкмады» башларың!
Авыр дип укуны ташлап качмадың! —
Идән юдың, бил бөктең хәлфәләргә:
Илледә үк - - «хәреф таный башлады»ң!

2. ҖЫЛЫ ЯЗДА ЯУГАН КАРЛАР

1995 тә язылган беренче юл

«Бисмилла!» дип, язып китик бу елны.
Былтыргыдай, шигырь итик бу елны.
Җир, Күк әле имин бугай... Без дә бит
Мәхәббәтнең шул ук - - күндәм бер колы!

Фатиха алдым

Язганың — ни, Каләм? Хис ташкан хатмы?
Күккә ашар моң - - ялкыннан хисапмы?
Колак салдым — йолдыздан алдым хәбәр:
— Безләр — разый... Башла яңа Китапны!

Без очрашкан көн

Бу очрашу — Галәмдә бер очракмы?
Күкләр кушканмы: ялгышмы йә хакмы?
Тетрәп сүнгәндә... гөлт итте рух-филтәм:
Күзләрең бит көлтә-көлтә ут атты!

Сөю юлында

Үз-үземне аңлар чик — ул югалды,
Юлны — җуйдым... Ярлар, таулар уалды.
Ташлап качты Түземлелек һәм Акыл,
Ә Хис, Өмет китмәде... Хыял — калды.

Нәфсе халәтен

Әй-йа, омтылышың! - - Күккә очарлык,
Җирнең бар яшь гөлен, җыеп, кочарлык.
.. Дәшми генә бер илле ел көтимме —
Миңа да бер наз мизгелең бушар, дип?

Нишли яңа көйләр синдә?

Төректәнме бу көй-мөнәҗәтләрең?
Гарәптәнме моңлы аять-мәкамең?
Хис манараңда имамнар гел яңа, —
Ә иманың үзгәрмәсме, әйт, җаным?!

Йолдыздан кем өне?

Күктән һаман аваз килер (шуннан бу!)
Яндырыр да суытыр бер (чыннан бу!).
Әкерен, салкын, үз кадрен белгән тавыш
Әйтер тагын: «Мин әле бу... Чулпан бу!»

Яңа гасырга үрелеп карау

Алда да гашыйк җаннарга серләр күп,
Ачылыр яңа суратләр — сүзләр күп.
Алай да... бу зәгыйфь «Чулпан сүрәсе»н
Күк сүзе итеп, анда кемдер сөйләр күк!

Мактавым бугай бу

Холкың-фигылеңә ни әйтим, гүзәл яр? —
Миннән гайре аңа кемнәр түзәр, яр?
... Шундый хисем: кыпып атарсың чәчәк,
Саклый алмам, куркам: читләр өзәр, яр!

Шагыйрь дусларыма

Мөдәррис, Зөлфәт, белмисез, хәлем сез:
Үзе матур, сүзе — суык, рәхимсез
Яшь кыз әсир итте... янам да язам.
Тагын нишли алам? Бәлки, әйтерсез?

Хафиз, Ронсарларны уйлап

Бөек гашыйкларның аңлый хисләрен,
Җан кардәшем итеп данлыйм үзләрен:
Шундый таныш миңа алар халәте! —
Башлыйлар — яттан тәмамлыйм сүзләрен!

Икебезнең сурәт

Икәү төшкән «мәшһүр» сурәт аша мин
Бар дөньяга бәян итәм — дошмәмен:
— Эшләпәле яшь бер туташ — син анда,
Һәм аузы ачык, гашыйк «карт эшләпә» - - мин...

Үлеп көнләшәм

Көнләшәм! Кичерсен ходам... үләм мин!
Хакым да юк бу «бәхет»кә, беләм мин...
Әйдә, дим, бер кычкырыйм, җан бушансын, —
Сизәм юкса: үз-үземне җиңәлмим!

— Ренат әфәнде, Сезнеңчә, композитор булуга нәрсә көчләрәк тәэсир итә: табигать кочагында туып үсүме, аралашкан кешеләрме, әллә инде берәр олы шәхесме?

— Музыкага һәм, гомумән, иҗатка һәвәслек, минем уйлавымча, нәселдән килә. Бу — галимнәр тарафыннан күптән исбат ителгән. Моны дәлилле торган бер мисал да китереп узыйк әле. Белгәнсебезчә, алманнар бик төгәл халык. Тарихи документлар да аларда бик яхшы саклангән. Алман галимнәре Бахлардан алып Шуманнар чорына кадәр яшәп иҗат иткән танылган композиторларының шәҗәрәләрен өйрәнгәннәр. Бу ике гасыр чамасы араны эченә ала. Шуңлыктан, аларны төрле вакытта төрле дәүләтнеке итеп йөрткәннәр: әйтик, Пруссия композиторы, Австрия, Германия яисә немец композиторы... Нәтиҗәдә шушы композиторлар арасында кардәшлек, туганлык җепләре булуы ачыкланган. Бездә инде мондый бәйләнешләрне тикшерү җиңел эш түгел. Шулай булса да, күп кенә зыялыларыбыз, олы затларыбызның нәсел җепләре бергә бәйләнгәнлеген без дә беләбез.

Мин үзем әни карынында чакта ук диярлек музыка тыңлап үскәнмен. Әни үзешчән театрда уйнаган, җырлаган. Әти дә гармунда, мандолинада уйнап, татар, башкорт җырларын бик матур итеп җырлаган. Әти ягыннан бабай үзе ясаган курайда сыздыра торган булган. Ул Башкортстанның Каргалы авылында гомер иткән. Беләсездер, атаклы язучыбыз Әмирхан ага Еники дә шул ук авылның Еникеевләр нәселеннән. Ә танылган скрипкачы, халыкара конкурслар лауреаты Зариус Шаһморзаева (кыз чагындагы фамилиясе — Еникеева) белән без өченче буын балалары. Әни ягыннан нәселебезнең очы исә Тукайлар шәҗәрәсенә барып тоташа.

Шушы нәсел-нәсәптәге музыкага һәвәслек миңа да күчкәндер инде. Малай чакта ук курайда көй чыгарып азаплана идем. Аннан гармунда уйнарга өйрәндем. Мәктәптә укыганда бер ансамбль кебек нәрсә оештырып, аның белән җитәкчелек тә иттем әле. Бераз соңлабрак булса да, унбер яшемдә музыка мәктәбенең фортепьяно классына укырга керү бәхетенә ирештем. Дүрт елда 7 сыйныфны тәмамладым. Аннан музыка училищесы, консерватория...

— **Олы композитор булу өчен нәселдән килгән һәвәслек өстенә музыканы ихластан ярату да кирәктер әле. Малай чакта күңелегездә композитор булу теләге бар идеме?**

— Әйткәнемчә, мәктәп елларында гармун буенча шактый гына осталыкка ирешкән малай идем мин. Хәтта республика күләмендә узган олимпиадада җиңеп, бөтенсоюз ярышына уздым. Әмма музыка мәктәбендә укый башлауга мин үземә әр-яңа дөнья ачтым. Академик музыка дөньясы иде бу. Миндә шул яшьтән ук композитор булу теләге уянды. Бүтән бернәрсә дә кирәкми иде миңа. Композитор булсам, алтын хәрефләр белән язылган берәр таныклык бирәләрдер, дип тә уйлый идем. Шулай булып чыкты да. Композиторлар берлегенә әгъза булып алынгач, шаккаттым. Таныклыкта алтын хәрефләр белән: «СССР Композиторлар берлеге әгъзасы», дип язылган иде.

— **Сез 50 нче елларда сәнгать дөньясына килеп, бүген инде милли музыкабызны баетып, бизәп торучы композиторларыбызның берсе. Ә бит сезнең буын аякка басканда мәйданда җиң сызганып татар музыкасының классиклары иҗат итәләр иде бит әле! Н.Җиһанов, М.Мозаффаров, З.Хәбибуллин, Җ.Фәйзи кебек олы затлар арасында ничек Сез үз тавышыгызны ишеттерә алдыгыз икән?**

— Чыннан да, безнең буын композиторларыбызның иҗатка килүе, бигрәк тә мөстәкыйль иҗат юлына чыгулары гади генә булмады. Ул вакытта инде профессиональ музыкабызда байтак эшләр башкарылган иде. Безгә исә шул олы традицияне дәвам итү бурычы йөкләнде. Яшь иҗатчыларга булган мөнәсәбәт тә бер төрле генә түгел иде. Шулай да без үзебезне бәхетле санарга тиештер. Ни өчен дигәндә, без укырга килгәндә консерватория формалашып җиткән, анда тирән белемле, олы хөрмәткә лаек остазлар эшли иде. Әйтик, А.Леман, Г.Литинский, Х.Терегулов, Н.Рецкер... Аннан соң, өлкән буын композиторлардан иҗатлары белән дә, кешелекләре ягыннан да безгә өлге булучылар бар иде. Алар арасыннан минем үземә Мансур абый Мозаффаров бик якын булды. Ул үзе дә минем белән ничектер дустанә мөгамәләдә иде. Безнең бит ул дәвердә опера, балет кебек күләмле әсәрләр язган композиторларыбызның барысы да мөстәкыйль эшләмәде. Бәлки, моңа аларның белемнәре дә җитеп бетмәгәндер. Аларга ярдәмләшүчеләр булды. М.Мозаффаров мөстәкыйль иҗатчы һәм чын профессионал иде. Мәскәү каласында да уза торган иҗат атналыклары, пленумнарда элекке СССРның классик композиторлары Мансур абый иҗатына бик югары бәя бирәләр иде. Күп нәрсәне мин аңардан өйрәндем һәм аның милли рух белән сугарылган иҗатына бүген дә сокланып яшим.

Хәтерем ялгышмаса, 60 нчы еллар уртасында яшь иҗатчыларның беренче пленумы уздырылды. Аның программасында Ф.Әхмәтов, М.Яруллин, Р.Билалов, И.Якупов һәм минем әсәрләр урын алды. Үзенә күрә бер зур имтихан булды ул безгә. Танылган музыка белгече Я.Гиршман пленумнан соң матбугатта чыккан язмасында безне «великолепная пятерка» дип атады. Үзенчәлекле буын булдык без. Хәер, ул табигый дә. Һәр буын үз мохитендә яши. Аларның иҗаты да шул дәвернең сулышына аваздаш була. Бездән соң сәнгатькә килгән буыннарның да бит үз карашлары, үз алымнары бар. Ләкин нигезебез генә уртак һәм милли булырга тиеш.

— **Татар теленең бүгенге хәле күпләрне борчый. Аны саклап калу, сафландыру, яшь буынга ана телен өйрәтү өчен күпмедер чаралар да күрелә. Ә менә халкыбызның музыкаль теле турында сөйләшүләр матбугат битләреннән уза алмый. Әллә инде монда борчылыр урын юкмы?**

— Сөйләм теле һәм музыкаль тел бер-берсеннән аерылгысыз. Әйтик, элгәрәк заманда, радио-телевидение булмаганда, кешенең теле дә, җыр-моңы да нигездә бозылмый саклангән. Балалар үз телендә, үз гореф-гадәтендә тәрбияләнгән. Үзенең саф халык музыкасы белән үскән, шуның белән тормыш юлын тәмамлаган. Ә безнең җәмгыятьтә исә милли тәрбия, шул исәптән милли музыкаль тәрбия бирү эше дә көннән-көн катлаулана гына бара. Бу бигрәк тә көнкүреш музыкасында ачык күренә. Соңгы вакытта татар сәхнәсенә зәвыксыз, милли йөзе булмаган җырлар менеп тулды. Тарихы булмаган көйгә татар тексты белән җырлар башкарыла. Кем нәрсә булдыра ала, кем каян нинди интонация ишетә, барысы да татарныкы дип тәкъдим ителә. Мәскәү радио-телевидениесе дә эфирны иң зәвыксыз, мәгънәсез музыка белән тутыра. Мондый музыканы кабул иткән кеше шуның белән бергә чит гореф-гадәтләрне, кыланышларны, кием-салымны да үз итә. Галимнәр әйтүенчә, чит-ят музыка кешенең җанын, күңелен генә түгел, хәтта милли нәсел җебен саклаучы геннарны да бозуга китерә. Кыскасы, халыкның музыкаль теле зәгыйфьләнүе миллилекне дә юкка чыгара.

— **Ул чагында ни сәбәпле бүгенге татар эстрадасы гына түгел, хәтта урыс һәм чит ил эстрадасы да күпләр тарафыннан уңай кабул ителә?**

— Беренчедән, сәбәп шул ук укыту-тәрбиядә. Әйтик, кемгә дә булса берәр әдәби әсәр, шигырь бирегез. Ул аның җөмләсен — җөмләгә, сүзен — сүзгә аерып бирә һәм әсәргә үзенең ачык мөнәсәбәтен дә белдерә ала. Чөнки ул беренче сыйныфтан ук тел-әдәбият укыган, өйрәнгән. Ә музыкаль әсәрнең төзелеше, үзенчәлеге күпләр өчен «кара урман». Чөнки халыкка музыкаль белем бирү мөмкинлеге бездә әле дә булса юк. Икенчедән, музыка теле күңелгә җиңелрәк, тизрәк үтеп керә. Яшь бала да бит телне аңламый, ә музыканы кабул итә. Җитмәсә, күп кенә җырларның гармониясе дә, ритмы да, интонациясе һәм тексты да башны ватмыйча, уйламыйча гына кабул итүгә корылган. Кеше күңеленә тәэсир итәрлек мондый җиңел музыка тудыру өчен талантлы белгечләрне акча биреп тә файдаланалар. Ә инде көнкүреш музыкасының диверсион тәэсире дәүләтара, милләтара сәясәттә актив кулланылуы күптәннән билгеле.

— **Ни өчен бериш композиторлар аз санлы кешеләр генә тыңлый торган симфоник әсәрләр иҗат итү белән шөгыльләнә. Югыйсә, халык арасында танылу, популярлашу өчен эстрада җырлары язу кулайрак бит?**

— Чыннан да, популяр буласы килгән кеше җырлар язып таныла ала. Нинди җырлар? Көнкүреш җырлары язып. Академик пландагы җырлар язсаң, популяр була алмыйсың. Симфония, балет язсаң да шулай. Бигрәк тә бездә. Ә менә Көнбатыш илләрендә, Балтыйк буе халыкларында, Грузиядә алай түгел. Аларда бала чактан ук урта белем биргән кебек, музыкаль белем дә б
ләр. Аларга симфони
балет та эстрада, джаз
зыкасы кебек үк яхшы
лашыла. Ә без йөз ел
дәвамында колониаль
стемада яшәү сәбәпле
ндый үсешкә ирешә а
ганбыз һәм академик
зыкага якын түгелбез.

Икенче яклап килен
расак, иҗаты бит ире
ләп булмый. Бу — ко
зиторның күңел ихты
Кеше махсус композ
белеме алган икән, үз
зыкаль фольклорын я
белә, бөтендөнья муз
сын өйрәнә. Ул бу бай
ны тулысынча файдала
рга тиеш. А.Хачатурян
әйткәне булды: «Бере
кинофильмнардан з
килүгә, шунда чапты
Ә мин, күп заказлар
торып та, бармадым

Күзгә-күз карап

«Мин карында чакта ук музыка тыңлап үскәнмен»

Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, күренекле композитор Ренат Еникеев белән әңгәмә

өчен? Академик муз
ның мичен гел кызды
ге яндырып торырга
рәк. Бер суына икән,
генә кире кайтарып
мый. Күпләр кире кайт
алмый. Ә мин «Спарт
ны, скрипка өчен кон
яздым», — диде.

— **Соңгы вакытта
позиторларыбызның т
дәрәҗәдәге конкурс
стивальләрдә катна
ишетәбез. Димәк, әсә
ребезне башка халыкл
ишеттерү мөмкинлеге
арта бара. Ничек бәя
мондый очрашуларда
нең иҗат? Академик м
кабызның миче бик с
түгелме?**

— Әйе, музыкаль ф
вальләр, конкурслар
лып тора. Композито
рыбыз да аларда бик т
катнаша. Хәтта үзебе
Казанда да «Аурупа-А
дип исемләнгән халы
фестиваль оештыры
Дөрес, мондый чара
бездә элек тә, социал
заманында да була иде
сынауларда безнең му
һәрвакыт зур бәя ала
де. Югары дәрәҗәдәге
рашуларда минем үзем
дә кыллы квартет, си
ныт оркестр өчен рапсо
кебек әсәрләремне де
ның төрле почмакларын
яңгыратырлык әсәр
бәяләделәр. Колл
рым иҗатыннан да күп
саллар китерергә була
ңгыларын алсак, Р.К
муллин Германиянең
зден шәһәрендә узган
ләр конкурсында дип
алуга ирешә. Әле күп
түгел генә Японияд а
жировка, ягъни чит әсә
рне эшкәртү буенча
курс узды. Анда комп
тор Р.Билалов лауреат
менә лаек булды. Ә
иҗатыбызга чын бә
өчен бу аралашулар
бик аз. Шуңа күрә ун
ларыбыз да диңгезд
тамчы булып күренә
рупа-Азия» фестивале
кайбер библиографик б
шмәләр белән таныш

идем мин. Анда катнашкан яшь япон композиторлары, мәсәлән, һәркайсы берничәшәр халыкара конкурслар лауреаты яисә дипломанты. Мәсьәләнең икенче ягы әсәрләрнең башкарылуына бәйле. Чит илләрдә күптән яңгырый безнең әсәрләр. Моңа мисаллар байтак. Әмма аларны үзебезнең музыкантларыбыз шунда барып уйный. Ә менә чит ил музыкантлары яисә труппаларының безнең әсәрләрне үз репертуарларына алуын мин белмим. Булсын ул камера әсәре, симфония яисә опера. Шул биеклеккә ирешү — безнең төп бурычларыбызның берсе. Үз вакытында Ф.Яруллинның «Шүрәле»се Англиядә дә, Болгария, Аргентинада да куелды. Без аның белән бик горурландык. Бүген исә ул балет та чит илләрдә куелмый шикелле.

Чит ил музыкантлары безне ни өчен башкармыйлар соң? Бу --- катлаулы мәсьәлә. Монда әсәрнең югары дәрәҗәдә булуы гына да җитми. Дустым Ш.Монасыйповның остазы мәшһүр скрипкачы Янкелеевич: «Музыкада сәләтсез берни эшләп булмый. Әмма үзеңне халыкка таныту өчен бер процент музыкаль сәләтеңә туксан тугыз процент пропаганда алып бару сәләте булырга тиеш», дип әйтә торган булган. Бәлки, безнең музыкантларыбызга да, оешма, дәүләт җитәкчеләренә дә шушы сәләт җитенкерәми торгандыр.

— Көнкүреш музыка өлкәсендә авторларны профессиональ һәм һәвәскәргә бүлеп йөртү галәмәте бар. Сез бу бүленешкә ничек карыйсыз?

- - Сез, көнкүреш музыка, дип дөрес билгеләдегез, чөнки академик музыкада һәвәскәрлек булуы мөмкин түгел. Мин иҗат кешесен профессиональ һәм һәвәскәргә дипломына карап бүлмим. Үзлегеңнән яисә махсус дәресләр алып та укырга, өйрәнергә мөмкин. Диплом алып та, профессионал була алмаучылар бар. Монда сәләтнең роле зур. Әмма сәләт белән генә дә ерак китеп булмый. Композитор булам дисең икән, син композициянең барлык нечкәлекләрен белергә, музыкаль фольклорны, бөтендөнья музыкасын үзләштерергә тиешсең. Нинди генә һөнәр иясен алмыйк, чын сәнгать әсәре тудыру өчен аңа белем кирәк. Шуңа күрә көн саен гөмбәләр кебек үсеп торган һәвәскәр көйчеләрне чын иҗатчылар белән бәйләп карый алмыйм мин.

— Сезнең иҗатыгыз күпкырлы. Симфоник, камера музыкаларыннан тыш, Сез халык җырларын эшкәртү белән дә шөгыльләнәсез. «Карьят батыр», «Уел», «Бик еракта идек без» кебек җырлар әнә шундыйлардан. Үзегез дә күпләгән җыр иҗат иттегез. «Ак дулкыннар», «Ләйсән», «Синең эзләр», «Кәккүк моңнарын тыңларга» кебекләре исә халык арасында зур популярлык казанды. Соңгы вакытта профессиональ композиторларның җыр жанрыннан читләшүләрен ни белән аңлатырга? Чыннан да, эстрада концертларында аларның җырлары соңгы вакытта сирәк яңгырый башлады бит...

—- Профессиональ композиторларыбыз бу популяр жанрда һәрвакыт эшләделәр. Аларның халкыбыз күңелен, холык-фигылен, рухи байлыгын чагылдырган әсәрләре дистә еллар буе яңгырады. Бүген исә бу җырларны нигездә радиодан гына ишетәбез. Хәзер алар сәхнәдән сирәк кенә түгел, бөтенләй җырланмый. Чөнки бүгенге сәнгать дөньясында законны иҗатчылар түгел, ә базар мөнәсәбәте чыгара. Җырчыларны да базар үзенә тартып алды. Аларга да акча эшли торган әсәрләр генә кирәк. Сәнгать кешесенең иҗади теләге берәүне дә кызыксындырмый бүген. Шулай да композиторларыбыз югалып калды дип әйтмим мин. Яшьрәк буын җыр жанрында да эшли, эзләнә. Р.Абдуллин, Р.Әхиярова, Л.Батыр-Болгари, Р.Кәлимуллин, М.Шәмсетдиноваларның иҗаты минем сүзләрне раслый торгандыр. Бәлки, заманалар да үзгәреп китәр әле. Чын иҗатка омтылыш халыкта бетмәс тә, кимемәс тә, дип уйлыйм мин.

— Музыка сәнгатебезне савыктыру, үстерү юлларын ничек күзаллыйсыз?

-- Сәнгатебезне һәм, гомумән, милләтебезне савыктыру аның киләчәге — яшь буынны тәрбияләүгә бәйле. Бу — бердәнбер юл. Тарих та шул турыда сөйли. Мәгълүм ки, венгрлар үз вакытында дәүләтчелеген генә түгел, телен дә югалткан халык. Аларга немец шаукымы көчле була. Немецча сөйләшә дә башлыйлар. Нидән килә бу? Башта аларга немец көнкүреш музыкасы, җырлары килеп керә. Аларны махсус өйрәнеп торасы юк, музыкаль белем дә кирәкми. Шуны аңлап, венгрларның Б.Бартак, З.Кодай кебек күренекле сәнгать әһелләре, композиторлары халык арасына китәләр. Халык җырларын, балалар иҗатын җыйнарга тотыналар. Һәм шул меңләгән җырларны балалар бакчаларында, мәктәпләрдә өйрәтә башлыйлар. Телен онытса да, бала милли көйне бик тиз ота. Көйне откач инде аның үз теленә, тарихына да мәхәббәте уяна. Шулай итеп, венгр халкы тиз арада телен, әдәбиятын, сәнгатен кире кайтаруга ирешә. Милләт кайта, дәүләтчелек кайта. Безнең өчен дә бердәнбер юл — балалар белән эшләү. Аның өчен тирән белемле кадрлар әзерләү, матур басмалар иҗат итеп, зур тираж белән балалар җырларын тарату зарур. Баланың башын төрле стильләр белән тутырудан саклану да кирәк безгә. Үскәч, стиль-юнәлешләрне ул үзе сайлар. Музыкага өйрәтү нигезе исә, һичшиксез, милли булырга тиеш. Менә шул чагында гына яшь буын музыканың барлык юнәлешләрен дә милли нигездә үстерә алыр, дип ышанам.

Әңгәмәне
Ким МИҢНУЛЛИН
оештырды.

МОСАФИР СӘФӘРДӘН КАЙТТЫ

Ливан — ул гарәп Швейцариясе

Бу мөмләкәтне дөньяның барча кыйтгаларында икенче төрле шулай атыйлар.



Татарстан башкаласы элек-электән төрки дөнья мәркәзләренең берсе булып саналган. Ләкин совет чорында ул үз казанында гына кайнап яшәргә мәҗбүр ителде. Нәтиҗәсе һәркемгә мәгълүм. Татар халкы акрын-акрын гына урыслаша барып, Шәрык мәдәнияте белән элемтәләрне җуя башлады. Бәхеткә, тарих бу юлы да татар халкына мәрхәмәтле булып чыкты. Хәзер безнең азмы-күпме булса да мөстәкыйльлегебез, үз Конституциябез бар. Чит илгә чыгып керү дә Әлки районына барып кайту кебек гадәти бер хәлгә әверелде. Империя читлеге ачылуга ук (ул әле җимерелмәде) зыялыларыбызның иң беренче нәүбәттә Шәрык илләре белән мәдәни элемтәләр урнаштыра башлавы да очраклы гына хәл түгел.

Шәрык тарафы —- татар мәдәниятенең генә түгел, башка төрки халыкларның да чишмә башы ул. Аның белән гасырлар буена аралашып, без дөнья мәдәниятенең алтын сандыгына меңнәрчә җәүһәрләр салырга сәләтле зур һәм абруйлы милләт буларак таныла алдык.

Бүгенге көндә Татарстан Урта диңгезнең көнчыгыш ярында урнашкан Ливан Республикасы белән дә элемтәләрен ныгыта башлады. Казан каласындагы югары уку йортларында сиксәнгә якын шул ил егетләре һәм кызларының белем алуы моңа ачык мисал булып тора.

Ливан Республикасында шәхси чакыру буенча булып кайтучы милләттәшләребез саны да елдан-ел ишәя бара. Шунысы сөенечле, алар арасында мондый сәфәрләр вакытында милләт мәнфәгатьләрен беренче урынга куючылар күбрәк. Бүген мин мөхтәрәм укучыларыбызга әнә шундый ватандар зыялыларыбызның берсе — гарәп мәдәни үзәгенең Якын Көнчыгыш илләре буенча бүлек мөдире Азат АХУНОВ белән әңгәмә тәкъдим итәм.

-- Азат әфәнде, мәгълүм булганча, Сез әле күптән түгел генә шәхси чакыру буенча Ливанда булып кайттыгыз. Иң беренче нәүбәттә бу ил турында берничә сүз әйтсәгез иде?

—- Ливан - - күпмилләтле дәүләт. Аның халкының 46,5 процентын мөселманнар —- шигыйләр, сөнниләр һәм друзлар, 53 процентын христианнар тәшкил итә. Бу - - 30 нчы елларда алынган халык саны. Рәсми булмаган мәгълүматларга караганда, хәзер Ливанда мөселманнар саны күбрәк, диләр. Конституция буенча анда Президент итеп христиан кешесе генә сайлана ала. Премьер-министр — сөнни, парламент рәисе -— шигый.

Мин үзем Ливан Республикасы башкаласы Бәйруттан кала иң эре шәһәрләрнең берсе булып саналган Триполидә булдым. Анда Ислам университеты ректоры Рәшит шәех белән очрашып, татар егетләрен һәм кызларын әлеге югары дини уку йортында укыту эшен җайга салу турында сөйләштем. Алла боерса, бу хыял тормышка ашар, дип уйлыйм. Ошбу университетта белем алу өчен гарәп телендә укый һәм яза белү зарур. Уку дәвере - - дүрт ел.

Мине шулай ук Гарәп мәдәни мәркәзе рәисе, доктор Нәдә дә кабул итте. Ул Ливанда Татарстан хөкүмәте булышлыгы белән татар мәдәниятен һәм тарихын чагылдыручы күргәзмәләр оештыруның ике дәүләт өчен дә гаять кызыклы һәм файдалы гамәл булачагы турында сөйләде. Ливанда безнең мәдәният һәм сәнгать әһелләренең, аерым иҗат коллективларының чыгышларын оештыру зарурлыгы турында да сүз булды. Гарәп мәдәни үзәге бу тәкъдимнәрне Татарстан хөкүмәте җитәкчеләренә җиткерде инде. Аларның бәхилләве белән бу тәкъдимнәр акрын-акрын гына гамәлгә аша башлар, дип беләм.

Ливанны, икенче төрле, гарәп Швейцариясе дип атыйлар. Чөнки дөньядагы бик күп бай банклар анда урнашкан. Бу дәүләттә барча конфессияләр дә бер-берсе белән янәшә яшәп, искиткеч бай һәм үзенчәлекле архитектура ансамбльләрен хасил иткәннәр.

Гомумән, мәдәни яктан нык алга киткән Ливан мөселманнары белән багланышлар булдыру безнең халык өчен һәр өлкәдә дә — икътисадта, мәдәнияттә, сәясәттә булсын — бик файдалы булыр иде.

-- Сез Ливанга кемнең чакыруы буенча бардыгыз?

— Минем Казан дәүләт медицина университетының икенче курсында укучы Басыйл исемле бер якын дустым бар. Ул —- Ливан егете. Былтыр аның әнисе Ханан ханым да Казанда булып китте. Мин аны Болгарга алып бардым, Казанның тарихи урыннары белән таныштырдым. Ватанына кайтып җитүгә, ул мине үзләренә кунакка чакырды. Сүз белән әйтеп, каләм белән язып бирә алмаслык матур һәм җылы хатирәләр калды күңелдә. Андагы берсеннән-берсе гүзәл һәм мәһабәт мәчетләр, матур тар урамнар һаман да күз алдымда тора.

— Рәхмәт, Азат әфәнде, сезнең милләт өчен җан атып яшәүче Гарәп мәдәни үзәге җитәкчесе Александр Михеев әфәндегә һәм дә анда эшләүче барча зыялыларыбызга да уңышлар һәм нык сәламәтлек теләп калам.

Әңгәмәне Заһид МӘХМҮДИ оештырды.



● Триполи шәһәре күренешләре.

«Өча торган татарлар»

Раушания ханым Кадыйрова утыз өч ел буе Татарстан телевидениесендә режиссер булып эшләде. Шул дәвердә ул үзебезнең әдәбият-сәнгать әһелләре турында күпсанлы тапшырулар һәм фильмнар әзерләде, һәм ул тапшырулар ел дәвамында үзәк-телевидениедән дә күрсәтелә килде. Болар — Салих Сәйдәшев, Илһам Шакиров, Нәҗип Җиһанов, Ренат Ибраһимов, Зилә Сөнгатуллина, Зөһрә Сәхабиева, Зөһрә Шәрифуллина һ.б. турындагы тапшырулар һәм фильмнар.

Төркиядә әдәбият-сәнгать әһелләрен берләштерә торган «Туран» фонды яшәп килә. Раушания ханым шушы фондның президенты Туран Язган турында да телевизион фильм эшләде, ул урыс һәм төрек телләрендә «Эфир» каналы аша күрсәтелде. Раушания ханым шулай ук Финляндиядә яшәүче милләттәшебез Дәнис Бәдертдинне «Сагынам, дуслар!» дигән ансамбле белән бергә телевизион фильмга төшерде.

Раушания ханым халкыбызның ике мәшһүр улы — Рудольф Нуриев һәм Ирек Мөхәммәдев белән дә таныш икән. Аның сүзе — шулар хакында.

Рудольф Нуриевның язмышы белән мин 1961 елда ук — ул чит илдә калган мәлдә үк — кызыксына башладым. Материаллар җыйдым. Күрсәтәсем килде. Ләкин аны тыйдылар.

Ниһаять, 1992 елның март аенда Казанга симфоник оркестр белән дирижерлык итәргә пиндидер Нуриев килгән, диделәр. Шундук репетиция булган җиргә киттем. Залда Нуриевның апасы Резеда бар иде. Таныштык. Ул мине энесе — Рудольф белән таныштырды. Прокофьевның «Ромео һәм Джульетта»сы буенча репетиция булды. Сөйләштек. Дустым Сергей Синцов аның бөтен репетициясен тасмага төшерде.

Репетициядән соң Нуриев Ленинград аша Метрополитен-операга (АКШ) шул ук сюитаны дирижерлык итәргә китте.

Шул ук 1992 елның маенда Рудольф Нуриев Казанга кабат концерт бирергә килде. Концертта апасы Резеда, туганнары (әнисенең сеңлесенең кызы Мәдинә) булды.

Тәнәфес вакытында Нуриевның грим бүлмәсенә кердем. Бер ханым аңардан автограф алып тора иде. Рудольф мине әлеге ханым белән таныштырды.

-- Бу -- Ирек Мөхәммәдевнең әнисе, -- диде ул.

Шулай итеп, без Рәшидә ханым белән дә таныштык.

Үзебездә кунакта чакта мин Рудольфка:

— Сезнең дирижер булып Казанга килүегез турында фильм эшлисем килә, материалларым бар, — дидем.

-- Бик рәхмәт, мин сезгә булышырмын, -- дип ул шундук ризалыгын белдерде.

Ул үзенең сәркатибе Нэйл белән бергә килгән иде. Нэйл минем адресымны язып алды; Рудольфның беренче партнеры Нинель Александровна Кургапкинаның (Минкусның «Дон-Кихот» балетында иң яхшы Китри), Рудольфның Париждагы иң якын дусты Дусның телефоннарын бирде. Әмма ләкин... ләкин, кызганычка, моны тормышка ашырырга насыйп булмады. Ул, гомеренең соңгы көннәрендә, туган иле белән хушлашырга гына кайткан булып чыкты... Шулай да, Киновидение үзәгендә без моны тормышка ашырырга тырышып караган идек, һаман да шул акча булмау аяк чалды.

Мин химаячы эзли башладым. Юлым мине «Аверс» банкы директоры Ренат Габделбәр улы Заһидуллин янына алып килде. Эше үтә тыгыз булуга да карамастан, ул мине игътибар белән тыңлады. Шулхәтле матур итеп татарча сөйләшә, үзе әдәпле, тәрбияле, итагатьле!

-- Нуриев турында фильм төшерергә кирәк, әлбәттә. Мин сезгә ярдәм итәрмен, ләкин башта, үзе исән чакта Ирек Мөхәммәдев турында төшерергә кирәк иде фильмны, -- диде Ренат әфәнде.

Ярый әле татарның да Мамонтовлар, Третьяковлар, Дягилевлар кебек кешеләре бар, дип уйладым мин, куанып. Аның тормыштагы девизы да: «Без дөньяны яхшы якка үзгәртүчеләр яклы!» -- дигән девиз бит!

Миңа Ренат әфәнденең фикере белән килешергә туры килде, әлбәттә, әмма Рудольф Нуриев турындагы фикеремне, уемны, өметемне ташламыйм, күңелемдә йөртәм.

Ирекнең әти-әнисе белән танышкач, чыннан да, Ирек турында, аның әти-әниләре турында фильм төшерәсе килә башлады.

Рәшидә ханымны мин Нуриев дирижерлык иткән «Щелкунчик» балетына чакырдым, ул классик балет фестивале кысаларында барды (ул чакта Рудольф Нуриев исеме бирелмәгән иде әле аңа). Шуннан без якынаеп киттек. Мин Ирек турында тапшыру әзерләргә булдым.

Ирек бит Казанның үзендә туган. Октябрь урамындагы мәктәпкә укырга йөргән. Ленин исемендәге мәдәният сараеның бию түгәрәгендә шөгыльләнгән. Ул түгәрәк белән Вероника Мартьянова җитәкчелек иткән. Ирек беренче тапкыр А.Говорухинның «Тегүче малай» исемле балет-спектаклендә шәп иттереп Песи булып биегән.

Аннары Ирек Заһид Хәбибуллинның «Сихерләнгән малай» балетында Раушан ролен башкарган. Ул спектакльне автор үзе дә караган.

Шуннан соң Вероника Мартьянова:

-- Малайны Мәскәүдәге хореография училищесына әзерлибез, -- дигән карарга килә.

Баланы Нинель Даут кызы Юлтыева да сынап карый. Ул:

-- Ленинградка, Ваганова училищесына җибәрергә кирәк, — дигән тәкъдим кертә.

Ләкин Ирекнең әти-әнисе улларын Мәскәүгә җибәрергә, дигән карарга килә, чөнки анда Рәшидә ханымның бертуган апасы яши. Һәм ун яшьлек Ирек Мәскәүгә барып училищеда укый башлый.

> ***... Без — татарлар. Минем әнием Казан дигән гаҗәеп матур, борынгы калада туган.***
>
> ***Мин үземнең, урыс булмыйча, татарлыгымның нидән гыйбарәт икәнлеген аермачык әйтә алмыйм, әмма үземнең табигатемдәге үзгәлекне тоям. Безнең татар тамырындагы кан тизрәк агадыр сыман, һәрдаим кайнап чыгарга әзердер сыман ул. Аннары миңа без ягымлыракбыз, хисләрәкбез, сизгеррәкбез кебек тоела; безнең халкыбызда, азиатларга хас булганча, моңлылык, хисселек бар; моны безнең борынгы бабаларыбыздан — асыл зат сылу җайдаклардан килгән сыйфат, дип әйтеп була. Без — шул сизгерлекнең һәм каты куллылыкның кызыклы бер катнашмасы, мондый катнашма урысларда сирәк очрый. Татарлар, тиз кабынып китеп, көрәшкә тиз кушылучан, әмма алар бәйләнчек түгел, шул ук вакытта кызу канлы, ә кайчакта хәтта төлкедәй хәйләкәр. Татар — ул бик тә катлаулы җанвар, мин дә нәкъ менә шундый җанвар булам инде.***
>
> ***Рудольф НУРИЕВ.***

* * *

... Шулай итеп, «Аверс» банкы ярдәме белән без -- дүрт кеше -- Лондон тарафларына юл тоттык.

Башта мин Ирек белән телефон аша сөйләшүләр алып бардым. Ул Ковент Гарден театрның сәнгать җитәкчесе Энтони Дауэлны да, үзенең беренче партнеры Лэслины да, мәшһүр хореограф Макмилланның тол хатыны Деборагы да, язучы Роберт Тэйлорны да, Кырым ханы Гәрәйнең варисларының берсе принц Чезар Гәрәйне дә фильмга төшерергә сөйләшеп, килешеп куйган. Без килүгә, бу кешеләр инде барысы да безнең белән Ирекнең тормышы һәм иҗаты турында әңгәмә корырга әзер иде.

Мөхәммәдев дип әйтүгә, безнең алда бөтен әгелчәннәрнең ишеге ачыла иде.

Без килеп төшкәндә Фридерик Аштон дигән мәшһүр хореографның 90 еллыгын бәйрәм итәләр иде. Ирек тә Ф.Аштон куйган спектакльләрнең берсендә биергә әзерләнә. Шул ук көнне Тэйлорның «Ирек Мөхәммәдев» дигән китабын тәкъдим итү булды. Бу чарага бөтен гаиләсе белән принцесса Маргарет та килгән иде.

Ковент Гарден театры урнашкан төбәктә йөргәндә минем күз алдымда гел Рудольф Нуриев торды. Ковент Гарден эчендә Р.Нуриев рухы яши. Спектакль куючылар бүлмәсенә керсәң -- анда Нуриев портреты эленеп тора, артистлар бүлмәсендә дә -- шул ук хәл!

Лэсли белән, Макмиллан хатыны, яисә Мөхәммәдевнең агентлары белән сөйләшкәндә, алар барысы да Р.Нуриевны (ул анда 60 нчы еллар ахырында, 70 нче еллар башында эшләгән) бик яхшы хәтерләүләре һәм аны яратулары турында әйтәләр.

-- Мондый йолдызлар яңадан бервакытта да кабынмас инде... -- диләр алар.

Ирек Мөхәммәдев тә Рудольф Нуриев турында бик җылы итеп сөйләде. Париждагы Гран-Опера театрында сәнгать җитәкчесе булып эшләгәндә Рудольф Ирекне «Дон Кихот» һәм «Йокыга талган гүзәл» спектакльләрендә биергә чакыра.

Ковент Гарден -- дөньяның иң мәшһүр театрларыннан берсе. Биредә Русиядән Сергей Лефарь һәм Тамара Корсавина, Вацлав Нежинский, Вера Волковалар биегән.

1961 елда Нуриев Ковент Гарденга башка исем белән килә, чөнки ул чакта инде аны юк итәргә әзерләнгән булганнар...

Ковент Гарден театрына югары зәвыклы купшы тамашачы йөри. Мин Ирекнең сәхнәгә чыгуын карап утырдым. Шулкадәр дулкынландыргыч мәл булды бу: менә, минем якташым дөньяның иң мәшһүр сәхнәсен бизи! Тамагыма төер утырды, күземә яшь тыгылды... Ирекне озакка сузылган алкышларга күмделәр. Анда якташыбызның кадерен бик яхшы беләләр, театрга махсус аны күрер өчен киләләр. Ул катнашкан спектакльләргә билетлар алдан ук сатылып бетә. Принцесса Маргарет исә аңа гомумән табына, аны кайгырта-күзәтә. Ә безнең үзебезнең ул лачын-улларыбызның талантын күреп хозурланырга мөмкинлегебез юк, аларның сәнгатеннән күңелебезгә, җаныбызга рухи азык ала алудан мәхрүмбез, чөнки аларга үз илебездә урын юк...

Инглизләрне һавалы, салкын халык диләр. Һич тә алай түгел. Аларның күзләре үк нурланып, янып тора.

Телне дә, барасы җиремнең адресын да белмәгән килеш алар миңа музейны барып табарга ярдәм иттеләр. Моның өчен мин Пикассо, Ван Гог, Рафаэль, Ван Дэй исемнәрен генә атадым!

Ковент Гарден төбәгендә Театр музее урнашкан. Музейда мине иң шаккатырганы шул булды: анда беренче итеп Р.Нуриев фотосын куйганнар, аннары гына Англиянең үз мәшһүрләре -- Вивьен Ли, Лоуренс Оливье һ.б. урын алган! Музейга керә торган ишек каршына да Рудольф Нуриев фоторәсеме куелган. Театр музее бүлекләп оештырылган: драма театры бүлеге, балет бүлеге, опера бүлеге һ.б. Балет бүлеге башланганда тагын аягүрә Рудольф Нуриев басып тора.

Англиядә Р.Нуриевның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге турында матур итеп бизәлгән 600 битлек китап чыккан. Анда Нуриевның Казанда булуы турында да фоторәсемнәр бар. Китапны музейга сатарга куйганнар. Аның янында -- тагын Нуриев фотосы!

* * *

Ирек турындагы фильмыбыз эшләнеп бетеп килә, күзләргә таба әзер булыр инде, иншалла!

Менә шулай, үзебезнең лачыннарыбыз тормышы белән рухланып яшим инде мин...

Раушания КАДЫЙРОВА,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

● **Рудольф Нуриевны Аурупада «оча торган татар» дип йөрткәләр.**

● **Ирек Мөхәммәдев «Файдасыз саклык» спектаклендә.**

Хәтер кайтавазы

Ак яулыклы әбием

Туган авылым Кошманга кайтсам, күз алдыма дәү әнием — Сәләхова Нурсафа Ибраһим кызы килеп баса. Ул инде күптәннән җир куенында, каеннар күләгәсендә мәңгелек йокыда булса да, аның көчле, мәрхәмәтле рухы безнең күңелләрдә яши, ялгышлардан саклап килә. Педагогик эшчәнлегемдә, үз балаларымны тәрбияләгәндә, әйләнә-тирәдәге кешеләр белән аралашканда дәү әни күңелемә сеңдергән халык педагогикасы алымнарын бик еш кулланам. Бүгенге сыек рухлы, денсез, миһербансыз заманда олы җанлылыкны салкын прагматизм, оятсызлык, явызлык, мәрхәмәтсезлек алыштырган авыр бер мохиттә, мин күңелем белән Ак әбиемә мөрәҗәгать итәм. «Әгәр дә аның тәрбия ысулларын бүген күпләр кулланса, сабыйлар күңеленә рухи мирас итеп сеңдерсә, никадәр гаиләләр таркалмас, яшь гомерләр өзелмәс, әзмәвердәй ир-егетләр таш капчыкларда гомерләрен заяга уздырмас иде», — дим.

Изгелек ит тә диңгезгә сал — балык белер, балык белмәсә, халык белер

Дәү әни кечкенә генә буйлы, юка гәүдәле, зәңгәр күзле, ачык йөзле, хөр күңелле карчык иде. Кич җитеп, табын янына тезелешеп утырсак: «Аллага шөкер, бүген дә дөньябыз түгәрәк, табыныбыз тукмаклы!» — дип шөкрана кыла. Мин аның һич кенә дә төшенкелеккә бирелгәнен, уфтанганын, кеше малына кызыкканын, көнчелеген, гайбәт сөйләвен хәтерләмим. Күңеле киң булгандыр, аның тирәсеннән гел кеше өзелмәде. Безнең урамның бөтен бала-чагасы аны хөрмәтләп, «дәү әни» дип йөртә иде. Ул үзе янында бөтерелгән балаларның һәркайсына җылы сүз таба; йә үсүләренә куана, йә яңа киемнәрен күреп, «бигрәкләр дә килешә инде» дип, сабыйларның күңелләрен күтәреп җибәрә.

Көз җитә башлагач, безнең бакчада алмалар өлгерә. Дәү әни безгә кечкенә зәңгәр чиләкләр тоттыра да тирә-күршегә, туган-тумачага алма өләштерә. Сыерлары таңлаган кешеләргә сөт керттерә. Посылка килсә, күчтәнәч җимешләрдән күршеләргә авыз иттерә. Аның үзенә дә күчтәнәчләр явып кына тора: кульяулыкка пөхтәләп төрелгән йөзем, өрек, инҗир, әлүән каклары алып килеп дәү әнигә дога кылдыралар.

Безнең сабый йөрәгебезгә юмартлыкның бик кирәкле орлыклары сибелә, күркәм сыйфат икәнлеге сеңдерелә.

Дәү әни һәрбер кергән кешене баллы май, корт, каймаклы катык, хуш исле чәй белән сыйлап чыгара. Ул пешергән коймак-кабартмалар телеңне йотарлык була. Аның кунакчыллыгы гаделлеге белән юлдаш. Берәүне дә артык яки ким күрми. Күчтәнәчкә килгән һәр нәрсәне гаилә әгъзаларына тигез итеп бүлеп бирә, берәү дә өлешсез калмый. Дәү әнинең бу гамәлен мин үз балаларыма да өйрәттем. Балалар бакчасыннан алып кайткан алмаларын да, пычак белән кисеп, улларым 4 өлешкә бүлеп куялар иде. Үз өлешләрен ашыйлар, әти-әнигә дигәненә тимиләр, куана-куана безгә каптыралар.

Әле хәзер уйлап куям да, дәү әни халык педагогикасының иң кирәкле элементларын безнең күңелләргә салырга тырышкан бит, дим. Гади генә гамәлләре аркылы юмартлык, кеше хәленә керә белү, һәркемне тигез күрү, гаделлек, эчкерсезлек сыйфатлары тәрбияләргә тырышкан.

Әдәпленең күлмәге сәдәпле, үзе матур гадәтле

Әби күп телләр белә, татар теленең нечкәлекләрен, әдәбиятын-сәнгатен, фольклорын яхшы үзләштергән. Безгә әкиятләр, шигырьләр, бәетләр, дастаннар сөйли. Үзбәк, таҗик, урыс, фарсы, гарәп әдәбиятыннан мәгълүматлы. Ул шигъри җанлы. Урманда агач ботаклары шавын музыка итеп ишетә, җил сызгыруын курай аһәңенә охшата. Кошлар сайравын онытылып тыңлый. Үзе дә моңлы итеп мөнәҗәтләр укый, «Усл», «Тәфтиләү», «Кара урман», «Сарман»нарны гаҗәеп матур итеп җырлый. Аның әдәбияткә-сәнгатькә мөнәсәбәте миңа да күчте: шигырьләр язуым, тел, әдәбият укытучысы булып китүемә дә дәү әни сәбәпче. Ул сөйләгән әкиятләрдә батырлыкка, матурлыкка, яхшылыкка дан җырлана, әдәби әсәрләр аша безгә әхлак кагыйдәләре сеңдерелә, эстетик зәвык формалаштырыла.

Урамда уйнап кайткач, ашыйсы бик килсә дә, олылардан узып, ризыкка сузылмыйбыз, урлашмыйбыз. Дәү әниебезнең түгәрәкләп кискән телемнәрен валчыгына кадәр ашап бетерәбез, табынга ни куелса, шуны ялындырмый ашыйбыз, рәхмәт әйтеп торып китәбез. Институтта укыганда тулай торакта теләсә кая аунап, күгәреп, нәҗесләнеп яткан бербөтен, ярты ипиләрнең, батоннарның кадерсезләнгән күргәндә, тәннәрем чемердәп, әллә нишләп китә идем. Мәктәп ашханәсенең чүп чиләкләренә бер-ике генә тешләп ташланган икмәк телемнәренә күзем төшкәндә дә, йөрәк әрни-сыкрый килде. «Икмәкне хурлау, аңа басу — гөнаһ, Ходай әлләни бирер», — дия иде дәү әни. Бүгенге көнне икмәк бәясенең 16 тиеннән мең сумга менүен уйлыйм да, сансызлыгыбыз өчен күрмәгәнне күрә башладык, ахрысы, дип фикер йөртәм.

Барына бәрәкәт, югына хәрәкәт

Әбиебезнең рухы табигатьтән аерылгысыз иде. Йортыбызда ир-ат булмаса да, безнең өй кыегына сыерчык оясы куелмый калмый. Сыерчыкларның килүен, бала чыгаруын һәркайсыбыз көтә.

Бакчадагы җиләк-җимештән дәү әни кошларга өлеш калдырта. «Миләшләрне җыеп бетермәгез, кышкы салкыннарда кошларны ач үлемнән саклый ул», — дип искәртә.

Безнең сабый чак уфаллалы, урманлы иде. Язның беренче мизгеленнән кара көзгә чаклы без — ярты ятимнәр — кыякка, сәрдәгә, җуага, утынга йөрибез. Үлән җыйганда кош оялары очрый. «Бәбкәчләрем, бер үк кош ояларын туздыра, йомыркаларын төшереп вата күрмәгез, ана кошның өметен кисмәгез», — ди. Кайвакыт агач куышларында чикләвек «склад»лары очрый. «Тиен аны җыяр өчен күпме хезмәт куйган, көч түккән. Кеше әйберенә тисәң — кулың корыр. Сезгә әнә агачтагысы, җиргә коелганы да бик җиткән. Ходай биргәнгә шөкрана кылырга, хәрәм малга өмет сузмаска кирәк». Бу гаҗәеп тылсымлы сүзләр әле дә колагымда яңгырап, мине яманлыклардан саклап тора. Мин аларны түкми-чәчми үзем тәрбияләгән меңләгән укучыларыма һәм газиз балаларыма тапшыра киләм.

Без үскәндә йорт саен җидешәр-сигезәр бала, ашау-эчү такы-токы иде. Ипине кижә ашъяулыкка төреп, шүрлектә саклыйлар, башлы шикәрне дә аз-азлап китеп кенә бирәләр.

Акыл — тезген, холык — ат, тезгенеңне белеп тарт

Дәү әни зыялы дин әһеле гаиләсендә туып үскән. Ул гаҗәп оста дипломат, кеше психологиясен әйбәт белә, һәркем белән уртак тел таба, кемгә ничек тәэсир итәргә икәнен тиз сиземли иде.

Әле дә хәтеремдә: күршедә яшәүче гаилә әгъзалары ызгышкан. Яшь хатын дәү әни янына чәче-башы тузып, елап килеп керде. «Бер көн дә тормыйм, баланы алам да китәм!» — дип өзгәләнә. Ирен ямьсез сүзләр белән хурлый. Дәү әни нишләде дисезме? Башта яшь ханымны салкын су белән юындырды, кулына тарак белән көзге тоттырды, үз-үзен тәртипкә китерергә кушты, аннан самавырын дөрләтеп җибәрде. Тәмле теле белән җайлап-көйләп чәй эчертте. Теге апа бераз тынычлана төшкәч, башта аның үзен, аңа кушып ирен мактарга кереште. «Сез бигрәкләр дә әйбәт күршеләрем инде, лар аккошлар кебек бигрәкләр дә матурсыз. Улыгызны тигезлек белән үстерергә язсын. Безнең балаларны сугыш ятим итте, сезнекеләр әтиле-әниле булсын, балакай. Толлык гомере — ятимлек, кимлек ул, аңа кызыкма. Беребез дә алтын түгел, җитешмәгән якларыбыз да җитәрлек. Юләр җиңдем, дигән, акыллы юл куйдым дигән. Син бит яхшы ата баласы. Үзең дә җүнсез түгел, Аллага шөкер. Әнә ишек алдына кара әле. Үрдәк баласын каз яратмый, чит оянықын чукып маташа. Сабыеңны башка ояда зәгыйфь күңелле итеп үстермәскә тырыш», — дип таслап кына тезеп китте. Дәү әни минем — үсмер кызның — ишетүен әллә сизде, әллә сизмәде, бәлки, колагына керә торсын дип юри минем алда сөйләгәндер.

Күршеләрем аерылышмадылар, әлегәчә матур итеп көн күреп, балаларын аякка бастырдылар, үзләре әби-бабай булдылар.

Хезмәт төбе хәзинә

Без биш кешелек гаилә, бер әнкәйнең хезмәт хакына яшәгәнгә, артык иркенлектә көн күрмәдек. Ләкин ач та, ялангач та булмадык. Ишек алды тутырып мал асраганга, бакча тулы җиләк-җимеш-яшелчә үстергәнгә, гектарлап колхоз борчагы чапканга, чөгендер иккәнгә, очын-очка ялгап бардык. Күмәк хезмәт безне дуслаштырды, берләштерде, ярдәмчеллеккә, чыдамлыкка, эш сөючәнлеккә өйрәтте, һәркайсыбызның үз вазифасы бар иде. Шуны намус белән үтәп, дәү әни белән әнкәйне шатландырырга тырыштык. Үз гаиләмне корып, балалар үстергәндә дә мин дәү әнинең гаилә тормышына әзерлек алымнарын куллана килдем. Балаларымның тырыш, эшчән, намуслы булып үсүләрен, әйбәт укуларын кече яшьтән хезмәткә күнектерүдән күрәм. Хезмәт кенә кешене кеше итә, чыныктыра, авырлыкларны җиңәргә өйрәтә. Гаилә тормышында мең төрле эш башкарырга туры килә. Яшьләрне балачактан ук аңа әзерләмәсәң, алар бу йөкне күтәрә алмыйча, тиз сыгылып төшәләр. Нәтиҗәдә гаиләләр таркала.

Ир-атка да, хатын-кызга да җылы сүз кирәк. Дәү әниебез безгә «бәбкәчем, балам, алтыным,кошчыгым, җаным», дип эндәшә иде. Ул кеше кайгыларын кайгыртып, дөнья гаме һәм ахирәт турында уйланып яшәде. Бик тә оптимист кеше иде. Уйлап карасаң, аның өлешенә күпме бәхетсезлек килгән бит, тик ул аны көчле рухы белән җиңә белгән. 30 яшьтән икенче группа инвалидка чыккан. Ире сугышта һәлак булган. Бердәнбер кызы өч бала белән тол калган. Дәү әни барыбызга да рухи терәк иде. Ул тормышны сөйде, авырлыкларны җиңәрдәй көч тапты, түземле, сабыр булды. Аннан җылылык һәм наз түгелә иде. Аның үз иренә булган мәхәббәте легендага тиң. Соңгы минутка кадәр дәү әтине көтте: «Күңелем сизә, ул үлмәгәндер, йә тоткындадыр, йә госпитальдә генә яткандыр. Хәбәрсез югалганнар да табыла бит. Ике аяксыз, ике кулсыз дисәләр дә дөнья читеннән эзләп табып алып кайтып тәрбияләр идем», — дип өзгәләнеп-өзгәләнеп әйтә иде.

Аның шулай ихластан сөя белүе үзе хөрмәткә лаек. Тугрылыклы, мәхәббәт, хөрмәт, чиксез сагыну, ышаныч тулы иде аның күз карашында. Сугыштан соң, ирләрен көтмичә, яңа гаилә коручыларны ул берничек тә аңлый алмады. Ил сакчысына хыянәт дип кабул итте.

Дәү әни горур иде, ләкин мин-минлек белән авырмады. Физик яктан авыру булса да, рухы көчле иде. Аңа хас күркәм сыйфатлар — миһербанлылык, зыялылык, аң-белемгә омтылучанлык. Телгә җор-чая булса да, беркемне дә хурламады. Бай түгел иде, ләкин ризыгын күпләр белән бүлеште. Безнең белән бергә, әлләни зур булмаган өйдә ялгыз ятим-тол карчык Хәдичә әбине дә сыендырды. Ул безгә туган түгел иде. Аларны бары тик сугыш китергән ачы язмышлары гына берләштергәндер. Бик күп авылдашлар дәү әни янына йөреп, дин сабагына, әхлак-инсаф кагыйдәләренә, аш-суга өйрәнде. Дәү әни чын мәгънәсендә Ак әби иде.

Халидә ГАРИПОВА,
Кайбыч районының укучылар йорты рәисе.

ТЕЛЕ БАРНЫҢ — ИЛЕ БАР

МИЛЛӘТ АЛГА БАРАМЫ, ӘЛЛӘ ЧИГЕНӘМЕ?

Милли хәрәкәт таркалу чорын кичерә. Әлбәттә, бу — бик борчулы хәл. Хәзер без милли кадрлар тәрбияли башлауны максат итеп куябыз. Өч ел дәвамында уңышлы гына эшләп килүче Татар милли университеты (ректоры Х.Гарданов), акрын-акрын гына булса да, менә шушы максатны тормышка ашыру юлыннан бара. Әлеге университетта белем алучы студентларның житмешкә якыны мәктәпне алтын һәм көмеш медальләргә тәгәлләгән яшьләр. Һаман да рәсмиләшеп житә алмаган бу уку йортында белем алырга теләүчеләр саны елдан-ел арта бара. Хәзерге вакытта анда, читтән торып укучыларны да исәпкә алганда, жиде йөзгә якын кеше укый. Үз бюджеты да, бинасы да булмаган университетның шулкадәр зур популярлык казана алуы нәрсә белән аңлатыла соң? Туган телдә югары белем алырга омтылыш зур булу беләндер, дип уйлыйм мин. Чөнки соңгы берничә ел эчендә милли үзаң шундый зур үзгәреш кичерде ки, аны торгынлык елларындагы үзаң дәрәҗәсе белән һич тә чагыштырып булмый. Туган телгә, мәдәнияткә, тарихка ихтирам бермә-бер артты. Аннары бит милли мөстәкыйльлек биш-алты кеше зиһене югарылыгына гына кайтып кала алмый. Безгә бүгенге зыялыларыбыз башлап җибәргән изге эшне дәвам итә алырдай белемле яшьләр кирәк. Татарның урыс телендә белем алып академик дәрәҗәсенә күтәрелгән дөньякүләм танылган академиклары да бар. Ләкин бүген милләт татар телле академикларга мохтаҗ.

Һәр халыкның үз тормышын үзенчә корырга хокукы бар. Мәдәни үсеш дәрәҗәсе аның көзгесе булып тора.

Кытай социализмны милли үзенчәлекләрдән чыгып төзи. Японияләге капитализм да милли үзенчәлекләргә нигезләнгән. Хәзерге шартларда безнең өчен иң мөһим мәсьәләләрнең берсе — мәдәни мөстәкыйльлекне яшәртү, аңны үстерү.

Татар халкы фәкать шулай гына үз-үзен милләт буларак саклап калырга мөмкин.

Кызганычка, татар теле әдәби тел буларак нык үссә дә, әлегә ул фән һәм техника өлкәсендә кулланылмый диярлек. Бу мәсьәләдә ана телебез үле телләр рәтендә калып бара бугай. Татар телендә фәнни китаплар бик аз булу да әнә шуның белән аңлатыла инде. Фәлсәфә фәне өлкәсендә дә гаять фаҗигале хәлгә килеп тарыйбыз. Заманында профессор М.Абдрахманов югары уку йортлары өчен «Диалектик материализм» китабын язып калдырган иде. Я.Гыйззәтуллин исә «Җәмгыять белеме»н тәрҗемә кылды. Ләкин бу татар кебек шундый зур милләт өчен коточкыч аз. Тел никадәр күбрәк өлкәдә кулланылса, ул шуның кадәр баерак һәм камилрәк була бара. Ә тел ярлылыгы халыкның үзаңы саегаюга китерә. Бу җиһанда бар нәрсә дә бер-берсенә бәйләнгән.

Татарлар элек-электән Мәккәгә барып хаҗ кылганнар, Шәрык һәм гарәп илләренә барып белем алганнар. Заманалар уңай якка үзгәреп киткәч, әлеге традиция тагын яңара башлады. Миңа калса, моның белән без үзебезне кимсетәбез генә кебек. Ник дигәндә, чит мәдәнияткә (тугандаш булса да) табынудан бигрәк, үз мәдәни байлыкларыбызны дөньяга танытуга омтылу мең тапкыр дөресрәк һәм файдалырак булыр иде. Монда бөек Тукаебыз безгә үрнәк булып тора. Ул, татар халкына, фәкать аның үзенә генә хас үзенчәлекләргә нигезләнеп, мәдәни юнәлеш биреп калдырган шәхес. Уйлап карасаң, татар дөньясы тарихы һәм мәдәнияте дә башка халыклар тарафыннан өйрәнелүгә, табынуга лаек лабаса.

Гарәп фәлсәфәчеләре (Y—XII гасырлар) борынгы грек философларының әсәрләрен үз телләренә тәрҗемә итеп килгәннәр. Аларның күп кенә әсәрләре гарәп телендә сакланып калган. Аурупа грек философиясен башлыча гарәп телендәге басмалар аша өйрәнә алды. Шуңа күрә дә гарәп теле бүгенге көндә дөньяда иң бай һәм иң камил телләрнең берсе булып санала торгандыр.

Ил САТТАР,
философия фәннәре кандидаты.

Аның ике-өч процентын гына чит телдән кергән сүзләр тәшкил итә. Тәрҗемә эше гарәп телен баетып кына калмыйча, аларның фикерләү алымнарын, фикер йөртү осталыкларын да камилләштергән.

Туган телдә фәлсәфә кора, фәнни бәхәсләр алып бара алмаган халыкның киләчәге юк дип уйлыйм мин. Безгә менә шуны аңлый башларга вакыт. Ә күпләп милли югары уку йортлары булдырмыйча торып, без моңа һичкайчан ирешә алмаячакбыз. Шунсыз милли мөстәкыйльлек турында да сүз алып бару мөмкин түгел.

Татар теле дәүләт теле дип саналса да, безнең балаларыбызның күпчелеге урыс мәктәпләрендә һәм урыс телле югары уку йортларында белем алуларын дәвам итәләр. Һәм хәзергә башкача мөмкин дә түгел. Бөек Ватан сугышыннан соң, бөтен дөнья философиясе урыс теленә тәрҗемә ителеп, нәшер кылынды. Узган гасырлар философиясе генә түгел, 20 нче гасырда барлыкка килгән фәлсәфи юнәлешләрне чагылдыручы әсәрләр дә урыс телендә дөнья күрде. Ә без, татарлар, бу өлкәдә кыл да кыймылдатмадык диярлек. Чөнки моның өчен шартлар да юк иде, рөхсәт тә бирелмәде. Татар халкы азмы-күпме мөстәкыйльлеккә ирешкәч тә, һичбер алга китеш сизелми. Шуңа күрә дә галимнәр берничә тел белергә тырышалар. Ана теле һаман икенче рәттә калып бара. Ап-ачык ки, дөнья күләмендә зур абруй казанган халыкларның рухи казанышларын үзләштереп бармасак, безнең мәдәниятебез сай да, таркау да, тар да булып калачак. Фикер югарылыгыңны башка халыкларның казанышлары белән чагыштырганда гына үз фикереңнең дөрес, төпле булуына ирешә аласың. Без бит көндәлек тормышта бер-беребез белән аралашып, үзебезнең фикерләребезне төзәтеп, баетып торабыз. Тел, мәдәният мәсьәләсендә дә шулай булырга тиеш.

Әйтелгәннәрдән чыгып, шундый нәтиҗәгә киләсең: телибезме без, теләмибезме, татар мәдәнияте урыс мәдәнияте белән кискен көрәш хәлендә тора. Кискен көрәш дим, ләкин дошман димим. Көрәштә чыныккан аякта нык торыр, диләр. Без мәдәнияттә көрәштән башка беркая да китә алмыйбыз. Шул көрәштә мәдәни мөстәкыйльлекне булдыру безнең төп максатыбыз булып тора.

Мин, Кара диңгез флотында хезмәт итеп, 1955 елны Казанга кайттым. Ул вакытларда ук инде Казан урамнарында татар теле бик сирәк яңгырый иде. Бүген анда татар телендә аралашучы кешеләр күбрәк очрый. Ләкин күбесе сүз саен урыс сүзен кыстырып сөйләшә. Ярым урысча уйлый, ярым урысча сөйләшә башладык без. Үзебезнең милли фикерләү культурасын көннән-көн югалта барабыз. Мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында урысча белем алгач, башкача мөмкин дә була алмый. Әгәр татар баласы мәктәпне тәмамлагач, югары уку йортында ана телендә белем аласын белсә, ул туган телен яхшырак өйрәнергә атлыгып торыр иде. «Икенче сортлы» тел кемдә ихтирам уятсын? Элекке гасырларда гарәп әмирләре үзләре яулап алган шәһәрләрдән ясак итеп алтын-көмеш урынына грек философларының китапларын таләп иткәннәр. Безгә бит берни дә яуларга кирәкми. Ахыр чиктә ул әсәрләрне ана теленә тәрҗемә итеп тә була. Әмирләребез, ягъни хөрмәтле Президентыбыз һәм Премьер-министрыбыз бу байлыкны халыкка бүләк итәргә кызганмасыннар һәм бу эштә зыялыларыбызга һәртөрле булышлык күрсәтсеннәр иде. Югыйсә, хәлләребез бик мөшкел.

Былтыр Казан химия-технология университетында иҗтимагый һәм сәяси мәсьәләләр буенча фәнни конференция булып узган иде. Мин катнашкан секциядә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан бер галим чыгыш ясады. Аның, әгәр татар халкы урыс теленә җайлашудан баш тартмаса, 2050 елда милләт буларак юкка чыгачак, дигән сүзләре хәтергә кереп калган. Кабатлап әйтәм, монда урыс теленә, мәдәниятенә каршы көрәш җәелдереп җибәрү турында сүз бармый. Безгә татар телен мөмкин кадәр күбрәк өлкәдә — философиядә, техникада, сәясәттә булсын — куллана башларга кирәк. Шулай иткәндә, аның абруе бермә-бер үсәр.

Төрки халыклар киләчәктә бердәм мәдәни мәйданга керерләрме, әллә инде һәрберсе үз юлы белән китәрме? Шул мәйданда татар мәдәнияте нинди урын алыр? Төрки халыклар мәдәниятенә татар мәдәниятенең тәэсире булырмы? Бусын, кем әйтмешли, киләчәк күрсәтер. Әгәр кул кушырып йоклап утырсак, көннәрдән беркөнне безне Кызыл китапка теркәп куюлары да ихтимал. Ә хәзергә татар халкының мәдәни мөстәкыйльлеккә ирешә алсына өмет өзәргә иртәрәктер. Ник дигәндә, үзенең милләт булып кала аласына ышанмаган халык бинасыз, бюджетсыз, рәсми булмаган милли университетка атлыгып-омтылып тормас иде.

Әйе, үз хәлебезгә аек акыл белән карарга кирәк. Без урыс мәдәнияте диңгезендә йөзәбез. Шул диңгездә без — зур утрау. Ләкин ул утрау акрын-акрын гына кечерәеп, диңгез суына күмелеп бара. Сакларга, киңәйтергә, үстерергә, баетырга кирәк безгә аны.

Татар теле дөнья күләмендәге иң камил телләрнең берсе булып санала. Моны Берләшкән Милләтләр Оешмасы да, ЮНЕСКО да таный. Димәк, шундый зур абруйга ия булган телне сандыкта сүзлекләр рәвешендә саклап яту дөрес хәл түгел. Бу — җинаять белән бер.

Мөстәкыйльлегебез чамалы гына булса да, үз дәүләтебез, үз Конституциябез бар. Анда акка кара белән татар теле дәүләт теле дип язылган.

Кайбер югары уку йортларында татар бүлекләре булдырылды. Шул исәптән, мондый бүлек Казан дәүләт архитекторлар һәм төзүчеләр академиясенең төзүчеләр факультетларында да бар. Ул Вәгыйз Фәтхуллинның тырышлыгы белән инде дүрт ел дәвамында уңышлы гына эшләп килә. Ләкин әлегә ошбу бүлекләрнең мөмкинлекләре бик чикле. Чөнки урыс телендә укытыла торган югары уку йортлары каршында эшләп әллә кая китеп булмый. Татарга үз милли университетларын булдыра башларга кирәк. Алда ук әйткәнемчә, бездә мондый университет бар инде. Барлык фәннәрне дә саф татар телендә укытуга ирешү — көн тәртибендә торган иң төп мәсьәләләрнең берсе. Моңа ирешү өчен матди мөмкинлекләр бармы соң? Татарстан Республикасы чит ил галимнәре тарафыннан эшләнгән икътисади программалар өчен миллионлаган долларлар түли. Ә нигә бу эшне үз галимнәребезгә тапшырмаска? Әлеге бурычны шулай ук татар милли университеты да башкарып чыга алыр иде. Икътисади, мәдәни үсеш программаларын без үзебез дә булдыра алырлык хәлдә.

Татар халкы язмышы өчен борчылган зыялылар минем бу язмамны игътибарсыз калдырмаслар, дип уйлыйм. Әйдәгез, бергә-бергә милләтне тәрәккыят юлына бастыру юлларын эзлик. Тарих тарафыннан бүлеп бирелгән вакыт инде бетеп бара, ашыгырга, чаңсуга башларга вакыт.

Унөченче бит

Былтыргы урып-җыюлардан бирле алмаган эш хакын быел чәчүләр беткәч алу белән, Гыйльми, Казанга барып, әллә нинди гомер күрмәгән аракылар тояп кайтты да, урыста «запой» дип аталган, атналарга сузыла торган бәйрәмгә кереп китте. Хәер, бу изге эштә ул ялгызы гына түгел иде. Авылның барлык ирләре, бердәмлек күрсәтеп, Гыйльмигә иярделәр. Ләкин һәркем үзе генә, үзенчә күңел ачты.

Хатыны Хәербанәт, иренең яшереп куйган «алтын запасын» эзләп-эзләп тә таба алмагач, маймыл кыяфәте керә башлаган «сөекле» иренә кул селтәде дә, күрше авылга сеңлесенә китеп барды.

Гыйльметдин, аулактан файдаланып, «алтын запасын» өстәлгә тезде, ләззәтләнеп чираттагы шешәне ачты.

Бу «Терминатор» дигән усал чит ил шешәсенә башта шикләнебрәк караса да, бер стакан эчеп

Көлсәң — көл, көлмәсәң — ела!

Раушан ШӘРИФ

«ТЕРМИНАТОР» ГЫЙЛЬМИ

куйганнан соң, ул да үз кешегә әйләнде. Һәм Гыйльми түзмәде, йомылып бетмәгән күзләренә бәреп чыккан яшьләрен сөртте дә яңа дустына моң-зарын сөйләп китте.

— Менә син, беләсеңме? Нинди рәхәт күрдем мин бу тормышта, ә? Дәшмисең? Мин дә дәшмәдем. Иртә таңнан кара төнгә кадәр монгол аты кебек эшләдем дә эшләдем. Ничә колхоз персидәтеле генә алыштырдым мин үз гомеремдә. Их, дөнья, ычкынып та булмый, кычкырып та! — диде дә, сөялле куллары белән өстәлгә сукты.

Шулвакыт, кирәк бит: үз җаена гына эшләп утырган телевизордан ап-ак чәчле, шешенеп беткән бер адәм: «Әле тормыш тагын да авыррак булачак», — дип, тәкрарлый башламасынмы. Моны ишеткәч, Гыйльми түзмәде, өстәл өстендәге чәйнәлеп бетмәгән кипкән балык башын телевизорга бәрде, ләкин ул, сөйләүчегә тимичә, антеннага эленеп калды һәм телевизор айлар буе эзләп тә таба алмаган сигезенче каналны күрсәтә башлады. Гыйльми кинәт айнып китте, чөнки экраннан аңа «Терминатор» үзе карап тора иде. Гыйльми ачык авызын ябып, тәкерегән йотарга да өлгермәде, телевизор эчендә атыш, сугыш башланды.

— Ну, малай, көчле икән бу «Терминатор», — диде Гыйльми, дәртләнеп. — Бер сугуда биш-алты кешене екты да салды!

Ул үзенең дә өстәл аягы кебек нечкә беләкләренә бетмәс-төкәнмәс көч-куәт кергәнен тойды.

— Тагын да начаррак була, имеш, — диде ул, борын тишегән колхозның иткә тапшырып өлгермәгән яшь нәсел үгезенеке кебек киңәйтеп. — Юк, булдырмабыз!

Гыйльми «Терминатор» шешәсен бугазыннан эләктереп алды да, аракысын авызына койды. Шул чак телевизор эчендәге көчле шартлаудан антеннага эленгән балык башы егылып төште һәм «Терминатор» юкка чыкты.

— Их, коралын сорыйсы калган икән, — дип әзгәләнде Гыйльми. — Ярый, без дә төшеп калганнардан түгел. Корал бездә дә бар, һич булмаса, халык ярдәм итәр.

Шул сүзләр белән ул, ишекне тәрәзә пыялалары ыңгырашырлык итеп япты да, өеннән чыгып китте.

Иртәнге сәгать дүрттә, сугыш алдыннан гына була торган төнге тынлыкны бозып, бөтен йоклаган авыл этләрен дәррәү кузгатып «ДТ-75» тракторы кабынды. Ул, авыл урамнарын изеп, колхоз идарәсенә юл алды. Трактор, кара төтеннәр чыгарып, ажгырып килгән тизлеген киметмичә, идарә ишегеннән кереп китте дә, «приемный»да секретарь-машинистка өстәле янында туктап калды. Шар итеп кабина ишеге ачылды, аннан башына мотоцикл шлемы кигән, кулына урак белән чүкеч тоткан Гыйльми сикереп төште. Ул, ышанычлы адымнар белән атлап, колхоз рәисенең бүлмә ишеген тибеп ачты да эчкә узды. Өстәлдәге бөтен әйберләрне бер селтәүдә идәнгә коеп төшерде. Стенага «Жириновский» аракысының этикеткасын беркетте. Аннары, үзенең тәвәккәллегенә канәгать елмаеп, «пред» кәнәфиенә чумды. Озак көтәргә туры килмәде. Ишектән, гөләфи чалбарының төймәләрен каптырырга да онытып, яланаякка уникеле галош өстерәгән, өстенә хатынының зәңгәр погонлы кофтасын кигән, кулына малаеның борчак ата торган алтатарын тоткан, эчә-эчә анархист кыяфәтенә кергән, эшеннән куылган, милиция Мәснәви килеп керде.

Ул, аякларын «пред» өстәленә куеп әмрикәннәрчә утырган Гыйльмине күргәч, очкылык тотып артка чигенде. Кабул итү бүлмәсендә торган тракторга бәрелгәч кенә туктап калды.

— Гыйльми, ты че?.. — диде ул урысчалап (эчеп алгач урысча сөйләшә торган гадәте бар иде).

— Сам ты че! — диде Гыйльми, тәш арасыннан черт итеп төкереп. — Сез капитулировать итәргә һәм халыкка чын йөзегезне ачарга тиеш! Чөнки мин сезнең мафиягезнең оясын тар-мар иттем. Власть минеке.

Мәснәвинең очкылык тотуы туктады. Тик шунда ук, сул җилкәсе тартышып, уң аягын көзән җыера башлады. Ул, әйләнчек сарык кебек, башын бер болгап алды да, мәгънәсез күзләрен Гыйльмигә текәде.

— Хәзер мафияңне күрсәтәм мин сиңа! Вставай, хәчтерүш, син арестован! — дип кычкырды.

Ләкин Гыйльмине тавыш белән генә куркытып булмый иде инде. Чөнки «Терминатор» аракысы аны бөек эшләргә өндәп, дәртләндереп тора иде. Ул «пред» өстәленә мәче тизлеге белән сикереп менде дә, аякларын аерып басты. Бу минутта Гыйльми коеп куйган Шварцнеггер иде, бары тик ике-өч башка үсәсе генә бар... Ул, телевизордагы тыншык борынлы тәрҗемәченең тавышына охшатып каты итеп сүгенде дә, кулындагы чүкечне, граната аткандай, Мәснәвигә бәрде. Тегесе, читкә тайпылып, идәнгә ятты. Чүкеч, ишектән очып чыгып, «приемный»да торган трактор тәрәзәсе аша утыргычка кунаклады.

Мәснәви атып җибәрде. Борчак Гыйльминең ачык авызына кереп китте. Ул ютәлли башлады. Мәснәви, форсаттан файдаланып, штурмга ташланмакчы булып, идәннән күтәрелде. Гыйльми урагын баш өстенә күтәрде.

— Тагын бер адым!.. Мин үземә «хәрәкири» ясыйм! — диде дә, урагын корсагына терәде. Мәснәви, урактан куркып түгел, колагына ят сүз килеп бәрелүдән туктап калды. Урамда, идарә янына җыелган халык шаулашып алды һәм бүлмәдә, Былтыр каршысына чыккан Шүрәледәй, колхоз рәисе Гомәр пәйда булды. Монысы да кыяфәте белән Мәснәвидән ерак китмәгән. Тик ак майкасы өстеннән тутый кош төсендәге ялтыравыклы галстугын тагарга онытмаган иде. Ул, Гыйльмине күрү белән, болай да зур күзләрен тагын да шарландырып, трактор пускачы кебек кабынды:

— Син нәрсә, мать якаңны, төрмәдә черисең киләме?! — дип үкерде. — Мин сиңа устрою, хәшәрәт! — Аннары йөгереп барып, Гыйльминең урагын тартып алды.

«Әһә, бу аракыны бутап эчкән, саграк булырга кирәк», — дип уйлады Гыйльми.

Шул вакыт, сигнал кычкыртып, идарә алдына район милициясе начальнигы Җамали килеп туктады. Ул да Гыйльми салган киң юлдан аяк астындагы пыяла ватыкларын шыгырдатып эчкә узды. Бер сүзсез, тәрәзә төбендә торган графиндагы суны тимер тешләренә бәрә-бәрә пыяла стаканнан хрусталь тавышлары чыгарып эчеп куйды да, махмырдан бөгәрләнеп беткән битенә тир бәреп чыккач кына телгә килде:

— Нәрсә булды? Нишлисез?

Айный башлаган Гыйльми революция ясый алмаячагын аңлап алды. «Халык күтәрелмәде, димәк, әзер түгел, изелеп яшәү күбрәк ошый, күрәсең», — дип уйлады ул. Тик болай гына бирешәсе килмәде.

— Булмады, — диде ул. — Менә болар, төн уртасында минем өемә килеп керделәр дә, Мәснәви күкрәгемә алтатарын терәде, ә Гомәр, урагын бугазыма куйды. «Әйдә, кабыз тизрәк тракторыңны!» — диләр. Икесе дә калтырыйлар. Билгеле, мин гади тракторчы, Аллаһы Тәгалә буй да бирмәгән. Закон кешеләренә каршы килә алмадым.

Гомәр белән Мәснәви, күзләрен кысланыкы кебек акайтып, авызларын ярга дулкын бәргән балык кебек кыймылдата башладылар. Ә Гыйльми дәвам итте:

— Мин, әлбәттә, кабыздым, бөтен авыл шаһит, барысы да ишеттеләр. «Әйдә, хәзер «Белый дом»ны алырга барабыз», диләр. Мин әйтәм: «Ник, бер алдылар бит инде...» — дим. Шунда Мәснәви кабыргама алтатары белән төртте дә алга барырга кушты.

— Ә ни өчен монда кердегез, — диде Җамали, бер илле грамм булмаса, ычкынасын сизеп.

— Председатель ачкычларын югалткан, ә аның ак сейфында аракы бар икән. Шуны трактор белән эттереп алмакчы булганнар.

Җамалиның йөзе үтүкләнеп, күзләренә шул үтүк җылысы йөгерде.

— Аңлашылды! — диде ул, тамак кырып. Аннан соң Гомәргә таба борылды: — Белый домыгызның кирәге юк! Тизрәк сейфыңны ач!

Гомәрнең авызыннан төрле авазлар чыкты, тик ул җөмләсен җыеп әйтә алмады. Аның да хәле начарлана башлаган иде. Җамали аңа кул селтәде дә, тәрәзәдән:

— Хәйдәров! — дип кычкырды.

Ишектән таза гына, әллә урманда туып үскән, әмма үзе кешегә охшаган милиция киеменнән кап-кара бер кеше килеп керде.

— Синең специальность! — диде Җамали, сейфка ишарә ясап.

Тегесе кесәсеннән кәкре тимер чыгарды да, Гыйльми өстәлдән төшкәнче, сейфны ачып та уйды. Ан-
Гыйльми белән Җамали сейф эченә иелделәр.
да, ак башларын горур тотып, озын муенлы берничә «Столичная» басып тора иде.

— Менә сиңа «Белый дом», — диде Җамали, телен шартлатып.

Ул Гыйльмигә күзенең агы белән карап алды да, тораташ булып катып калган Гомәр белән Мәснәвигә төкерекләрен чәчеп җикерде:

— Сволочи!

Тегеләрнең хәлләре болай да мөшкел иде, аларга шул җитә калды. Мәснәви һуштан язып егылды, ә Гомәрнең галстугындагы тутый кошы талпынып куйды. Җамали «әйе» дип баш кагып торган Гыйльмине бүлмәдән төрткәләп, артына тибеп чыгарды да, ишекне эчтән бикләде.

— Сез нәрсә, мин монда үләргә йөрим, ә сез... Нәрсә терәлеп каттың, сал тизрәк, — диде ул Гомәрнең очып китә алмаган тутый кошына ябышып. «Сал» сүзе ишетү белән, Мәснәви дә сикереп торды. Барысы да өстәл янына җыелдылар.

Ә идарәдән чыккан Гыйльмине авылдашлары күтәреп диярлек каршы алды. Тик хатын-кызларда гына була торган сизгерлек белән, нәрсәдер буласын аңлап, сеңелесеннән кайтып җиткән Хәербанәт кенә бөтен тантананың ямен бозды. Ирен сөйрәп алды да җиргә лып итеп утыртты:

— Нәрсә?! Нәрсә булды тагын, ир имгәге? Нинди аракы эчтең бүген? И Алла, нигә генә чыгаралар шул чит ил аракысын?! Үзебезнекен генә эчкәндә бу тиклем кайгы-хәсрәт юк иде. Ә хәзер нәрсә? Әнә бит, курчак Фәһимәсенең Сәлимҗаны, «Петр Первый» аракысын эчкән дә, бакча артларындагы үрдәк күленә казык кагып чыккан, «Яңа шәһәр салам. Кораблар йөздерәм. Аурупага тәрәз ачам», дип әйтеп әйтә ди. Чабата-Ибрай «Жириновский»ны эчеп, сыерларын, сарыкларын көтүдән алып калган да: «Никакой көтү сезгә, барыгызны да Монголиягә куам», — дип тамак җырта ди... Ә бүре Сәгыйть нишләгән? «Зверь» дигән аракыны бушатканнан соң эте белән сугышкан. Этләренә дә, Сәгыйтенә дә карарлык түгел. Ә син нәрсә кыланасың? Менә бу нәрсә? — диде дә Гыйльминең борын төбенә бушаган «Терминатор» шешәсен төртте.

— Күреп торасың ич! — диде Гыйльми, идарә ягына ымлап. Хәербанәт трактор кереп киткән зур гына тишекне күрмәгән иде әле. Шуңадыр, Гомәр белән Мәснәви хәлендә катып калды. Бераз торганнан соң, үз акылына кайтып, күргәннәренә төшенеп бетмичә:

— Тракторың кайда соң? — дип сорады.

— Приемныйда!

— Кайда?

— «Пред»ка керергә приемныйда тора...

Нәкъ шул вакытта, Гыйльминең сүзләрен җөпләп, идарә эчендә гөрләп трактор кабынды. Хәербанәт, башына таш төшкәндәй, чайкалып китте. Җамалиның «По машинам!» дигән тавышы ватылып бетмәгән пыялаларны коеп төшерде.

Трактор идарә эченнән рульдәге Гомәрне, Ленин башлы кызыл байрак тоткан Мәснәвине һәм кайчандыр социалистик ярышта җиңеп алынган көмеш вазаны тоткан Җамалины алып чыкты да, 190 градуска борылып, олы юлга карап басты. Милиция начальнигы салган аракысын эчеп куйды да, бушаган шешәсен җиргә бәреп:

— Алга! — дип әмер бирде.

Трактор, җыелган халыкны аралап, милиция машинасы артыннан авылдан чыгып, олы юлга юнәлде. «Әһә, Мәскәүне алырга киттеләр», — дип уйлады Гыйльми җирдә аунап яткан буш «Столичная» шешәсенә тибеп. — Тракторны гына харап итмәсәләр ярар иде. Мәскәве чурт с ним... Мәскәүсез яшәп була ул, ә менә тракторсыз яшәп кара». Гыйльми, күргәннәренә ышанырга да, ышанмаска да белмичә торган Хәербанәтен җитәкләп, кайчандыр җыр-гармун тавышлары гөрләп торган, хәзер җансыз, фәкыйрь тынлык белән тулган авыл урамнары буйлап өенә таба атлады.



I бүлек





Хөкем инде икенче атна бара. Гаепләнүче Тансык Муллаяровны залга һәркөн куллары богаулы хәлдә алып керәләр. Залның тәрәзәдән читтә, ышыграк почмагында, әлеге процесс өчен махсус корган тимер читлек. Гаепләнүчене, суд башланырга ярты сәгатьләр кала, һәркөн шунда китереп ябалар, Читлекнең ике ягында ике сакчы. Карабаш Төзүчеләр клубының халык белән шыгрым тулы залының рәт араларында да күкрәкләренә өр-яңа автоматларын кыскан солдатлар йөреп торалар. Әмма алай да таманга гына әле. Мондагы халык тау башында пыскыган учак төсле. Әз генә җил исеп китсә дә, дөрләп кабынып китәргә әзер. Тамаша залы атырга җыенган Везувий вулканы төсле гөжли. Муллаяровны иртән бирегә, хөкемчеләр каршына китергән чакта, залдагылар аңа:

— Хәшәрәт!

— Мәлгунь җан!

— Бәдсүрәт, бәд буй!

— Күптән җир убасы нәрсә! Тьфу!

— Соңгы минутларыңны сулыйсың, олтырак бит! — дип кычкырып. артыннан лач итеп төкереп калалар.

Хөкем залының әле теге, әле бу башыннан:

— Бу суд кешеләренең башка эшләре беткән, ахры. Нигә инде юк белән баш катырып утыралар, валлаһи. Бу хәшәрәтнең җинаяте күз алдында. Ничу монда өч тарыдан боламык тугларга. Тотсыннар да үзебезгә генә бирсеннәр. Без ул җир битнең биш минут эчендә әгъзасын әгъзага аерып, этләргә ташлыйбыз! — дип кычкырып утыручылар да бар. Әлеге процесста шаһит буларак катнашучы, Бөгелмәдә «Ашыгыч ярдәм» машинасы шоферы Әлмәндәр Тудияровка баш судья Бакый Агишев кисәтү артыннан кисәтү ясап кына тора. Әлмәндәр исә мено бүген дә, урыннан сикереп торып:

— Аблакатларым коткарыр дип көтмә, хайван! Бу юлы элмәктән котылу юк сиңа! Суза тор дуңгыз муеныңны, өр-яңа сүстән үргән галстук әзер аңа! Бу юлы үзем салам синең муеныңа ул сүс галстукны! — дип кычкырып калды.

Судта рәислек итүче, ап-ак чәчле, үз яшенә караганда ашыкмый гына калынаеп баручы агай, хөкемдар Бакый Агишев үз гомерендә мондый хәлләрне байтак күргән кеше. Залдан шулай кычкыргалап утыручыларга да аның әллә ни исе китми. Карабаш эшчеләр посслогының кунакханәсе бирсдә туктаучылар өчен әллә ни уңай булмаса да, ул бүген яхшы йоклады. Иртән биштә үк торып, Казанга шалтыратты, өй, гаилә хәлләрен белеште. Кызы Гөлназ гландасын алдырган. Операция уңышлы узган, Гөлназны шифаханәдән бүген-иртәгә чыгарачаклар. Ә улы Госман, бар куәтен биреп, диссертациясен тәмамлап килә. Госман урысчалатып кына:

— Папа, я уже вышел на финишную прямую. Диссертация почти готова. Определили день защиты. Постарайся хоть на банкет успеть, — диде.

Агишев чиста күлмәктән, яңа галстук таккан. Башта ул, һәркайсына аерым-аерым кул биреп, әлеге процесста катнашучы судьялар белән күрешеп чыкты. Алар бирсдә алтау. Баш гаепләүче, прокурор Илһам Сәмигуллин, гаепләнүче Муллаяровны якларга алынган Мәскәү адвокаты Абраам Давидсон белән баш кагып сәламләште.

Баш хокемдар Бакый Агишев, аерата ихтирамын сиздереп, кече тикшерүче Фикрәт Чинкин һәм аеруча куркыныч җинаятьләр буенча республика өлкән тикшерүчесе Александр Бачковский белән килеп күреште.

Тимер читлек эчендә алтын тешләрен ырҗайтып утырган Тансык Муллаяров хатыны Валентина Крот-Муллаярованы үтерүдә гаепләнә. Бу инде өченче суд. Алдагы икесеннән Тансык Муллаяров җиңел генә котылып аклана килде. Башта Муллаяров эшен Фикрәт Чинкин алып барган иде. Материалларны судка да ул әзерләде. Тәҗрибәсе җитеп бетмәү дә булгандыр инде. Эше дә бик катлаулы. Тегечакны Чинкин оттырды бу процессны. Мәрхүмә Валентинаның әтисе гвардия танкисты Андрей Силаевич Крот эшне яңадән кузгатты, кияве Тансык Муллаяровны яңадан судка бирде.

— Мин бердәнбер кызымны үзенә-үзе кул күтәрә торган итеп үстермәдем. Яңадан тикшерү алып барыгыз, кызымны кабереннән казып алыгыз, яраларын яңадан тикшерегез! — дип кенә бара. Судның икенчесе Казанда булды.

— Валя үзенә үзе атты, аның фаҗигале үлемендә минем мыскал да гөнаһым юк, — дип, Тансык Муллаяров бу юлы да судан коры чыкты. Гәрчә икенче судка эшне өлкән тикшерүче, отставкадагы авиация майоры Александр Яковлевич Бачковский әзерләсә дә.

Бу өченче суд Фикрәт Чинкинның һәм Александр Бачковскийның гаризасы буенча кузгатылды. Монда эш мундир намусы турында гына бармый. Валентина Крот-Муллаярованың мәрхүмә булуына инде алты ел узды, күп сулар акты. Тансык Муллаяровны бу судка унбиш елга хөкем ителгән җиреннән, төрмәдән алып киләләр. Чөнки ул янә өйләнеп, тагын бер хатынын атып үтерергә өлгерде. Анысыннан алай җиңел котыла алмады. Суд аны атарга дип хөкем чыгарган иде. РСФСР Верховный Суды үлем җәзасын унбиш ел белән алыштырды. Валентина Крот-Муллаярова эше буенча гаепләнүче Тансык Муллаяровны әлеге процесска Түбән Кама төрмәсеннән китерәләр.

Эше муеннан булса да, шул атнасында ук архивка китәргә тиешле «Муллаяров эше»н һаман өстәлендә тотты Чинкин. Аның турында яңадан-яңа материаллар тупларга тырышты. Интуициясе мәҗбүр иттеме — Тансыкның армиядә хезмәт үткән частена хат язды. Муллаяров ракета частьләрендә хезмәт иткән. Бу часть ул чакта Белоруссия урманнарында торган. Дус-дошман күзеннән нык яшерелгән часть була. Хәзер ул каядыр Себергә күчерелгән, командирлары да алмашынган. «Сезне кызыксындырган шәхес турында мәгълүматларны Мәскәүдән Стратегик гаскәрләр баш штабының кадрлар бүлегеннән ала аласыз», дигән хат килде әлеге часть командирыннан. «Кажется, ул егет белән ниндидер бер шөбһәле вакыйга булды», дип тә өстәгән иде сәргаскәр. Подполковник мондый юлларны бер дә юкка гына өстәмәс.

Үз хисабына бер атнага ял алып, Фикрәт Мәскәүгә очты. Әнисә хакына, зәп-зәңгәр күзле, озын калын толымлы, соры чәчле Әнисә, беренче мәхәббәте хакына Чинкин айга, галәм түрләренә очарга әзер иде. Аның садист кулыннан һәлак булуына тик Фикрәт кенә гаепле. Әйе, ул үзен гаепле саный. Теге чакны ул, адвокатлар бәйләнерлек мыскал да урын калдырмый тикшерү алып барса, кан эчәргә күнеккән хәшәрәтне таш капчыкка яптыруга ирешсә, бичара, беркатлы Әнисә аның тозагына эләкмәгән булыр иде. Һәрхәлдә, бүген исән булыр иде...

Стратегик гаскәрләр баш штабының кадрлар бүлегендә утырган подполковник та әллә ни яңалык өсти алмады.

— Без кадровый офицерларга гына шәхси «дело»лар алып барабыз. Ә рядовой состав демобилизация срогын тутыра да кайтып китә. Ничек кенә ярдәм итәргә соң сезгә? — дип, подполковник ихлас күңелдән уңайсызланды. Аннары гына:

— Әһә! Тагын бер мөмкинлек бар. Мәскәүнең үзендә үк шул частьтә хезмәт иткән ике егет яши.Без аларны белемнәрен күтәрергә дәшкән идек төсле. Шуңа истә калганнар, — дип, подполковник икенче картотека тартмасын ачты. — Дөрес, берсе Ковальчук Николай, Волоколамскида яши. 37 нче автоколоннада шофер. Икенчесе — Митяев Павел. ВДНХ ягында тора. Макарон фабрикасында баш энергетик.

— Барам, үзләрен күрәм, — диде Фикрәт.

Чинкин әлеге подполковникка нинди уңай белән бу сәфәргә чыгуын сөйләгән иде инде.

— Бер тиенлек кенә файдасы тисә дә, мин шатмын, — дип озатып калды аны кабинет хуҗасы.

Макарон фабрикасының баш энергетигы Павел Митяевны Чинкин цехта очратты. Тансыкның фотосын күрсәтү белән:

— Это же подонок, каких свет не видел! — булды аның беренче сүзе.

Волоколамск шәһәрендә яшәүче Николай Ковальчук сәфәрдә иде. Фикрәт аның кайтканын фатирына барып көтеп утырды.

— Разве он еще жив? Матушка-земля все еще его терпит? — дип сорады Николай, Тансыкның исемен атау белән...

Бөтен барлыклары биш цифр эченә сыеп беткән, бик тә яшерен баллистик ракета гарнизоны куе урман эченә урнашкан. Әйләнә-тирәдә алтмыш-җитмеш чакрымнарга бернинди шәһәр-поселоклар юк. Утыз кешедән артмаган гарнизон солдатларына беркая барырга да рөхсәт кәгазьләре бирелми. Гарнизон урнашкан аланнан өч чакрымнар гына ераклыкта нибары илле-алтмыш йорттан артмаган белорус авылы бар. Шул авылдан гарнизонга сөт, ит, яшелчә китерәләр. Берничә кыз хуҗалык блогында эшләп йөри. Гарнизон каршында гына солдат итеге таптап тап-такыр иткән түгәрәк мәйданчык бар. Кичләрен нарядтан буш солдатларга шул түгәрәккә чыгып гармун тартырга рөхсәт ителә. Гармун, баян тавышына авылдан кызлар менәләр, җырлашалар, биешәләр, танышып китәләр. Тансык та бер кыз белән таныша. Очраша башлыйлар. Баллистик ракета гарнизоннан ике йөз метрлар чамасы читтә. Гарнизон солдатлары аны чиратлашып нарядка йөреп саклыйлар. Тансык та йөргән кызы Олесяны нарядка чыккан кичләрендә, чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган ракета кырына дәшә булган. Монда аларга кем дә комачауламый, мәхәббәткә тулысы белән бирелергә була: сөйгәнеңне кулың туйганчы иркәлә, иренең күпкәнче үп.

Солдат Муллаяров кына түгел, сөйгән кызлары белән башка егетләр дә шулай күрешәләр. Югыйсә, өч ел буена беркая чыкмый, беркем белән аралашмыйча, акылыңнан шашарсың. Бу гаять яшерен гарнизонда хезмәт итүчеләрне өч ел буена өйләренә ялга да җибәрмиләр. Ярамый. Ә солдат кайда да җаен таба тормышның. Солдатларның баллистик ракета кырында очрашып мәхәббәт куертуы турында беркем белми. Хәтта солдатлар үзләре дә берсен берсе күрмәмешкә салышалар. Чөнки объект бик яшерен. Андый-мондый хәл була кал-

са, тикшерә башласалар, башыңа Себер төрендә урын табылмас. Иң яхшысы — белмәү, бер-береңне күрмәү.

Солдат йоклый, хезмәте бара тора, дигәндәй, ул арада хәрби вазифа срогы узып та китә. Солдатларның «дембель» көтәр көннәре якынлаша. Олесяның күренеп кенә корсагы үсеп килә. Тансыкка нишләргә? Уңганнар солдаттан орден-медаль тагып кайта. Ә Тансык корсагы иягенә җиткән хатын белән кайтып керә алмый бит инде. Әнисе Әбү-Нәгыймә акылдан шашар, уклау белән куар. Бу йөктән, аркада калыккан бөкредән котылырга кирәк егеткә. Ә ничек? Бик гади. Олесяны үзе нарядка чыгасы кичне күрешергә чакыра ул. Көзге караңгы төн. Мондый күренешләргә Тансык кына түгел, Олеся да качып-посып, әти-әниләреннән яшертен генә килә торган була. Бу юлы да ул, төнге караңгылык белән дә хисаплашмыйча, сөйгәне янына ашыга. Карынында бәбәй үсеп килә. Ничә тапкыр дерт-дерт итеп тибеп куйганын да сизде. Ә җан сөйгәненең инде хезмәт срогы да тулып килә.

— Бер дә кайгырма, күгәрченем. Дембель җитү белән мин сине үзебезгә алып кайтып китәм, — дип иркәли аны сөйгәне. Менә бүген дә ул аның кочагына ашыга. Төн карангылыгы аны өркетми, кыю килә. Белгән. Күп тапкырлар ярган сукмагы. Төн караңгылыгында:

— Стой! Кто идет? — дигән тавыш яңгырады.

— Тансык! Милый, это я! — дип җавап биреп өлгергәнче, ике тапкыр ату яңгырый. Ана булырга өлгермәгән унтугыз яшьлек хатын «эһ!» дип әйтергә дә өлгермичә җан бирә.

Мәскәүдәге махсус штабка гына буйсынган иң яшерен хәрби объектларның берсендә мондый хәлнең килеп чыгуы командирларны нык борчуга сала. Бу ЧП турында Мәскәү белсә, беттем, диген. Ә Тансык, мин ул кызмы-хатынмы белмим, Устав буенча эш иттем, дип бара. «Стой, кто идет?» — дип сорадым да, җавап бирүче булмагач, аттым, янәсе. Кем булуын, нинди максат белән килүен тикшерегез, анысы инде сезнең эш.

Тансыкны Минск шәһәренә хәрби прокуратурага алып китәләр. Ул анда да шул ук сүзне кабатлый. Әйе шул тикле яшерен объектка Америка шпионкасы да килеп чыгарга мөмкин. Иң яхшысы, бик зурга җибәрмичә, бу эшне вакытында ябу. Хәрби прокуратура тикшерүчеләре дә шул юнәлешне алалар. Ә солдат Муллаяровның инде өйгә кайтыр көннәре дә җиткән. Әйе, ул Уставта кушылганча эш иткән — сүзендә нык тора. Аны тоткарлаудан файда юк. Иң яхшысы күздән югалсын.

Тансык белән бер гарнизонда хезмәт иткән Павел Митяев та, Николай Ковальчук та:

— Ул сволочь гарнизонга бүтән кайтмады. Аны дембельгә тикшергән җирдән җибәрделәр. Юкса, без аны алай җиңел генә котылдырмый идек. Кирәген алып китә иде, — дип сөйләделәр.

II бүлек

Фикрәт Чинкин да, Александр Бачковский да судка тагын беркат тәҗрибә, гыйбрәт алу өчен йөриләр. Прокурор Тансыкны алар туплап биргән материаллар нигезендә гаепләячәк. Рәис хөкемдар Бакый Агишев алар белән гадәтенчә кул биреп күреште.

— Дулкынлана торгансыздыр инде, — диде ул, тикшерүчеләрнең икесенә дә сигарет тәкъдим итеп. — Сез эшләп биргән Гаепләү нәтиҗәсен тагын бер карап чыктым. Болай ныклы аргументларга корылган төсле. Бу юлы бу хәшәрәт Муллаяров гадел хөкемнән котыла алмас төсле.

— Гаепләү нәтиҗәсен фактларга нигезләп кенә эш бетми, — дип куйды Александр Бачковский.

— Дәүләт тарафыннан гаепләүче үзен ничек күрсәтер. Без тырышу белән генә түгел бит, — дип өстәде Чинкин да. Шушында ук торган прокурор Илһам Сәмигуллин:

— Эшне бүген төнлә тагын бер карап чыктым, тикшерү яхшы эшләнгән. Гаепләнүчене стенага тери торган фактлар Каф тавы биеклеге. Белмим, адвокат Абраам Давидсон аларга кизәнә алырмы икән? Һәрхәлдә, Тансык Муллаяровны хатыны Валентина Крот-Муллаярованы атып үтерүдә җиң сызганып гаепли башларга мин ярсу аттай атылып торам.

Бит араларына ал, кызыл, зәңгәр, сары төстәге кәгазь кисәкләре кыстырган калын-калын томнарны тоткан судьялар берәм-берәм өстәл артына утырыштылар. Бу араларда алар да төп тәртәгә җигелеп тарталар. Кичке дүртләрдә суд утырышлары тәмамлану белән генә эш бетми. Судьялар әлеге буталчык эш буенча калын-калын томнарга әверелгән гаепләү документларын, экспертиза, махсус тикшерү нәтиҗәләрен кунакханәдәге номерларына да алып кайталар. Процесс материалларын өйрәнү анда да дәвам итә.

Барысы да утырышып беткәч, баш хөкемдар Агишев торып басты. Галстугын төзәтте. Кулындагы калын кызыл карандашы белән өстәлгә әле яңа гына куелган сулы графинга суккалап, залдагы халыкны, чакырылган шаһитларны тынычланырга чакырды.

Ике атнадан артык дәвам иткән әлеге процесста, судьялар күп санлы шаһитларны тыңлап, гаепләнүче Тансык Муллаяровтан сорау алып, 198... елның җәйге кичендә булган коточкыч җинаятьнең картинасын ачыкладылар төсле. Гаепләнүче Муллаяровны дәүләт исеменнән гаепләргә җыенучы Сәмигуллинның да сүз алыр минутлары якынлаша.

Судта тыңланган хәлләрдән залда утыручыларның хис-кичерешләре ташып чыгарлык булып күпергән. Вулкан авазы гөжли, менә-менә ата башларга әзер. Читлек эчендә, богаудан бушаган беләзекләрен язгалап, башын әле аска иеп, әле кемнедер эзләгәндәй залга төбәп утырган Тансык Муллаяровка йодрык күрсәтәләр, янау сүзләре яудыралар. Солдатлар тыеп тормаса, урыннарыннан яу булып кубып, читлеккә ташланырга күп сорамаслар иде.

Менә шуларны истә тотып та судны җинаять булган җирдә, Бөгелмәдә түгел, ә Карабашта уздыралар. Халыкның күтәрелүеннән куркып. Чөнки, ялгышамы, ялгышмыймы, халыкның анда эше юк, ул үзенчә фикер йөртә. Җитмәсә, бик сирәк ялгыша. Ә монда мәсьәлә көн кебек ачык. Вәхшиләрне чиркандырырлык җинаять эшләнгән. Мәк чәчәгедәй саф, әле яшәргә дә, яшәргә генә җыенган, итәк тутырып балалар үстерү турында хыялланган, нибары егерме ике яшь белән барган хатынның гомере бүген читлек эчендә утырып торган кансыз җәллад тарафыннан өзелгән. Ә ул һаман котылып кала килә. Ха! Бер дә харап икән. Икенче хатыны Әнисәне үтергән өчен унбиш ел биргәннәр икән, имеш. Биш ел да узмас, тагын чыгып җитәр, комсыз карчыга булып, янәдән бәбкәләр чүпли башлар.

Җаннарын чын нәфрәт телгәләгән халык судның төгәлләнүен, аның хөкем чыгарганын да көтеп утырырга теләми. Аларның исәбе, само-

суд ясап, Тансыкны үз куллары белән өзгәләп ташларга. Андый омтылышны берничә тапкыр ясап карадылар. Әле үткән атнаны гына кичке якта, милиция идарәсе каршына Бөгелмәнең ярты халкы җыйналды. Тансык Муллаяровның Түбән Кама төрмәсеннән монда китерелүен каян белгәннәрдер?! «Үзебез суд ясыйбыз, сезгә эш калдырмыйбыз», диләр. Милиция начальнигы полковник Колсанов халыкны ике сәгать үгетләде. Суд хөкем чыгармый торып, берәүнең дә җинаятьче икәнен ачыклап булмый, бу үзе җинаять, дип аңлатырга тырышты.

— Беләбез судьяларыгызның да кем икәнен! Кем күбрәк төртсә, шул хаклы! Сезнең кулдагы мәлгуньнең атасы автохуҗалык директоры, кулында миллионнарны уйната! Ышанмыйбыз судка! Кан эчүче адәм актыгы бу юлы да судан коры чыгачак! — дип кычкыручылар да булды. Әйе, полковник Колсанов та кысып хәл-

дә. Тансык Муллаяровны суд залына бер-берсенә охшаш өч уазикның берсендә китерәләр, көчле наряд сагы астына алынган тоткынның кайсы машинада булуын конвой начальнигы гына белә. Алып кайтканда да шулай. Төзүчеләр клубындагы биш ишекнең әле берсеннән, әле икенчесеннән чыгаралар. Милиция начальнигы халыкның дәррәү ябырылып, алар кулындагы тоткынны талап алуларыннан курка. Тоткынны судка китергәндә дә, кичтән алып киткәндә дә урам маршрутлары үзгәртелә. Халыкның көтмәгәндә урам чатында конвойга һөҗүм итүеннән шикләнә Колсанов. Ул чакта, матур гына зур пенсия белән пенсиягә җыенганда, полковник погоннары иң башыннан очты дип сана. Шуларны истә тотып, судны Бөгелмәдән кырык чакрымнар ераклыктагы Карабаш эшчеләр поселогында уздырырга булдылар.

Бу юлы судка мәрхүмәнең якын туганнары һәм хөкемне алып бару өчен иң кирәкле дип табылган шаһитләр генә дәшелгән иде. Әмма өч йөзләп кеше сыешлы тамаша залында алма төшәрлек тә урын юк. Клуб каршындагы мәйданга Бөгелмәдән һәркөн диярлек ун-унбиш автобус килеп туктый.

Нәфрәте тау ташкыны булып ярсыган халыкны сулы графинга карандаш белән суккалап кына тынычландырып булмый шул. Әмма баш судья Бакый Агишевның мондый очракларда куллана торган ышанычлы алымы бар. Менә ул кулына микрофон алды. Бераз карлыкканрак тавыш белән, әмма аңлаешлы итеп:

— Әгәр тиз арада тынлык урнашмаса, залдагы халык чыгартылачак. Хөкемне ябык ишекләр артында дәвам итәчәкбез, — диде.

Давыл басылгандай, зал тынычлана төште. Әмма әле барыбер, кайсыдыр озаклап йөткереп, кайсы кулындагы ачкычын, зонтигын идәнгә төшереп, кыбырсынып, тыеп тора алмастай ярсуларын, нәфрәт хисләрен судьяларга үзләренчә җиткереп тордылар.

Суд ул халык җыены түгел. Хакимнәр, хис-кичерешләрне аңлаган хәлдә дә, төгәен дәлилләр, кат-кат төшерелгән, экспертизалар белән расланган фактларга таянып эш итәргә тиеш. Бер якта гаепләүче, икенче якта яклаучы. Гаепләнүче — уртада. Ә судьялар ике якны да тыңлап, тикшерүчеләр туплаган факт һәм дәлилләрне бизмәнгә салалар. Гаепләү көчле булганда, суд залына үз ирегендә килүчене хөкемгә тартып, конвой кулына тапшыралар. Яклаучы көчле булганда исә, суд залына конвой сагы астында китерелгән гаепләнүче, акланып, залдан ук үз ирегенә җибәрелә. Мондый очраклар еш булып тора. Теге чакны, Актүбә эшчеләр поселогында узган беренче суд процессы залыннан Чинкин, гарьлегеннән, үзе атылырдай булып чыкты. Тикшерүче бөтен көчен, аң-белемен туплап алып барган иде югыйсә. Тәҗрибәсе җитмәде, ахры. Ул чакны Фикрәт Чинкин гаепләнүче Тансык Муллаяровның җинаятен судьялар, аларның утырышчылары ышанырлык итеп исбат итә алмады шул. Муллаяров суд залыннан Чинкинга мыскыллы караш ташлап, авыз кырые белән көлеп чыгып китте.

Алары әле бер хәл. Тикшерүче башы андый гына түбәнчелекләрне кичерә инде ул. Шуннан ике ел да узмады, бу вампир Әнисәне, Чинкинның аңлаша алмаган мәхәббәтен, кыскасы, өзелеп сөйгән фәрештәсен үтерде. Дүрт яшьлек кызын гомергә ятим итте...

Дөнья дигәнең, сәер бит ул. Бер карасаң гаҗәпкә калырсың: без яшәгән мохит баш җитмәслек капма-каршылыклардан тора. Тимер читлек эчендә кыргый җанвар кебек утырган Муллаяровның үлемен дәррәү теләгән залда, аны кочагына алырга әзер бер сәер җан да бар иде. Бу ханым иң арткы рәткә баскан да, урындык өстенә басып, читлек эчендә утырган «мәхәббәт ташына» үбүне аңлаткан ишарәләр җибәрә. «Кадерлем! Мин синең белән! Борчылма! Барысы да без дигәнчә булыр!» Рәйсә Тимеркәева ишарәләвe бу. Нефть техникумының химия укытучысы. Утыз алты яшьлек ирсез хатын. Уңдүрт яшьлек кызы бар. Тансык аннан алтымы-бишме яшькә кечерәк. Алар арасындагы мәхәббәтме бу? Тимеркәева химия фәне укыткан техникумга Муллаяров ярты кыш чамасы кичтән укырга йөргән. Шулчакны Рәйсәне бермe-икеме тапкыр озата кайткан... Тол хатын йөрәгендә туган сәер бер хис ут булып дөрләп кабынып китте. Менә хәзер дә аны шушы хис суд залына китерде.

ИСЕМЕҢДӘ — ҖИСЕМЕҢ...

«Бөгелмә вокзалында өч татар егете белән таныштым, нефтьчеләр икән. Зарифулла, Рәхимҗан, Галинурларның да Казанга кайтулары. Бер вагонга туры килдек. Чаллыда безнең янга тагын бер ир-ат утырды. Ул үзен «Николай» дип таныштырды да, безнең исемне сораша, үзе теләгәнчә тәрҗемә итә, боза башлады. Шулай итеп, Зарифулла, авызын ера торгач, «Зиновий» булды. Рәхимҗан да аны-моны уйламыйча, җиңел генә «Роман»га әйләнде.

— Галинур, — дип таныштырды тагын бер кат үзен өченче егет, укый торган китабыннан аерылмыйча.

— Кем, кем? — Яңа юлчы, канәгатьсезлек белдереп, кашын җыерды. — Төшенмәдем. Кем дидегез?

— Га-али-нур. — Бу юлы күршем басым ясап, исемен иҗекләп әйтте.

— Мин чынлап сорыйм бит, — диде теге, хәтере калгандай. — Безнеңчә ничек?

— Галинур! — Бу юлы да бер үк исем кабатланды.

— Русча ничек дим мин сиңа? — Тигәнәк һаман үзенчә тел чарлый иде әле.

— Сез үзегез кем буласыз? — Җавап әйтү урынына Галинур Чаллы кешесенә, нәкъ аңа охшатып, сөзеп карады.

— Әйттем ич, Николай! — диде теге төксе генә.

— Безнеңчә, татарча ничек? — Галинур да нәкъ аныңча төпченергә тотынды.

Чаллы кешесе беравык телсез калды, аның сары чәче үрә торгандай булды.

— Никак! — диде ул, ниһаять, кырт кисеп. — Безнең исем тәрҗемә ителми.

— Алай булгач, — дип, Галинур аның җавабын җайлы гына эләктереп алды, — нишләп безнең исемнәрне бутамакчы буласыз? Безнең исемнәр дә, сезнеке кебек үк, тәрҗемә ителми бит. Нәкъ Каюм Насыйри әйтмешли, «төшсә суга батмыйдыр, ут кабынса янмыйдыр, күмсәң җиргә — чермидер...»

— Сезнеке миңа әллә нишләп авыр сыман тоела, — дип, юлчы гафу итенгәндәй акланмакчы булды.

— Алайса большевиклар аралашкан «товарищ» сүзе бар. — Галинурның әйтәсе сүзе бетмәгән икән әле. — Әмма ул да татар сүзе, башка телләргә «мал-туар ише» дигәннән кергән. Исегездә тотыгыз, Николай, ата-бабамнан килә торган исемне үзгәртергә мин сезгә флюгер да, манкорт та түгел!

Галинур, борылып, кабат Чыңгыз Айтматовның «Гасырга тиң бер көн» дигән китабын ачып укырга тотынды.

Күрәсең, Николай белән моңарчы әнә шулай күзгә-күз карап, ачыктан-ачык сөйләшүче булмаган. Әрсез булса да, ул бераз каушап торды. Киеренке тынлыктан котылу өчен эчке кесәсеннән кәрт алып, уйнарга тәкъдим итте. Уйнаучы табылмагач, ялтыравыклы чемоданын ачты, аннан бер литрлы шешә чыгарды. Исемнәрен үзгәрткән ике манкортны стакан эзләргә җибәрде. Әйләнеп килгәч, стаканнарына шешәсеннән аксыл-яшел сыекча койды. Тирә-якка самогон сасысы таралды. Озак та үтмәде, өчесе дә исереп, үзара бәхәсләшә, якалаша ук башладылар. Әгерҗе станциясендә сәрхушләрне милиция кулга алгач кына вагонда тынычлык урнашты.

Зарифулла, Рәхимҗан кебекләрнең рухи мирасыбыз булган, ЗАГСта, паспортта теркәлгән исемне бозып, үз-үзләрен кимсетеп, түбәнсетеп йөрүләре барыбызны да борчый. Табигать, халык тарихы, туган тел кебек үк, безнең исемнәребез дә яклауга мохтаҗ. Исем бозучыларга чик куелырга тиештер ләбаса.

Зәйтүнә ЗӘЙНУЛЛИНА».

Менә шундый хат. Укучыларыбыз теләгенә кушылып, язучы-юрист Мәгъсум Насыйбулланың «Яшерен касса» кыйссасыннан бер өзек тәкъдим итәбез.

Мәхбүс Хәят Солтанова, җавап бирәсе урынга, еларга тотынды. Район прокуроры Мөнип аның хәленә керә — ашыктырмый, фикерләрен тупларга булыша. Зур тетрәнү кичергән тоткынның тынычланганын сабыр гына көтә. Аның шактый буталчык сүзләренә колак сала. Күңеле аша үткәрә.

— Нишләттеләр мине? Кеше күзенә ничек күреним хәзер... Гаебем юк бит минем, нишләп ышанмыйлар? — дип өзгәләнә Хәят. Аның йөзе суырылган, зифа буйлы гәүдәсе сыгылган ботактай бөгелеп төшкән. Ике сүзнең берендә: «Намусым!», «Исемем!» — дип кабатлый. Моны ул шундый җан әрнүе белән әйтә, аның ихлас сөйләвен, акылың белән аңлаудан бигрәк, йөрәгең белән тоясың. Мөнип күз алдына үз әтисен китерде. Чөнки ул да исемнең зурлыгын, намус сафлыгын икесен бер итеп карый иде. Район прокуроры заманында әтисеннән менә нинди гыйбрәтле сабак алды.

...Университетның дүртенче курсын тәмамлагач, Мөнипне җәйге спорт лагерена җибәрделәр. Араларында чит телләр факультетында укучылар да бар иде. Шуларның берсе шаяртып кына:

— Майкл дип йөртермен мин сине, Мөнип, ярыймы? — диде.

— О, ол райт! — дигән булды Мөнип. — Минем исемне үзгәртеп, инглизчә тел шомартмакчы буласыңмыни?

— Әйе шул, Майкл, заманча да яңгырый бит бу.

Күп кирәкмени шаяннарга. Шул җитә калды. Егерме ел Мөнип исемен йөрткән егет бер-ике көн эчендә «Майкл»га әйләнде. Яшерен-батырын түгел, егетнең үзенә дә ошап китте «заманча яңгырашлы» исем. Туган районында яшәүче таныш кызына, әти-әниләренә язган хатларны да ул берзаман «Майкл» дип төгәлли торган булды. Бер язды, ике язды. Өченчесенә әтисеннән татарча «тозлап-борычлап» язылган җавап алды. Гомер буе мәктәптә туган тел укыткан, һәр сүзнең ямен һәм тәмен белгән әтисе үз улының тиктомалдан Майклга әйләнүенә хәтере калган, рәнҗегән иде.

«Керләнсә, күлмәкне алыштыралар, тузса, искесен салып, яңасын кияләр, улым! — дип башлаган иде ул хатны, — ләкин кеше дигән бөек затның исеме күлмәк түгел, Мөнип. Ул керләнми дә, тузмый да. Ефәк күлмәгеңне ташлап, нейлонын алып ки — сүзем юк, әмма без кушкан исемеңә кагылма. Адәм рәтле кеше гомер юлын бер исем белән уза, аңа тап төшерми. Менә нәрсәне мыегыңа урап куй, улым: исемеңнән намусың читләшмәсен! Иң мөһиме шул. Атадан балага, буыннан-буынга күчә исем. Шулай булмаса, кешелек тарихында җуелмас эз калдырган бөек кешеләрне дә белмәс идек без. Моның ни икәнен күз алдыңа китерә аласыңмы? Минемчә, рухи томаналык булыр иде бу.

Хәтерлим, без яшь чакларда яңа тынышырга туры килгән кешеләргә: «Исем-шәрифләрегез кем булыр?» — дип эндәшә идек. Игътибар ит: исем-шәриф! Сез, бәлки, бу сүздән авыз ерырга да әзер торасыздыр, ләкин без ул сүзләрне кешегә ихтирам билгесе итеп әйтәбез.

Агач — җимеше белән, адәм — эше белән күркәм, ди татар. Фидакарь эше белән үз исемнәрен халык күңеленә мәңгелеккә язган ир асыллары, ил арысланнары аз түгел безнең халыкта! Пугачев таянычы булган татар батырлары дисеңме, Октябрь инкыйлабында ирек яулаган каһарманнар дисеңме! Ватан сугышында соңгы сулышкача көрәшкән геройлар дисеңме — барысын да үстерде татар иле. Аларның һәркайсына мәрмәрдән һәйкәл салырлык. Аларның исемнәре дә һәйкәл!

Син бик яхшы беләсең, Мөнип улым, балага исем кушу тәртибе канунда каралган. Яңа туган балага исем сайлау хокукы ата-анага бирелгән. Сабый әле дөньяга килмәгән, ә аңа исем сайлыйлар. Үзенә бер бәйрәм сыман гадәт бит бу. Туган-тумача, дус-иш калмый — барысы да исем эзләшә. Мәгънәле, шул ук вакытта күңелгә ятышлы, матур һәм аһәңле булсын, диләр. Без сиңа, үз заманында модага ияреп, «Дизель», «Трактор», «Руль», «Двигатель» кебек исем кушмаганбыз икән — аңла, зинһар: бу бит наданлыктан түгел. Исем сайлауда һәр халыкның үз традицияләре бар. Кыз бала исеме йолдыз балкышын хәтерләтсен, назлы гөлчәчәкләрне искә төшерсен. Ир баланың исем-шәрифләре шундый булсын ки, анда корыч чыңласын, акыл һәм зирәклек гәүдәләнсен. Күрәсең, нинди матур изге теләк, нинди тирән мәгънәле сүз. Уйламыйча исем кушуны өнәми безнең халык, андыйлардан көлә. Ишеткәнең бардыр: бер кеше малаена «Биртек» дигән исем кушкан, имеш. «Нишләп баланы мәсхәрә итәсең?» — дип сорагач, ул: «Ярамаган тагын сабыйга!» — дип кул селтәгән. Ә бит сабыйларның үсә торган гадәте бар. Әлеге мокыт шуны истән чыгарган.

Әйтергә теләгәнем шул, Мөнип: исем — кешенең гомерлек юлдашы. Берәүләргә — сәер, икенчеләр өчен — кызык һәм көлке, өченчеләргә «тел әйләнмәслек» булырга да мөмкин. Ләкин үзеңнең туган җиреңдә, туган телеңдә аны кушкан һәм газиз итеп йөрткән кешеләр өчен исем күркәм дә, изге дә. Әйе, исем изге дә, улым! Синең без кушкан исемең бер дә хурланырлык түгел, балам. «Мөнип» — гарәпләрдән алынган, «туры юлга басучы» дигәнне аңлата торган зур мәгънәле исем. Бәлки, инглизләр өчен «Майкл» да шундый кадерледер, анысын әйтә алмыйм. Кулыма каләм алуым да инглиз исемнәрен хурлау, яманлау өчен түгел. Байронны ничек яратуымны үзең беләсең! Ләкин сиңа «Джордж» дип кушмаганмын икән, моңа үкенмим, сиңа да хурланырга туры килмәс дип уйлыйм.

Һәр дәүләт үзенең гербын, гимнын, байрагын саклый. Ә кеше өчен боларның барысын да исеме алыштыра. Син дә үз исемеңне намусыңа тап төшермичә сакла. Каш ясыйм дип күз чыгару — акыл галәмәте түгел. Исемең — бер, эшең берәгәйле булсын! Намуслы исеменә кара тап төшермәс өчен бөек Пушкин җәрлә Дантес белән дуэльгә чыккан. Үзен сакламаган, гомерен җәлләмәгән — исемен, намусын саклаган.

Сиңа тагын бер тарихи белешмә. Рәсәйдә XIX йөзнең башына кадәр фамилия дигән нәрсә булмаган. Аны патша сарае тирәсендә тыз-быз килеп йөргән югары катлау руханилар, дворяннар, зур дәрәҗәле түрәләргә генә биргәннәр. Ромадановский дигән кенәзләр нәселе үз фамилиясен ике катлы итеп — Ромадановский-Стародубский дип язарга уйлаган. Ә патша Алексей Михайлович моңа рөхсәт бирми. Хикмәте бар икән: «Стародубский» дигән сүз әлеге кенәзләрнең иске биләмәләрен искә төшереп тора, ә Мәскәү патшасына, киресенчә, борынгы таркаулыкны бетерергә, урыс җирләрен берләштерергә кирәк. Шул сәбәпле, патша кенәзләргә фамилия янына «Стародубский» дигән сүзне язмаска куша. Гади исем генә диген син — патша хәтле патша үзе хәл итә торган мәсьәләгә әверелгән. Ромадановскийларның берсе, Григорий исемлесе, хөкемдарга баш орып, күз яшьләре белән үтенә: «Күрсәт шәфкатеңне, борынгы бабаларымнан килгән намускаемны миннән тартып алырга кушма», — ди.

Күрәсең, Мөнип, исем-фамилияне намус билгесе итеп караганнар һәм аның өчен патша алдында баш органнар. Шуңа күрә син дә әти-әниең зурлап кушкан исем-шәрифеңне бозма, намускаебызны тапламá!»

Әтисенең бу хаты Мөнипнең шәхси китапханәсендә, иң кадерле китаплар арасында саклана. Дәфтәрдән алынган тоташ ике битне тутырып язган. Прокурор Мөнип, тоткын хатынны тыңлап утырганда, әтисеннән васыять булып калган шушы хатны яңадан укып чыккандай булды. Дөньяның ачысын-төчесен татыган, дәһшәтле сугыш юлларын үткән әтисенең фикерләре белән әле генә тормыш юлына аяк баскан Хәят сөйләгән сүзләр арасында ниндидер бәйләнеш бар сыман тоелды. Кем белсен, бәлки, рухи бердәмлектер бу. Бәлки, халык күңелендәге әхлак кагыйдәләренең таза, саф килеш бер буыннан икенчесенә күчүедер.

АСЫЛЫБЫЗГА КАЙТЫП БАРЫШЛЫЙ

Ул дөньяны Ислам аша ачкан...

— Беләсезме, мин тәкъдиргә, Аллаһының рәхмәтенә, аның бәндәне ташламавына бөтен барлыгым белән ышанам, — дип башлады сүзен Искәндәр әфәнде Михаиль. — Минем бөтен узган гомерем, тормышым кем тарафыннандыр алдан билгеләп куелган юлдан барды кебек...

Искәндәр әфәнде Михаиль — Казандагы Ислам университетының гарәп теле кафедрасы мөдире, «Алтын ай» акционерлар җәмгыятенең Якын Көнчыгыш илләре секторы мөдире Александр Савельевич Михеев. Ул Ислам диненә күчкәч, аңа мөселманнар, шәкертләре якын итеп шулай дәшә башладылар.

Әйе, вакыт дигәнең һәрнәрсәне үз урынына куя. Нәсел шәҗәрәсендә урыс һәм черкас каннары ярылып ятса да, тумышы белән христиан булса да, җаны, рухы белән мөселманлыкны якын иткән Искәндәр әфәнде. Ислам динен кабул иткәч, өч ел элек ул хаҗ да кылып кайтты. Александр Савельевич, йөзеннән нур сирпелеп торуы, сөйкемлелеге, коңгырт күзләре белән үзе дә татар халкының зыялыларына тартым икән. Аның белән күбрәк сөйләшкән, аны күбрәк белә барган саен, Искәндәр әфәндегә соклануым артканнан-артты. Күңеле дә, җаны да, уй-хыяллары да бәллүр кебек саф, керсез икән аның.

— Мин бик күп диннәрне тирәнтен беләм, аларның һәркайсын җентекләп өйрәндем. Әмма Исламнан да камилрәген тапмадым, — дип дәвам итте ул сүзен.

... Александр Савельевичның бүгенге көндә ирешкәннәренең, йөргән юлларының барысы да балачак хыялларына барып тоташа. Төньяк Кавказ шәһәрләренең берсендә туып, гүзәл табигать белән хозурланып үскән малайның күңелен тарих дәресләре айкап-чайкап алгандай итә. Көнчыгышка, Мисыр пирамидаларына беренче сәяхәтләре аның хыялында тарих дәресләрендә туа. Гөрләп торган серле гарәп илләре, Мисыр турындагы мавыктыргыч хикәятләр нәни Сашаның уй-хыялларын әллә кайларга алып китә дә күзгә күренмәс чылбырлар белән бәйләп куя. Бу чылбырлар исә кеше гомеренә җитәрдәй нык булып чыгалар. Бала чакта бөрләнгән уй-хыяллары аны Мәскәүдәге иң дәрәҗәле уку йортларының берсе булган чит телләр хәрби институтына алып килә. Бирәдә әдәби гарәп телен һәм аның күпсанлы шивәләрен өйрәнергә мөмкин була.

Ул елны институтка килгән яшьләрнең күбесен кытай теле бүлегенә җыялар. Ләкин Саша шул мәлдә хәлиткеч адым ясый — үзен гарәп теле бүлегенә алуларын сорый. Егеткә кабул итү комиссиясе бик тә гаҗәпләнеп карый. Укырга килүчеләрнең барысы да диярлек француз, инглиз, итальян телләре дип авыз суларын корыта, ә бу егет... гарәп телен сайлаган. Сашаның теләге берсүзсез үтәлә. Бу көннәрдә егетнең әлеге телнең Көнчыгыш илләренә юл ачуын аңлаган күңеле бер генә тапкыр талпынып, канатланып очмагандыр, билгеле.

Институтта, икенче курсны тәмамлагач, шәкертләргә нинди дә булса чит илгә чыгу мөмкинлеге тудырыла. Һәм 20 яшьлек Александр Көнчыгыш шәһәрләренең анасы — Каһирәгә эләгә. Гарәп илләре егетне бөтенләйгә үзләренә әсир итәләр. Искәндәр әфәнде бүген дә бу тәүге хисләр, хатирәләр турында дулкынланып сөйли.

... Еллар уза. Александр Савельевичка хезмәте буенча ун елдан артык гарәп илләрендә яшәргә туры килә. Ул Якын Көнчыгыш гарәп илләрен аркылыга-буйлыга дигәндәй иңли. Төньяк һәм Азия гарәпләренең бер-берсеннән аңлаша алмас дәрәҗәдә аерылган телләренең һәркайсында тоткарлыксыз сөйләшергә өйрәнә. Шулай итеп, ул гарәп телләрен үзенә буйсындыра, ә гарәп телләре — аны... Әйтерсең, Александр Савельевичның хыялларын язмыш үзе чынбарлык белән тоташтырып бара. Саша кечкенәдән үк данлыклы тарихи шәхес — Клеопатра язмышы белән кызыксына. Һәм шундый вакыт җитә ки, тәкъдире аны Клеопатра эзләре буйлап йөртә. Мисыр белән Алжир шушы истәлекле, дулкынландыргыч көннәре белән аның күңелендә мәңгелеккә уела. Көнчыгыш гарәп илләре — Ливия, Йәмән, Гыйрак, Судан, Иордания егетнең күңелен үзенчәлекле гореф-гадәтләре, көнкүреше белән җәлеп итә. Гарәпләр аны үз кешеләредәй якын итеп, ачык йөз белән каршы алалар, яратып үзләренчә «Искәндәр әфәнде» дип дәшәләр. Әлеге илләрдә узган еллары аңа яшәүнең асылына төшенергә булыша. Аларны Искәндәр әфәнде тормышының аеруча мәгънәле чоры итеп искә ала.

Александр Савельевичның китап киштәләрендә гарәп телендәге басмалар, журналлар, истәлекле әйберләр ул көннәрнең кадерле хатирәсе булып саклана. Журналларны аңа гарәп илләрендә калган дуслары даими җибәреп тора. Искәндәр әфәнде шушы журналлардан көненә 3—4 бит укуны үзенә кагыйдә итеп куйган.

— Миңа хезмәтем буенча гарәп илләрендәге барлык катлау кешеләре белән — машина йөртүчедән алып министрга кадәр — аралашырга туры килде, — дип сөйли Александр Савельевич. — Мин яшь, кызыксынучан идем. Бу елларда байтак илләр гиздем, урыс һәм гарәп телләрендә күп укыдым.



Үзем дөньяны күзәтәм, үзем аның асылына төшенергә тырышам. Аурупага күп яңалыклар биргән гарәп цивилизациясенең көче нәрсәдә соң? Алар нинди өлкәләрдә артта калган? Инде барысы да җимерелгән, кешеләрнең бер-берсен алдавына корылган бу дөньяда сафлык, намус дигәннәре сукыр бер тиен белән бәяләнгән чакта бәлки шушы артталык 20 нче гасырның акылыдыр?

Күңелен һәрчак шушындый уйлар бимазалый Александр Савельевичның, һәм ул Коръәнне, дини әдәбиятны укырга керешә, тормыш куйган сорауларга җавап эзли, дин әһелләре һәм галимнәр белән гәп кора, Кәгъбә тарихын, пәйгамбәрләр тормышын өйрәнә. Төркиядә Искәндәр әфәнде мөселманнар арасында танылган шәхес Фәтхулла әфәнде, Согуд Гарәбстанында Ас-сенуси мәчете шәехе, Сүриядә Димәшкъ мәчете имамы белән хәдисләр, мәзһәб, фикһә, яшәү хакында барган әңгәмәләр аңа дөньяның күп хикмәтләрен ачарга, аңларга ярдәм итә.

— Инде шактый вакытлар узып, Татарстанга кайткач, бирәдәге алфавитның нигә өч тапкыр үзгәртелүгә дучар ителүен дә аңладым кебек, — дип сөйли А.Михеев. — Милләтне Ислам йогынтысыннан сакларга теләгәннәр икән. Чөнки гарәп алфавиты, гарәп теле — ул Исламның асылына төшенү юлы. Минем тирәнтен ышануымча, зыялыларның бер өлеше кабат латин хәрефләрен кертү өчен җан ата икән, бу — милләтне тагын бер тапкыр дини тамырларыннан аераларга тырышу.

Вакытлар узгач, чит илләрдән кайткач, Александр Савельевич алдында Мәскәү, Ленинград кебек мәртәбәле шәһәрләрдә эшләү мөмкинлекләре ачыла. Әмма ул, бу шәһәрләрне калдырып, Казанда яшәргә ниятли. Аның хатыны да — Казандагы, зыялы татар гаиләсеннән — Сафиуллиннар кызы. Хатынының әбисе Александр Савельевичны, бик тә яратып, хәтта сокланып кабул итә һәм, мәрхүм булганчыга кадәр, киявенә җылы, ягымлы мөнәсәбәттә була. А.Михеевның, Ислам динен кабул итеп, мөселман булу тарихы да күпмедер дәрәҗәдә шушы әби белән бәйле.

... Михеевлар гаиләсенең Сүриядә яшәгән вакыты. Алар чираттагы ялларын уздырыр өчен Казанга кайталар. Шунда Михеевларга әбиләренең авырып китүе, гомеренең кыл өстендә булуы турында хәбәр килә. Яшь гаиләгә, тиз генә җыенып, шәһәрнең икенче районына барырга кирәк була. Үлем эчендә яткан кеше янына бару бик авыр, газаплы. Шунда Александр Савельевичка, әйтерсең, кемдер искәртә. Ул, юлга чыкканчы, душ астында юынып ала.

Мулла нигәдер озаклый. Ә әбинең күршесе Александр Савельевичның гарәп телендә су эчкәндәй укуын һәм сөйләшүен яхшы белә. Ул, әбинең аңсыз ятуын, җан бирә алмый интегүен күреп, Михеевка Коръән суза.

— Укы!

Александр Савельевич башта бу тәкъдимне кире кага, аннары изге китапны алып, үлем белән яшәү арасында яткан карчыкның баш очына утыра, Коръәннән Әл-Фатиха сүрәсен укый башлый. Искәндәр әфәнде аны нәкъ җиде тапкыр укый. Бу вакытта бик авырлык белән генә сулап яткан әби аның укуын ишеткәндәй һәм әлегә кадәр Коръән сүзләрен генә көтеп яткандай тоела. Укып бетергәч, Михеев нык тетрәнеп һәм хәлсезләнеп әби яткан бүлмәдән чыга. Бер минут та узмый, ишектә күрше хатын күренә һәм әбекәйнең җан бирүе турында әйтә.

Аның үлеме Александр Савельевичның җанын актарып ташлагандай итә. Ул, Коръән чыгарга ризалашып, дөрес эшләдемме соң? — дип газаплана. Чит илгә әйләнеп кайткач, мәчетнең имам, суфиларына да шушы хакта сөйли. Алар, үзара киңәшләшкәннән соң, Александр Савельевичның гамәле дөрес булуы турында әйтәләр: «Әби Коръән фатихасы сүзләрен көтеп яткан һәм шуны тыңлап дөньядан киткән. Аллаһы исә бу эш өчен сине сайлаган, без синең күңелеңне изеп торган авырлыкны алабыз», — диләр.

Тормыш кешене төрлечә сыный. Көннәрдән бер көнне Александр Савельевичның машинасын урлыйлар. Ул моңа бик борчыла. Эшләгәнен тиенләп дигәндәй җыйнап, үз хәләл көче белән сатып алынган машина ич ул! Ходай Тәгалә ник бу эшкә юл куйды икән, дип газаплана Александр Савельевич. Ул шушы уйларын Габдулла хәзрәт белән дә уртаклаша. Хәзрәт исә, Искәндәр әфәндене гаҗәпкә калдырып, Аллаһының бу эш белән аңа игелек эшләвен әйтә: «Машиналар белән бик күп бәхетсез очраклар килеп чыга. Аннары үзеңне үтереп, машинаңа утырып китүләре дә бар иде бит. Тәңре менә сине шундый бәла-казадан саклый», — ди. Габдулла хәзрәтнең җавабыннан соң, Александр Савельевичның авыр кичерешләре дә юкка чыга, күптән түгел генә авариягә юлыга язуы да хәтереннән үтә.

Соңгы елларда халкыбызда исем кушу, никах уку йолалары яңару, гореф-гадәтләр кайту — олы бер сөенеч. Әмма катнаш гаиләләргә бу йолаларны мәчеттә башкарырга ярамый икән. Искәндәр әфәндене катнаш никахта булган танышларының кызларына мәчеттә, бөтен йоласына туры китереп, исем кушу мөмкин булмавын әйтәләр. Ата-ана бу хәлгә бик тә борчыла. Шунда аларга тирән дини белемле, мөселман буларак, Александр Савельевич ярдәмгә килә, кызга исем кушу йоласын җиренә җиткереп үти. Танышлары да тынычланып кала. Искәндәр әфәндегә мондый үтенечләр белән еш мөрәҗәгать итәләр.

Александр Савельевич табигатьне ярата. Иртәнге намаз вакытында яңа көн туганын күрү аның тормышына ямь өстәгәндәй итә. Англиядә булганда таң ату манзарасын күзәтү аны аеруча тәэсирләндерә. Англиядә бездән барган делегацияне бер пакистанлының өенә урнаштыралар. Кич белән ул кунаклардан: «Иртәнге намазда катнашырга теләүче кеше бармы?» — дип сорый. Искәндәр әфәнде үзенең бик тә катнашасы килүен әйтә. Бу өч көндә аны иртәнге сәгать дүртләр тирәсендә уяталар. Алар махсус җиһазланган бүлмәдә намаз укыйлар. Дога укылып бетеп, йола тиешенчә башкарылгач, пакистанлы аны тәрәзә янына дәшә. Ә анда акрын гына яңа көн туып килә. Бөтен тирә-як — искиткеч тынлыкта, матурлыкта. Шунда яңа танышы әйтә: «Искәндәр! Кара! Аллаһы Җиргә яңа көн бирә. Шуны карап торсаң, аның көчен, бөеклеген үз күзләрең белән күргәндәй буласың».

— Мин андагы матурлыкны бернәрсә белән дә чагыштыра алмыйм. Бөтен барлыгымны бер теләк биләде. Шушы мизгел бетмәсен, мәңге дәвам итсен иде! — дип хатирәләрен яңарта Искәндәр әфәнде.

Уйлар, уйлар... Нинди ләре генә юк аларның! Шуларның иң тирәне, мәгънәлесе Җир белән серләшкәндә туа. Искәндәр әфәнде, Ислам дине канунннары кушканча, бакчада эшләүне — казу, тырмалау кебек мәшәкатьләрне ир-ат башкарырга тиеш дип исәпли. Шуңа күрә дә бакчасындагы төп эшләр аның кулы аша үтә. Шул вакытта аның күңел түрендә татлы-газаплы уйлар баш калкыта.

... Ул үзенең Җирдәге урынын дөрес сайладымы соң? Ә бәлки борынгы бабаларыдай иген үстерсә, отышлырак булыр иде?..

Ислам университетында уку шартлары бик тә кырыс. Спиртлы эчемлекләр куллану, тәмәке тарту тыела, дәресләр күбесенчә гарәп, урыс телләрендә алып барыла. Менә шундый шартларда шәкертләрнең күңелендәге очкынны дөрләтеп җибәрү кирәк. Чөнки андый очкын юк икән, ул университет шартларына түзә алмаячак.

Исламның кешеләргә яктылык, югары әхлак алып килеренә ышанган Александр Савельевич, шәкертләргә белем бирү белән бергә, аларны яхшы күңелле булырга, изгелек кылып яшәргә чакыра, яшьләрдә тарихны ярату, үткәннәргә хөрмәт белән карау хисләре тәрбияләргә тырыша. Шәкертләре белән мактанып та ала: «Бездә иң саф, чиста күңелле яшьләр укый», — ди.

... Бүген ана улны, ата кызны белми башлаган, кайберәүләрнең байлыкны түргә менгереп, шуның өчен намусларын саткан бер заманда арабызда Искәндәр әфәнде кебек кешеләрнең яшәве киләчәккә ышаныч уята.

Сөембикә КАШАПОВА.

Үз илем — алтын бишек

Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА,
композитор

КЕЧЕ УКМАСТА, ЧИШМӘЛӘР ИЛЕНДӘ

Гасырлар буе Романовлар чыбыркысын үз җилкәсендә татыган татар авылларының милли үзенчәлеккне, үзаңны саклап кала алганына таң каласың. Авыл кешеләренең сөйләшүе дә чын татарча, аһәңле булып яңгырый. Халкыбызга хас гадилек, борынгы бабаларыбызга ихтирам, сабырлык, сөю-сәгадәт, саф мәхәббәт хисләре, күркәм гореф-гадәтләр авыл җирендә яхшы сакланып калган.

Нигә бу авылга мондый исем биргәннәр? Бирегә беренче аяк баскан кеше күңеленә булачак авылның кай тарафы хуш килгән? Изгеләргә дога кылып, теләкләрен теләп, балтасы белән агачка чапканда шул кайтавазлар аңа ни сөйләгән?

Милли тел — күрке халыкның, бетми милли телләр,
Күп яшәргә дәртле милләт халкы милли тел биләр.
Яхшы милли телле — милләт, милли тел — милләт җаны,
Изге хисне, милли гадәтне дә милли тел сөйләр.

Миргазиз УКМАСЫЙ.

Урыс һәм татар мөнәсәбәтләре

Балык Бистәсенә сәфәргә чыккач, миң үзем булырга туры килгән авыл кешеләренә беренче итеп әнә шул сорауларны бирдем. Һәр авылның үзенә күрә сүз остасы, фәлсәфәчесе, артисты, мәзәкчесе, башлап йөрүчесе була. Кече Укмас авылының фәлсәфәчесе дип мин Сабирҗан абый Мөбарәковны атар идем. Заманында зирәклеге, уңганлыгы һәм... усаллыгы белән танылган Сабирҗан абый күп хатын-кызның явын алырлык чибәр кеше. Күзләре күк йөзе кебек, зәп-зәңгәр! Хәләл җефете Миңниса апаның тавышы Шәрыкның моңлы музыка кораллары авазын хәтерләтә. «Шушы авылда туып үстек, гомер кичердек, мәңгелек йортыбыз да шушы зират каеннары арасында булса иде», - - дип тели ул.

Сабирҗан абый иң беренче нәүбәттә авылларының атаклы кешесе итеп Миргазиз Укмасыйны атады. (Шагыйрь 1884 елда Казан гөбернәсенең, Лаеш өязе Кече Укмас авылында мулла гаиләсендә туган). Аннары ул тирә-як авыл кешеләрен гашыйк иткән елгалар, инешләр, урманнар, дини мөнәсәбәтләр турында сөйләргә кереште.

Олы Укмас белән Кече Укмас әүвәл бер авыл булган. Авыл тирәсен хисапсыз калын урманнар каплаган. Укмас зурайганнан-зурайган, анда җиде мәдрәсә генә булган. Бу мәдрәсәләрдә тирә-як авыллардан гына түгел, читтән килгән шәкертләр дә гыйлем эстәгән. «Бабайлар, авыл аша Пугач үткән, дип сөйлиләр иде. Пугачны мин башта Пугачевтыр, дип уйлый идем. Соңыннан пугачны сугыш, яу мәгънәсендә аңладым, - - дип сөйли Сабирҗан абый. - - Чукындырырга килгән кяферләр белән мөселманнар арасында бәрелешләр булган. Ниндн зур авылдан бер генә гаилә яшеренеп кала алган бит. Кайсы дин юлында шәһит киткән, кайсылары чукынган. Кече Укмас янында Дикое Поле дигән урыс авылы урнашкан. Татарлар аны Көек дип йөртәләр. Урыслар Кече Укмасны Малый Атмас, диләр. Элек бу ике авыл үзара дошманлашып яшәгән. Татар авылында урыска, урыслар авылында татарга каршы тәрбия бирелгән. Картларның «урыслар гөсел коенмый, шапшаклар, эш сөймиләр» дигән сүзләре яшьләр колагына кече яшьтән үк сеңеп барган. Дикое Поле урыслары татарларга хәтта кызыл балчык бирмәгәннәр. Балчык алыр өчен дә ялынырга туры килгән безгә, каһәр. Утлап йөргән атлар ялгыш тегеләр ягына чыкса, аларны үзләренә куып китә торган булганнар. Безнекеләр дә күп уйлап тормаган, авылларына менеп, кайсын кая орып, кыйнап, атларын алып төшкән, хәтта күсәкләр белән сугышканнар. Алар безне татар, без аларны урыс булганнары өчен яратмаган инде. Ә инде колхозлашу чоры башлангач, урыс белән татар авылын бер күмәк хуҗалык иттеләр. Яши торгач бер-беребезгә ияләштек инде. Ә менә Олы Укмас белән Кече Укмас хәзер икесе ике колхозда. Берсенә газ керде, икенчесе утын яга. «Аралар ике генә чакрым булса да, тормыш шартлары үзгә. Үги итәләр безне», - - диләр олыукмаслылар.

Ерганаклар Идел ясар, аларны Идел ашар

Кече Укмас елга-инешләргә бик бай. Шунысы кызык, Сабирҗан абый гына түгел, авылның башка кешеләре дә чишмәдән башланган инешләрне олылап Елга дип атыйлар. Шуңа мин дә аларны елга дип язарга булдым. Беренче урында зурлыгы ягыннан да, матурлыгы ягыннан да Йөрәк елгасы тора. Тау башыннан карасаң, гел йөрәк шикелле: елга үзенең борылышлары белән йөрәк ясый. Ярлары яшел таллыкка күмелгән, йөрәк эчендә дә гел агачлык. Болыннарында шаулап балан үсә, тик аны күрше авыллар җыеп бетерә икән. Икенче урында — Кызыл Су елгасы. Ул бик тирән, текә җирдән карасаң, башың әйләнеп егылып төшәргә дә мөмкин. Елганың ике яры да кызыл комлы балчыктан тора. Язгы ташулар вакытында елгадан кан төсендәге су ага. Бу ташулар дин өчен, ирек өчен корбан булган шәһитләрегезне онытмагыз, дигәндәй ярсып-ярсып хәтерне яңарта. Кече Укмаста тагын Изәт елгасы бар. Ул авылга төшеп җитәм дигәндә, уң кул яктан Сөякле елга менеп килә. Шуннан бераз гына киткәч, Агачлы елгасы күренә. Иске Арыш юлы белән барганда Янчык авылына Мирәт елгасы төшә. Аннан астарак Шәвәли елгасы җәйрәп ята.

Авылга Балык Бистәсе ягыннан кергәндә сул якта чишмәләр күп. Авыл халкы аларның суын аш-суга гына тота. Күз чишмәсенең суын эч авырткканда, балалар тәненә кутырлар чыкканда файдаланалар. Сабирҗан абый авыл халкының тешләре бик таза, без теш алдырырга сирәк йөрибез, диде. Димәк, су фтор һәм организмга кирәк тозлар эремәсенә бай, дип фараз кылырга кирәк. Авыл халкы тагын ике чишмәнең генә исемнәрен хәтерли алды. Берсе — Җәрми, икенчесе - - Әхмәт чишмәсе. Бу кешеләр үзләре исән чакта чишмәләрне карап, тамакларын чистартып торганнар, ахры. Һәм шуңа күрә дә исемнәре халык теленә кереп калгандыр.

Пумала писер Туктамыш

Кече Укмаста Туктамыш исемле писер булган. «Аңа нигә «Пумала» кушаматы такканнардыр, анысын әйтә алмыйм, — диде Сабирҗан абый. - - Әмма дә уңган-булган инде, бөтен авылны шул бер кеше тоткан.

Бер түрә сорый икән писердән:
— Кем булып эшлисең?
— Пумала писер булып.
— Старостагыз кем?
— Пумала писер Туктамыш.

Теге эш, бу эш вазифасын кем башкара, дигән сорауга да гел бертөрле җавап - - Туктамыш писер.

Хәзер менә җирле хакимият тә, колхоз идарәсе дә, милиция участогы да бар, ә тәртип юк».

— Эш дигәндә, укмаслылар әмма дә уңган инде безнең, — ди Миңниса апа, чәй ясый-ясый. - - «Кызыл Байрак» колхозы элек-электән районда алдынгы булды. Көек, Кече Укмас, Бәткә һәм Янчык — дүрт авыл халкы аерым бригадаларга бүленеп, ярыша-ярыша эшли иде. Бригадир Камил абзый төнге уникеләрдә үк сукачыларны уятып йөрер иде. Тәрәзәне шундый әкрен шакый, әйтерсең, күршедәге икенче бригат кешесе уянып, алданрак чәчә башлавыннан курка.

«Колхоз — диңгез, без - - парахут,
Дөпелдәтәбез генә», - -

дип җырлап йөри торган заманнар узды, бергә җыйган колхоз байлыгы хәзер башка авылларда, кече укмаслыларга эш кенә калды. Хәзер менә, Аллага шөкер, колхоз рәисебез үзебезнең авыл малае. Низам абый, Сәҗидә апаның малае Гомәр Шиһапов безнең күз алдында үсте.

- - Уңдык рәистән, - - ди Сабирҗан абый, чәен уртлап куйгач. — Бер ел дигәндә газлы итте бит авылны, рәхмәт төшкере. Гомәр ул эшсез тора алмый. Ни өчен дигәндә, нәселләре чуар йөрәкле. Бервакыт без кем беләндер тау башында сөйләшеп утырабыз. Сәҗидә апа, уллары Хәсән, Гомәрне ияртеп, колхоз кәбестәсенә су сибәргә төшкән. Әниләре дүрт төпкә бер чиләк су сибә, ә малайларның эшне тизрәк тотасы килә - - бер чиләк суны 11 төпкә җиткерәләр. Кайтып барганда иплән кенә тау башыннан төштем дә әйттем Сәҗидә апага:

— Моннан ары кәбестәне малайларың гына сугарсын инде. Ни өчен дигәндә, алар рекорд куйды бүген, — дидем. Шул сүз җитте егетләргә, аңлап кызарыштылар. Булырдай адәм уң яшендә баш булыр, булмас адәм кырыкта да яшь булыр дигәндәй, кечкенәдән эшләп, эш рәтен белеп үскән егет ул Гомәр.

- - Пумала писер Туктамыштай булган кешеләр бар инде алайса колхозыгызда?

- - Әлбиттә. Андыйлар булмаса, дөньяның кызыгы, тормышның рәте китә бит. Дөнья мәшәкатен үз җилкәсенә алырлык Гомәрдәй егетләре булган Кече Укмас яши әле, яши!!

Байлар Сабасының асыл хәзинәсе

«Үткәннәрне белми торып, хәзергенең мәгънәсен һәм киләчәкнең максатын аңлау мөмкин түгел», - - дигән Максим Горький. Музейларда булганнан соң, узган тарихыбыз кабат күңелләрдә яңара. Сабада да бар андый изге урын. Бай тарихлы төбәк бит ул Байлар Сабасы. «Идегәй» дастанында мондый юллар да бар бит:

... Изге шәһри Болгарны,
Астаналы Сиварны,
Капкасы биек Казанны,
Чулмандагы Җүкәтау,
Урмандагы Сабаны...

Район үзәгеннән ерак булмаган Эзмә авылының иске зиратында Хөсәен атлы кешегә куелган 1332 елгы кабер ташының бүгенге көндә дә саклануы Саба якларының бик борынгы булуын тагын бер кат дәлилли. Дөрес, район музее бераз соңрак оешты. Ул бина булмау, дөресрәге, игътибар җитенкерәмәү сәбәпле сузылды. Башта мәктәп музеенда мәгариф ветераны Рәйсә Сираҗиева туплаган тарихи материаллар бер бүлмәгә генә сыймый башлады. Халыкның соравын искә алып, район хакимияте КПСС райкомының элеккеге бинасыннан дүрт бүлмәне музейга бирде. Ә инде 1993 елның 13 маеннан ул Татарстан Республикасының берләштерелгән дәүләт музеенең Саба филиалы статусын алды. Аның белән дә тынгысыз энтузиаст Рәйсә Бәдретдин кызы Сираҗиева җитәкчелек итә. Филиал яңадан-яңа экспонатлар белән яңартылып тора. Биредә элекке заманның һөнәрчелек-көнкүреш әйберләрен, археологик казылмалар, тарихи документлар белән танышырга була. Әдәбият һәм сәнгать бүлеге аеруча игътибарны җәлеп итеп тора. Саба төбәгеннән алты кеше Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Алар -- язучы һәм галим Әбрар Кәримуллин, рәссам Тавил Хаҗиәхмәт, композиторлар Хөснулла Вәлиуллин, Фасил Әхмәт, музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов, мәшһүр артист Шәүкәт Биктимеров. Музейда әдәбият белгече Азат Әхмәдуллин, язучылар Мәгъсүм Хуҗин, Фәүзия Бәйрәмова, этнограф Дамир Исхаков, композитор Аллаһияр Вәлиуллин, артистлар Шамил Бариев, Һаҗәр Шәкүрова, Әлфия Хәсәнова, Илдус Сафин, Нәҗип Бәдретдиновлар турында да тулы мәгълүмат алып була.

Әле күптән түгел тагын бер мәшһүр якташыбыз - - Мәскәү рәссамнары берлеге әгъзасы, Бөтендөнья татар рәссамнары ассоциациясе президенты, сынчы Кадим Җәмитов үзенең ун әсәрен туган як музеена бүләк итеп кайтарды. Алар арасында Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал кебек шәхесләрнең бюстлары бар. Гомумән, ташларны эреткән якташыбыз экспозициясе күпләрне сокландырыр. Хәзер галим һәм җәмәгать эшлеклесе Әбрар ага Кәримуллинның тормыш һәм иҗат юлына багышланган бүлек аның шәхси әйберләре белән баетыла.

Кыскасы, Саба музееннан халык өзелеп тормый. Анда дүрт меңгә якын экспонат тупланды. Эзләнүләр дәвам итә.

Тәлгат НӘҖМИЕВ.

● Музейның фәнни хезмәткәре, районның баш мөхтәсибе хаҗи Илдар Яхъя экспонатлар белән таныштыра. Дан орденының тулы кавалеры, снайпер Абдулла Мотыйгуллинга багышланган экспозиция.

РӘСЕМНӘР ҺӘМ ХӘТЕРДӘГЕ ИСЕМНӘР

«Мәдәни җомга»ның 3 нче санында (4 нче август 1995) гражданнар сугышы хакындагы язманы һәм Татарстан халык язучысы Гомәр ага Бәшировның «Без кичкән сират күперләре» исемле истәлеген укыгач, олы язучыбыз белән кайбер очрашуларым турында язарга булдым.

Сугыш башланган елның кышы бик салкын килде. Без шул чатнама суыкта Толымбай авылыннан ерак түгел Зөя елгасы буенда таш булып бозланып каткан җирне, утыннар ягып җылытып, көненә унар сәгать лом белән чукый идек. Өс-баш юка, ашарга алып барган икмәгебез таш булып ката... Төзелешнең әһәмияте дә бар: Зөя елгасы буйлап немец-фашист яулары килеп чыга калса, танк һөҗүменә каршы торырлык ныгытма булачак бу. Октябрь азакларында бирегә фронтка китеп өлгермәгән бер төркем язучылар – Гомәр Бәширов, Фатыйх Хөсни, Хәсән Хәйри, Кәшифи Басыйров, китап нәшрияты хезмәткәрләре җибәрелгән иде. (Кәшифи Басыйров белән мин военкомат чакыруы белән алданрак кайттык).

Бу вакытларда Мәскәүдән эвакуацияләнеп кайткан күп кенә урыс язучылары Татарстанда җылы өйләрдә, ашау-эчү белән тәэмин ителеп, иҗат итәргә җай таптылар. Күпчелек татар язучылары, шагыйрьләре, сәнгать әһелләре бу вакытта фронтта кан коялар иде. Шушы айларда мин Гомәр ага Бәшировны якыннанрак белдем. Ул хәрби төзелешкә катнашучылар өчен чыга торган гәзиткә материаллар җыя, анда эшләүчеләр белән очраша, әңгәмәләр кора. Агитатор буларак, трасса буйлап йөреп мәгълүмат тарата, җиңүнең безнең якта булачагына күңелләребездә зур ышаныч тудыра иде. Бигрәк тә бу эш Мәскәүне азат иткәч (1941 ел, 5 декабрь) активлашты. Шул көннәрдә гәзитләрдә басылып чыккан әмер халыкны эшкә дәртләндерде.

Сугыштан соң бергә нәшриятта эшләгәндә без ул көннәрне еш искә ала идек. Минем ФЗӨда укыганда мехчылар хезмәтен сурәтләп ясаган рәсемне Гомәр ага Бәширов «Кызыл Татарстан» гәзитендә бастырды.

Балачактан ук Гомәр Бәширов, Шамил Усманов хикәяләрен укып үскәнгә, гражданнар сугышы темасы мине аеруча кызыксындыра иде. Г.Бәшировның «Сиваш» исемле әсәренә багышлап бер-ике рәсем дә ясадым. Шуларның берсе – Гомәр Бәширов портреты. Мин язучыны гражданнар сугышы елларындагы Кызыл Армия сугышчысы киемендә сурәтләдем. Үзенә күрсәткәч, ул аны ошатты һәм кайбер киңәшләр бирде. Әлбәттә, мин, ул киңәшләрне истә тотып, портретны яңадан күздән кичердем.

Шул рәсемнең бер вариантын «Мәдәни җомга» укучыларына да тәкъдим итәм.

Мансур РӘХИМОВ,
Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны.

«КӨМЕШ КАШЫК БОЛЫТТА»

Керләнә өст-өстенә рух,
һич хозур вөҗданга юк,
Ни сәбәптән тәнгә – мунча,
җанга – юк?!
Г.Тукай.

Яңгыр, яу, яу, яу,
Тәмле ботка бирермен.
Тәмле ботка казанда,
Тәтәй кашык базарда.

Яңгыр, яу, яу, яу,
Безгә ачлык килмәсен,
Кеше ачка үлмәсен,
Яңгыр, яу, яу, яу!..

Ел коры килгән чакта балаларның яңгыр чакыруы, болыт чыгуын теләп су сибешү йоласы өлкәнрәк буын кешеләр күңелендә якты истәлек-хатирә булып саклана. Гөнаһсыз сабыйларның эчкерсез теләкләрен күкләр ишетәме? Ишетәләр. Илаһи музыка яңгырауга, моннан ничә йөз гасырлар элек һәлак булган цивилизация кешеләре яңа башлады. Менә алар, җиргә яңадан туасы җаннар, ана карынында. Кайчандыр туфан калкып, су төбенә киткән цивилизация кешеләренең җаннары, гөнаһларыннан арынып өчен, яңадан җиргә килә. Күңелләре чистарырмы аларның? Әллә, элекке гөнаһларына яңаларын өстәп, җир йөзеннән кабат китәрләрме? Туасы җаннарны җирдә бәхет, сөю-сәгадәт көтәме, әллә кайгы-хәсрәтме? Кеше дигән бөек исемгә лаек булырлармы алар? Җирдәге афәтләр – су басулар, җир тетрәү, сугышлар очраклымы?

Чаллыдагы «Болгар» дәүләт бию ансамбле тарафыннан куелган «Көмеш кашык болытта» дигән бер актлы балетны карагач, күңелгә шундый фикерләр килә. Бу авангард стилендә куелган хореографик фреска – композитор Мәсгудә Шәмсетдинова, рәссам Таң Еникеев һәм концертмейстер Юрий Смышляевларның иҗади дуслыгы, фикер берлеге нәтиҗәсендә туган әсәр. Таң Еникеев белән Казан тамашачылары Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә зур уңыш белән барган «Идегәй» спектакле аша таныш.

Әлеге балетта композитор, рәссам, балетмейстер хезмәтләре шулкадәр тәңгәллек тапкан, драматургиясе бер-берсенә шулкадәр үрелгән ки, тамашачы аны бербөтен әсәр итеп кабул итә. Шул ук вакытта аларның һәрберсе аерым-аерым да яңгырый ала. Глобаль космогоник тамаша, образ аша чистарыну музыкада да, биюләрдә дә, декорациядә дә чагылыш тапкан.

Әсәрне тагын да тулыландырып, өйбәтрәк күзалларга ярдәм иткән бер шәхес турында әйтәсе килә. Бу – үзешчән рәссам Гөлнәфисә Лопанова. Аның рәсемнәре хореографик феерияне бизәп торачак. Хәзер ул рәсемнәрен күргәзмәгә әзерли. Балет барган көннәрдә татар халкының тормыш-көнкүрешен чагылдырган экспозиция әзерләү дә күздә тотыла.

Элек Чаллыда оешкан «Совет-итальян дуслыгы» җәмгыяте балет белән кызыксынып, аны Италия тамашачыларына күрсәтергә хыялланa. Итальяннар аны хәтта ачык һавада, шәһәр урамнарында да күрсәтергә мөмкин, дип исәплиләр.

Чаллы тамашачылары балет белән быел көзен танышачак.

Земфира ХӘСӘНОВА,
биюләрне сәхнәләштерү бүлеге мөдире.
Чаллы.

КҮК КАПУСЫН АЧУЧЫ

60 нчы елларда Казан күк гөмбәзенең югары катламын ачып, реактив очкычларда бихисап пассажирлар йөреткән беренче класслы очучы Рәшит Ибраһимов хәзер инде лаеклы ялда. Әмма авиация ветераны кул кушырып утырмый. Ул – алты китап авторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Бүген «Очарга вакыт» дип исемләнгән яңа документаль әсәр яза.

Бу сәхифәдә укучыларыбыз игътибарына шул әсәрдән бер өзек тәкъдим итәбез.

Казан күптәннән, бик күптәннән инде үзенең бөек шәхесләре белән горурланып килә. Бөтен дөньяга танылган галимнәр, язучылар, күренекле революционерлар, сугыш һәм хезмәт каһарманнары бүләк иткән шәһәр бу. Казан – беренче булып күк капусын ачып җибәргән Александр Васильев кебек күренекле авиаторлар биргән кала да.

1910 елның август ахырында шәһәр буйлап шундый хәбәр тарала. Имеш, киләсе урыс атнасында Казан ипподромында моңа кадәр күрелмәгән тамаша булачак: атлар чабышы урынына пиндидер шайтан арбаларының һавада очып йөрүләрен күрсәтәчәкләр икән.

Берничә көннән соң Казанда чыга торган гәзитләр әлеге имеш-мимешләрнең чынлыгын раслап шау-шу куерталар. Анда: «Һаваларда галәмәт хәл, анда кем оча – адәмме, фәрештәме?» – кебек баш белән мәкаләләр дә бер-бер артлы басылып чыга. Тиздән шәһәр коймалары аршин-аршин хәрефләр белән язылган игъланнар белән бизәлә.

Ниһаять, сентябрьнең уночендә имеш-мимешләр гамәлгә аша: Казан ипподромы (ул әле дә үз урынында) иртәдән үк тамашачылар белән шыгрым тула.

Ипподром гөжләп тора. Биек трибунаның иң югары катындагы җәйле кәнәфиләргә шәһәрнең аксөякләре җәелеп утырган. Алардан астарак кечерәк түрәләр, сәүдәгәрләр, жандармерия әһелләре, хәрбиләр урнашкан. Ә мещаннар һәм гади шәһәр халкы иң аскы рәтләрдә көнбагыш чиртеп утыра. Җирдә, чирәм өстендә, драгун полкы музыкантлары бер сафка тезелеп басканнар да, шул заманның гаять популяр булып саналган күңелле бию көе – «Аерылган ханым»ны башкаралар.

Кинәт оркестр иң тантаналы маршка күчә. Бераздан үзәк капкада «Бенц» автомобиле пәйда була. Генерал-губернатор турыдан-туры аэропланнар янына килеп туктый. Ул очу аппаратлары янында кайнашкан авиаторлар белән кул биреп күрешеп чыга. Шулар арасында әле күптән түгел генә Казан университетында белем алган Александр Васильев та бар. Егет Франциядә очучылар мәктәбен тәмамлап, әле генә кайтып төшкән икән. Менә ул генерал-губернатор галиҗәнапларын аннан-моннан гына тимерчыбыклар белән аркылы-торкылы тарттырып ясалган очкычлар белән таныштыра.

– Бу – аэроплан-моноплан, ягъни бер канатлы очкыч. Аның «Гном» дип аталган моторы илле ат көченә тигез. Бусысы биплан – «Анрио-5». Ул шулай ук француз фирмасы җимеше. Утыз бин ат көченә ия! Очкыч сәгатенә 60 чакрым тизлек белән очарга сәләтле...

Һавага беренче булып Васильевның кунагы – француз авиаторы Леон Леторга күтәрелергә тиеш була.

Тынлык. Менә, ниһаять, аэропланның моторы телгә килә – тыкы-тыкы... тыкы-тыкы. Авиатор: «Очып китәм бугай инде, егетләр», – дигәндәй кул изи. Шул мизгелдә механиклар берьюлы читкә тайпыла. Очкыч дилбегәдән ычкынган елгыр юргактай алга ыргыла. Вак сикәлтәләрдә чикерткә кебек сикергәли-сикергәли йөз саженнар йөгереп узгач та, аэроплан кинәт җирдән аерылып китә. Бу минутларны сулыш та алмыйча зур түземсезлек белән көтеп алган тамашачылар дәррәү аягүрә басып, шау-гөр килеп, кул чаба башлыйлар.

Кинәт очкыч чайкалып җиргә төшеп калмасынмы. Ул арада берәүләр чәлпәрәмә далмасынмы. Халык мәш килгән очкыч янына ашыга. Әүвәле иң өлгер тамашачылар һәлакәткә дучар булган очучыга хәлләреннән килгәнчә беренче ярдәм күрсәтергә ашыканалар. Алар очкыч хәрабәсе арасыннан аңын җуйган француз егетен тартып чыгаралар. Кызганычка, тамашачылар арасында да яраланучылар бар икән. Берәүләренең мотор кыйпылчыгы башын тишкән, икенче берәүләренең ычкынып киткән көпчәк аягын гарипләгән, өченчеләрен зырылдап әйләнеп торган пропеллер кулсыз калдырган. Тирә-юньдә елаш, ыңгыраш:

– Йә, әйтегез инде, мәрхәмәтле әфәнделәр! Кулсыз ир белән ни эшли алам мин хәзер, ишилим?

Ә исәннәр француз очучысы янында. Ул кан эчендә.

– Мәрхәмәтле гражданнар! Юмарт әфәнделәр! Бәхетсезләргә ярдәм кулыгызны сузыгыз. Кем күпме хәйрия бирә ала... Мөмкин кадәр...

Әмма арада каты бәгырьлеләр дә юк түгел:

– Үз-үзләрен үтерүчеләр! Комикадзелар!

Шул ук сәгатьтә бу «кыяметне» оештырган авиатор Александр Васильевны генерал-губернаторга чакыртып алалар.

– Моны ни дип белергә, йә аңлатыгыз, авиатор әфәнде!

Каушап калган очучы:

– Могаен, монда һава чокыры гаепледер, – ди. Губернаторның күзләре маңгаена менә.

– Нинди чокыр ди ул тагын бии-буш һавада?!

Икенче көнне «Казанский телеграф» гәзите хәбәрчесе бу фаҗигале тагы гена аңлатып бирә: «Казан күге ятларны кабул итәргә теләмәде», – дип язып чыга ул.

Ниһаять, губернатор белән аңлашкан Васильев аэроплан янына әйләнеп кайта. Тагын да гайрәтләнеп һавага күтәрелергә теләгәнен күреп, француз механигы гаҗәпләнеп кычкырып җибәрә:

– Сез акылдан яздыгыз мәллә, мосье Алекс? – ди ул Васильевка, күзләрен шар ачып. – Шундый фаҗигадән соң...

– Менә сиңа пәрәмәч! Иске авыздан яңа сүз, – дип җавап кайтара аңа очучы, ачуын көчкә басып. – Контракт ни өчен төзелгән дип беләсең син? Әгәр мин бүген очмасам, иртәгә без синең белән, мосье Лафани, мескеннәр булып калачакбыз. Меңләгән тамашачылар акчаларын кире кайтаруыбызны таләп итсәләр, нишләрсең? Ә билетлар, мәгълүм булганча, бер атнага алдан сатылып куелган.

Һәм ул һавага күтәрелергә старт ала.

– О, гүзәл Мария! Коткар!

Механик Лафани, күзләрен йомып, өнсез кала. Очкыч мәйданында бер мәзмай бутала. Бәхеткә, күзе бар икән Васильевның: ул четерекле конструкцияле аэропланның юнәлешен үзгәртеп өлгерә. Шул косичә очкыч, мәэмай аша сикереп чыгып, җирдән аерылып китә. Инде очышның бу мизгелендә Васильевның миен тагын бер хәвефле уй борауный.

«Леон Леторның ялгышын гына кабатламаска иде», – дип борчыла ул.

Менә хәзер ул шул хәтәр биеклеккә житеп килә. Очучы очкычның кинәт төшеп китүен сизеп ала. Бу – һава чокыры. Нәкъ ул уйлаганча. Әмма очышның беренче этабы уңышлы үтә. Күрәсең, фәрештәләр аңа канат җәя.

Васильев очкычын яктайтып, 180 градуска борылып ясый һәм аны тамашачылар тезелешеп утырган трибунага таба юнәлтә. Чокыр артта калды. Аллаһның рәхмәте!

Аста аны меңләгән тамашачылар хәйран калып күзәтә. Менә очкыч дулап трибуна өстенә якынлаша. Теге фаҗигадән соң айныйгына башлаган гавам шикләнеп кала: «Бетәбез бугай. Аллам сакласын!» Ниһаять, аэроплан тамашачыларның өстеннән очып үтә. Христианнар чукына, татарлар белгәнен авыз эченнән генә укып сакалын сыпыра. Генерал-губернатор канәгать. Механик Лафани да хуҗасына мөкиббән. Әмма шатланырга иртәрәк әле.

Ипподром өстендә чыпчык канаты биеклегендә кабат бер тапкыр әйләнеп очкач та, каһарманыбыз исән-имин җиргә килеп төшә. Аэроплан – җирдә, әмма тимер кош туктап та өлгермәгән. Ипподром гөж килә.

Пропеллер туктауга, гаярь егетләр очучыны урыныннан кубарып, аны кабат-кабат югарыга чөя башлыйлар. Әле яңа гына һавадан төшкән очучы хәтта шүрләп куя.

Менә ыспай гына адъютант йөгереп килеп, Васильев әфәндене генерал-губернатор галиҗәнаплары үзенә дәшүен әйтә. Әмма халык төркеме аның үзен дә божрага ала. Тиздән атлы казаклар салган сукмакта губернә башлыгының олпат гәүдәсе күренә. Иң беренче нәүбәттә ул каһарман авиатор Васильевка генерал сөюме бирә. Аннан соң тәкәббер генә кыяфәттә ак перчаткасын салып, аның кулын кыса. Ә үзе мыек астыннан елмаеп, һаман бер сүзне кабатлый:

– Ай да, Саша! Ай да, Александр! Ай да, Васильев!

Алай гына да түгел, очучының кочагына алып, аны күкрәгенә кыса-кыса:

– Молодец, голубчик! – ди. Аннан тагын да кәефләнеп: Юк, син күтәренкәй генә түгел, ә чын бөркет икәнсең лабаса, туганкай, – дип өстәп куя.

Ниһаять, генерал галиҗәнаплары тирә-юньдә шаулашкан гавамга кор тавыш белән әре генә сүз ката:

– Туганнар! Менә ул Казан күгенә күтәрелгән безнең беренче каһарманыбыз.

Соңгы елларда Сөембикәгә багышланган аерым әдәби әсәрләр, шулай ук кайбер фәнни хезмәтләр басылып чыкты. Рабит Батулланың кыйссасында сурәтләнгән Сөембикә без белгән конкрет тарихи образга да, татар халык иҗатындагы — легендар-дастани Сөембикә образына да туры килә. Биредә тарихи Сөембикә образы белән фольклорда сурәтләнгән хыялый эпик батыр кыз Сөембикә образы бергә укмашып бирелә кебек.

Әсәрнең башында Сөембикә турында бер сүз дә юк. Кыйссаның зур бер өлеше Казанның мәшһүр шагыйре Мөхәммәдъяр һәм атаклы Таргын нәселеннән килгән Кошчык оланга багышлана. Сүз Идел вә Җаек буйларында яшәгән татарлар, нугайлар һәм башка халыклар турында бара. Шагыйрь Мөхәммәдъярның фаҗигаи тормышын, озак еллар буе Казан каласыннан еракта интегеп, тилмереп йөрүен язучы тәфсилләп сурәтли. Шуны ассызыклап әйтергә кирәк: автор нугай халкының тарихын, гореф-гадәтләрен, төрле ышануларын, гомумән, милли сыйфатларын әйбәт белә һәм ышандырырлык итеп бәян кыла.

Тарихи Сөембикәнең дөньяга килүе, балачагы, үсмер еллары турында без бик аз беләбез. Әнә шундый очракта язучы ни эшләргә тиеш? Булачак ханбикә тормышының иң матур бер чорын «атлап үтәргәме», әллә башкачамы? Рабит Батулла бу мәсьәләгә үзенчә килә. Сөембикәнең балачак вә үсмерлек елларын бәйнә-бәйнә тасвирлый. Кыйссаның йөз битен алып торган «Сөем тутай-бәгим» бүлеге нәкъ шул хакта. Әйтергә кирәк, аны рәхәтләнеп укыйсың һәм шуннан соң язучының үз әсәрен нигә кыйсса дип атавын тагын да төгәлрәк, тирәнрәк аңлыйсың. Чөнки ул чыннан да оста чичән-импровизатор авызыннан чыккан дастан-кыйссадай яңгырый, аны шул Сөембикә заманы кешесе язгандай булып тоела... Әсәрнең бу бүлегендә Сөембикә һәм аның ахирәтләре, ир-егетләр киеменә киенеп, төрле маҗаралар кичереп, Исмәгыйль морзадан үч алалар, Аблак бабаның әмир Идегәй исеме белән аталган Бүзтарланын кайтарып бирәләр. Бу үзенчәлекле күренешләр белән танышкач, бик күп халыклар иҗатында таралган амазонкалар турындагы бихисап легендалар хәтергә килә. Тик шуны искәртик: Батулла кыйссасында амазонкалар дигән сүз дә һәм алар белән бәйле легендалар турында бер генә киная да юк. Аларның кирәге дә сизелми. Чөнки сүз, ни дисәң дә, конкрет тарихи шәхес һәм аның кылган эшләре турында бара. Шулай да, минемчә, язучы әлеге легендаларның эчтәлеген, әдәби үзенчәлекләрен һәм төп фикер юнәлешен тирәнтен өйрәнгән һәм бик белеп файдалана.

Кыйссада зур гына урын алган тагын бер әкияти-мифологик сюжетка тукталып үтик. Сүз Ирәмбаг хакында. Ирәмбаг — Сөем тутайның күңелендә барлыкка килгән хыялый гүзәл бер бакча. Башта ул аны төшендә күрә һәм үзенең өлгер ахирәтләре белән Ирәмбагны эзләп юлга чыга. Тылсымлы әкият каһарманы кебек, бик озак, авыр, куркыныч юллар үтеп, Бөек моголлар империясенә барып җитә, шул данлы империягә нигез салучы Бабур һәм аның угылы Хумаюн белән очраша... Аңа гашыйк була. Әмма кавыша алмый... Бу хыялый хәлләр турында уйлагач, төрле сораулар туа: әйтик, Бабур һәм аның угылы Хумаюның үсмер Сөем тутайга ни мөнәсәбәте бар? Гомумән, үсмер Сөем тутайның ерак Һиндстанга сәяхәте мөмкинме? Язучы әкияти-мифологик сюжетлар белән артыграк мавыкмыйммы?

Билгеле булганча, Заһретдин Мөхәммәт Бабур — Һиндстандагы Бөек моголлар империясенә нигез салучы, ул 1483—1530 елларда яшәгән. Аның улы Хумаюн солтан 1508—1556 елларда яшәп, 1530—1540 елларда шул ук империянең хөкемдары була. Әсәрдә бу тарихи фактлар төгәл аталмаган, әмма Сөем тутайның озын гына монологы аша язучы үз каһарманының нәсел җепләре (шәҗәрәсе) турында бай гына мәгълүмат бирә. Сөем тутай, соңрак Казанның мәшһүр ханбикәсе Сөембикә — татар тарихында фаҗигаи бер урын алган Тимерләнк (Аксак Тимер) белән әмир Идегәйнең торыны икән. Хумаюн да Тимерләнкнең, кайчандыр ярты дөньяны дер калтыратып торган Аксак Тимернең торыны икән. Шулай булгач, Мөхәммәт Бабур, Хумаюн солтан һәм Сөембикә — барысы да якын туганнар булып чыга! Әнә кайларга барып тоташкан икән гүзәл Сөем тутайның нәсел җепләре!

Солтан Хумаюн да, әйтелгәнчә, конкрет тарихи шәхес. Тик шуны гына искәртеп үтик: борынгы Шәрык мифологиясендә Хумаюн — Гамаюн — Хумай бәхет кошы. Мифология мәгълүматларына караганда, башына Хумай-кош шәүләсе төшкән зат киләчәктә атаклы хөкемдар булачак. Кыйссадагы Хумаюнның шәүләсе Сөем тутайга төшә һәм, бераз вакыттан соң, ул Казанның мәшһүр ханбикәсе булачак. Шулай итеп, язучы үзенчәлекле мифологик сюжетлар ярдәмендә безгә Сөем тутайның, вакытлыча гына булса да, бәхетле киләчәген искәртеп куя.

Кыйссаның иң җитди өлеше, һичшиксез, «Кайный Казан каласы» дигәне. Әгәр баштагы бүлекләрдә әкияти-мифологик һәм легендар-эпик сюжет вә мотивлар, образлар зур урын алып торса, соңгы бүлектә алар юк дәрәҗәсендә аз. Чөнки вакыйгалар кырыс, киеренке, фаҗигале. Бу вакыйгаларның тарихи нигезләре, барышы хакында биредә тәфсилләп сөйләп тору кирәкмәстер: аларның күпчелеге турында соңгы елларда кат-кат язылды, языла килә. Шуңа күрә, әле күптән түгел генә четерекле, каршылыклы дип каралган кайбер мәсьәләләргә генә тукталып үтик. Шуларның берсе — Сөембикәнең Казандагы тормышы. Иркен Нугай далаларында туып үскән, шунда азатлык рухы ныгыган Сөем тутай, Казан ханы Җан Галигә кияүгә чыккач, башкалага күчеп килә, аны сагынып, үз итеп килә. Килгәч тә, озак вакыт узмый, биредә — Казан аксөякләре, түрә-морзалар арасында — үзенә лаек урын яулый. Сөембикәнең беренче ире булган Җан Галинең умырткасыз, җебегән бер бәндә булуын без элек тә белә идек. Кыйссада Җан Галинең бу сыйфатлары конкрет күренешләр ярдәмендә сурәтләнә.

Әмма Сөембикәнең чын бәхете Сафа Гәрәй ханга кияүгә чыккач башлана. Ничек кенә булмасын, Сөембикә Сафа Гәрәй хатыны буларак кына чын ханбикә дәрәҗәсенә күтәрелә. Гомумән, Сөембикәнең шәхси бәхетен, хан белән ханбикәнең әчкерсез тирән мәхәббәтен сурәтләгән күренешләр Батулла китабының иң уңышлы вә иң

Кыйсса-и Сөембикә

көчле битләреннән булса кирәк.

Тарихтан билгеле булганча, Сафа Гәрәй хан Сөембикәнең беренче һәм соңгы мәхәббәте. Сөембикәдәй гүзәл акыл иясе мәхәббәтенә лаек булган икән, үзенең рухи сыйфатлары ягыннан Сафа Гәрәй хан Сөембикәдән һич тә ким булмаска тиеш. Билгеле булганча, безнең тарих фәнендә әлегә кадәр Сафа Гәрәй ханга объектив бәя бирелгәне юк. Кайбер галимнәр әле хәзер дә Казанның тарихи фаҗигасендә Сафа Гәрәй хан һәм аның халыкара сәясәте, бигрәк тә Мәскәү кенәзлеге белән мөнәсәбәте гаепле, дип язмакчы булалар. Ә бит тирәннәнрәк уйласаң, әгәр Сафа Гәрәй 1549 елда, нибары 42 яшендә фаҗигале рәвештә һәлак булмаса, бәлки Казан ханлыгы тарихы да башкачарак юлдан китәр иде. Язучы бу хакта, минемчә, бик хаклы рәвештә, болай ди: «Сафа Гәрәй хан тәхеттә булганда Казан беркайчан да Мәскәүгә буйсынмаячак. Сафа Казанның соңгы ханнары арасында иң усалы, иң батыры, каты рухлысы иде». Рабит Батулланың тарих фәнендә һәм әдәбият тарихында беренчеләрдән булып Сафа Гәрәй ханны чын-чыннан эпик баһадир дәрәҗәсенә күтәрүе һәм шул бисклектән бер бармак та түбәнәйтмәве — аның иҗади ачышы, хупларга лаек яңа сүзе.

Сафа Гәрәйнең кем тарафыннан һәм ничек үтерелүе турында әлегә төгәл мәгълүмат юк. Шуңа карамастан, Батулла үзенең тирән уйланылган, үзенчәлекле фаразын тәкъдим итә. Ни хикмәттер, укучы аңа бу очракта да берсүзсез ышана. Чөнки язучы ышандыра белә...

Сафа Гәрәй һәлак булгач, Казан каласы да, Сөембикә дә ятим калалар. Ханбикәнең кара вә караңгы еллары башлана. Мәскәү баскынчыларының ел саен яу чабып торуына, Казан түрә-морзалары арасында тызгыш-талаш-бәрелешләр туктаусыз дәвам итүгә карамастан, Сөембикә бер дә югалып калмый. Сафа Гәрәй васыяте буенча, сабый Үтәмеш Гәрәй хан итеп билгеләнә. Мәскәүнең туктаусыз баскынчылык сәясәтен күреп торгач, Сөембикә Мәскәүгә — Явыз Иванга бер-бер артлы махсус илчеләр җибәрә: башта — Бахшандыны, аннан соң — Дәүләтъярны. Әмма кансыз Иван инде Казанны хәрби көч белән яулап алу ниятеннән һич тә кире кайтырга уйламый. Сөембикәнең әлеге дипломатик адымнары нәтиҗәсез кала. Казан үзе генә Мәскәүгә каршы сугышта мөстәкыйльлеген саклап кала алмаячагын яхшы аңлаган ханбикә әтисе Йосыф бәккә, Юныс вә Гали морзаларга да хат язып карый. Алары да кирәкле нәтиҗә бирми. Явыз Иван тагын бер тапкыр Казанга яу чаба. Авыр хәлдә калган Сөембикә Казанны соңгы тамчы канга кадәр саклау кирәклеге турында халыкка махсус нотык белән мөрәҗәгать итә һәм Мәскәүнең кансызлыгы, комсызлыгы хакында сөйли, Мәскәү безне гасырлар буе имәчәк дип, урыс баскынчыларына каршы «актык тамчы кангача орыш!» игълан итә.

Әнә шундый шартларда Казанның төп яклаучыларыннан һәм саклаучыларыннан берсе һәм соңгысы булып Кошчак угълан кала... Нәрсә генә, нинди генә гайбәтләр язылмады безнең тарихта мәшһүр Кошчак угъланга карата! Ничек кенә хурларга, кимсетергә, рәнҗетергә тырышмадылар аны! Шатлыгыбызга, Рабит Батулла бу мәсьәләгә дә бөтенләй башкача, үзенчә, ә бәлки чыннан да тарихта булганча килә һәм атаклы Таргыннар нәселеннән булган Кошчак угъланны баштан ахырга кадәр тик уңай яктан гына сурәтли. Һәм бик дөрес эшли! Кошчак угълан гомере буе Казанның азатлыгы, милли мөстәкыйльлеге өчен дастан батырларына хас көч вә гайрәт, тугрылыклылык белән көрәшә, сугыша, чын ирләрчә сансыз күп батырлыклар күрсәтә; фаҗигаи бер сугышта тоткынлыкка эләгә, Мәскәүгә озатыла һәм шунда, чукынудан баш тарткач, ерткычларча җәзалана.

Казанның иң куркыныч шартларда калуын күреп торган Булат бәк Ширин халкына тагы да әшәкерәк хыянәт кыла: Сөембикәне үз кулы белән урыс баскынчыларына тотып бирә.

Ханбикәнең Явыз Иван белән беренче очрашуы, падишаһның аңа мөнәсәбәте турында тарихта әлләни мәгълүмат юк. Аерым фикерләр, күзәтүләр тик халык легендаларында гына сакланган. Шуңа күрә Сөембикәнең соңгы елларын сурәтләгән сәхифәләр дә нык кына уйландыра. Биредә язучы, күрәсең, халык эпосы традицияләренә таянып эш итә. Халык кыйсса-дастаннарында да эпик батыр, ир-егетме ул, хатын-кызмы, әсирлеккә эләгә һәм гаять тә авыр кыенлыклар кичерә. Язучы да, күрәсең, әнә шул традицияләрне дәвам итерә: әсәр чыннан да халыкчан кыйсса кебек яңгырый. Мәсьәләнең бу ягына тагын бер тапкыр игътибар итүебез сорала: сүз халык кыйссасы турында барамы, әллә китаби кыйсса хакындамы — бу төр әсәрләрдә, гадәттә, баштан ахырга кадәр үткән даими шигъри образлар системасы зур урын ала. Шундый образлар системасы Рабит Батулла кыйссасында да бар. Баштан ук, халыкның бик борынгы карашлары белән бәйләнгән вакыт символикасына тукталып, шуны әйтеп үтик: 1530 ел бу яктан аеруча зур әһәмияткә ия. Шул елда Койрыклы йолдыз галәмәте була! Җир тетри! Шул ук елда Заһретдин Мөхәммәт Бабур бу дөньядан китә. Һәм иң куркынычы — шул ук елда җиргә тагы бер Дәҗҗал килә — Явыз Иван туа!.. Әсәрдә гаять тә уңышлы кулланылган образлардан халык мифологиясендә дә киң таралган һәм язучы тарафыннан иҗади сайланган мәет кошы Каракош белән бәхет кошы Хумайны, шагыйрь Мөхәммәдъяр белән Кошчак оланның серле сорнаен, атаклы Идегәйнең аты Бүзтарланны, аерым төрки ыру-кабиләләренең тамгалары-символларын, әсәрнең буеннан-буена узган «Янмас кыз Гайшәбикә бәете»н телгә алып, аларның һәркайсы турында киңәеп, тәфсилләп, рәхәтләнеп сөйләргә мөмкин булыр иде. Әмма сүз бик озынга китмәсен дип, мин тик бер генә шигъри образга киңрәк тукталмакчы булам. Сүз төрки-татар илләренең тарихи язмышын чагылдырган ватык көзге образы хакында бара. Билгеле булганча, тарихи әсәр язарга алынган язучыга талантлы каләм остасы булу гына җитми. Ул тирән һәм киң белемле галим дә булырга тиеш. «Сөембикә» кыйссасын укып чыккач, мин шундый бер фикергә килдем: Рабит Баулла — талантлы язучы да, киң һәм тирән белемле галим-тарихчы да! Әле генә телгә алынган ватык көзге образы — моның ачык мисалы. Һәрбер төрки-татар иле XY—XYI йөзләрдә ватылган көзгене хәтерләтә. Аларның һәркайсының үз эчендә дә, дәүләтара мөнәсәбәтләрдә дә үзара туктаусыз сугышлар дәвам итә. Әнә шундый вакыйгалар турында тәфсилләп язгач, Батулла мондый нәтиҗәгә килә: «Олугъ Урданы, Нугайны, Хаҗитарханны, Кырымны, Казанны харап иткән төп сәбәпләрнең берсе шул булыр». Төрки-татар дәүләтләрен харап иткән башка сәбәпләр турында уйлана башласаң, Мәскәү урысларының кансыз колониаль сәясәтен дә истән чыгарып булмый. Әлеге илләрнең барысы да, хәтта башка күп кенә мөселман илләре дә, Рәсәйнең колонияләренә әверелләләр. Рәсәй аларны гасырлар буена имеп ятуын дәвам итә. Ә инде кайчандыр яулап алынган илләрнең берәрсе әлеге колониаль изелүдән котылыйм дип уйласа, Мәскәү үзенең XYI—XIX йөзләрдәге колониаль сәясәтен бүген хәтта тагын да ямьсезрәк төстә дәвам итерә. Моның ачык мисалы — безнең көннәрдә бер гаепсезгә тәмам җимерелгән Ичкерия Республикасы.

Фатих УРМАНЧЕ,
филология фәннәре докторы, профессор.

Атналык манзара TV

Дүшәмбе

4 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.35 Балалар өчен «Тамчы». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.40 «Түгәрәк өстәл». Реформалар программасы: ул нинди булыр? 20.20 «Әлли-бәлли-бәү». 20.40 Шәриф Камал. «Әдәби театр». 21.15. Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты. (Хор группасы). 21.35 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

6.45 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Приключения пингвиненка Лоло». 1 нче серия. 7.30 «КиноМеню». 8.00, 10.50 — «Юл патруле». 8.10, 11.30 — «Даруханә». 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.00, 13.25 — «90х60х90». 9.15 Мультсериал: «Еноты». 9.40 Нәфис фильм: «Старая крепость». 7 нче серия. 11.05 Сәбәпсез спорт. 11.40 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.05 Нәфис фильм: «Рожденная революцией». 10 нчы серия. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 Атна һәлакәтләре. 15.05 «Минем кино». Армен Джигарханян. 15.50 «Фитиль». 16.00 Нәфис фильм: «Когда наступает сентябрь». 17.40 «Минем йолдыз». Аркадий Вайнер. 18.30 «Бүгенге Европа» тележурналы. 19.00 «Эфирда — музыка». 19.15 «Актуаль әңгәмә». Милли мәктәпләр проблемалары. М.В.Лотфуллин. 19.30 «Видеомода». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 22.25 — «Шәһәр» информацион программасы. 20.45 «Телеэкспресс». 21.10 Нәфис фильм премьерасы: «Прах и кровь». 1 нче серия (Франция—Италия—Германия). 22.00 «Криминаль хроника» тележурналы. 22.50 Нәфис фильм: «Кровавый камень» (АКШ). 0.25 «Европадан — 20».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.25 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Могҗизалар кыры». 11.00 «Кеше һәм закон». 11.25 «Телемемуарлар». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Место встречи изменить нельзя». 14.05 Мультсериал: «КОАПП». 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 Мультсериал: «Отверженные». 16.25 «Йолдызлар сәгате». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.30 «Тет-а-тет». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.05 «Без». В.Познерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 А.И.Солженицын белән очрашу. 22.10 Телесериал: «Гиганты второй мировой». 22.55 «Юрамалар». 23.15 «Футбол күзәтү». 23.45 Э. Радзинский. «Тарих табышмаклары».

«РОССИЯ»

7.30 Эшлекле кешеләр вакыты. 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 Нәфис фильм: «Желтый пес» (Франция). 10.15, 12.10 Клип-антракт. 10.25 Документаль фильм: «Личная жизнь». 11.05 Милиция хроникасы. 11.15 «Телегазета». 11.20 Мульти-пульти. 11.50 Документаль фильм: «Братья Третьяковы». 12.15, 17.20 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 Мульти-пульти. 17.50 «Минем сугыш». А.Ивашенко. 18.20 «Алыргамы — алмаскамы». 18.30 «Коткару-911». 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Нәфис фильм: «Обманный удар» (Бөекбритания). 21.40 Репортер. 22.00 «Хакыйкать мизгеле». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Нәфис фильм: «Берлин. Александр Платц».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Такмаклар». 11.15 «Коллекционерлар». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.25 Музыкаль телефильм: «Три такта». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.40, 18.05 «Музыка мизгеле». 15.45 Безнең кино. Нәфис фильм: «Нелюдь, или В раю запрещена охота». 18.10 Документаль фильм: «Новая Южная Африка». 21.35 Д.Н.Мамин-Сибиряк. Видеофильм: «Под липой». 22.20 «Шәһәр эшләре». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 Музыкаль шоу: «Телекомпакт».

Сишәмбе

5 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.25 Мультфильм. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 Күп серияле нәфис фильм премьерасы: «Тарзан». 20.25 «Әлли-бәлли-бәү». 20.35 И.Байтирәк. Симфония. 20.55 И.Юзеев. «Сирень чәчәге». 21.05 «Сандугач» җыр фестивале. 22.20 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!». 7.10 Мультфильм: «Приключения пингвиненка Лоло». 2 нче серия. 7.30, 20.20, 0.00 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (4 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.10, 13.35 — «90х60х90». 9.25 Мультсериал: «Еноты». 9.50 Балалар сериалы: «Неоновый всадник». 1 нче серия. 11.10 «Юл патруле». 11.15 Атналык фаразлар. 11.40 «Даруханә». 11.55, 18.35 — «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.15 Нәфис фильм: «Большая перемена». 1 нче серия. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Минем кино». Александр Ширвиндт. 15.05 «Музыка һәм матбугат». «Каләм осталары». Юрий Антонов. 15.55 «Современник» театры спектакле: «Обыкновенная история». 18.50 «Эфирда — музыка». 19.00 Бөтендөнья телепремьерасы. Сериал: «Против течения». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.40 «Спорт-ревю». 20.55 «Телеэкспресс». 21.15 «Коммерция әйләнмәсе». 21.40 Казан автосалоны. 22.10 Русия киносы көне. А.Абдулов һәм А.Макаревич «Сумасшедшая любовь» нәфис фильмында. 0.25 «TAP RECORDS» коллекциясеннән. «INXS» группасы (Австралия).

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.45 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Без». В.Познерның авторлык программасы. 10.50 «Көлкеле манзара». 11.35 «Ел буе яшелчә бакчасы». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Место встречи изменить нельзя». 14.10 Мультсериал: «КОАПП». 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Футбол күзәтүе». 16.00 «Кара, тыңла». 16.20 «Кактус һәм К». 16.30 «Кварьете — күңелле квампания». 16.40 «Сер итеп кенә». 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Джем». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 «Беренче куллардан». 22.10 Н.Мордюкова һәм М.Ульянов «Простая история» фильмында. 23.45 «Юрамалар». 0.00 «Кабаре — барлык йолдызлар».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 10.55 «Телегазета». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 «Арсений Тарковский». К.Ваншенкин истәлекләре. 11.40 Клип-антракт. 11.45 Мультсериал: «Камень сновидений». 12.15, 17.20 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «РОСТ» студиясе. Артекта кинофестиваль. 16.50 «Ай тотучы». 17.50 Мультсериал: «Камень сновидений». 18.20 «Беркем дә онытылмаган». 18.25 «Телебәхәсләр». 19.10 «L» клубы. 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Нәфис фильм: «Приглашение». 22.30 «Бию-экспресс». 22.50 Криминаль хәбәрләр экраны. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Нәфис фильм: «Берлин. Александр Платц».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә».
8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 10.00
«Төш юрау». 10.45 «Кумирлар». 11.15 «Аукцион». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00,
15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.25
Мультфильмнар. 13.50, 15.40 «Музыка мизгеле». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.10 «Бакчачыларга
киңәшләр». 15.45 Нәфис фильм: «Пэпо».
17.15 Телефильм: «И хлеб, и песня». 17.45
«Россия — Женеваның үзәгендә». 18.05 «Бөтен Россия буйлап». 22.20 «Чегән җырлары
концерты». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...»
23.15 Совет Армиясенең Үзәк академия театры спектакле: «Все о Еве». 1 нче кисәк.

Чәршәмбе

6 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.50 «Ералаш» киножурналы. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Турыдан-туры элемтә». Телевизор караучыларның сорауларына Казан шәһәре һәм районнары хакимият башлыклары җавап бирә. 20.35 «Әлли-бәлли-бәү». 20.45 Татар халык моңнары. 20.55 Киноның 100 еллыгына. Нәфис фильм: «Король Лир». 1 нче серия. 21.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

6.50 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Приключения пингвиненка Лоло». 3 нче серия. 7.30, 20.20, 0.20 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (5 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.10, 13.35 — «90х60х90». 9.35 Мультсериал: «Еноты». 10.00 Балалар сериалы: «Неоновый всадник». 2 нче серия. 11.00, 18.20 — «Юл патруле». 11.15 «Атна низаглары». 11.40 «Даруханә». 11.55, 18.00 — «ПОСТ» — музыка яңалыклары». 12.15 Нәфис фильм: «Большая перемена». 2 нче серия. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Минем кино». Михаил Державин. 15.05 Нәфис фильм: «Осень». 16.45 Рей Бредбери: «Җир кешеләре». 17.10 Детектив сериал: «Таггерт». 18.30 «Филләр уены». 19.00 «Эфирда — музыка». 19.10 Нефть нигез салган шәһәр. Лениногорскиның 50 еллыгына. 19.25 «Поза». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 Телеэкспресс. 21.05 «Валаам». 21.15 «Бөтенләй башкалар»: рәссам Лена Раушева. 21.35 «Үз кешеләр». 22.10 Марлен Жобер «Пассажир дождя» нәфис фильмында. 1 нче һәм 2 нче серияләр.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.30 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Тема». 10.50 «Хайваннар дөньясында». 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Место встречи изменить нельзя». 14.05 «Мультсериал: «КОАПП». 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 «Күңелле ноталар». 16.20 «Шулай бервакыт». 16.30 «Ник һәм нигә?» 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Тин-тоник». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Җыр-95». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Футбол. Европа чемпионатына сайлап алу матчы. Фарер утраулары җыелма командасы — Россия җыелма командасы. Тәнәфестә (22.45) «Юрамалар». 0.00 «Тылсым-шоу».

«РОССИЯ»

8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Ритмика». 8.45 «Кирәк... кирәк...» 8.50 Клип-антракт. 8.55 «Төп мизгел». 9.05 «Пилигрим». 9.50 Р.Вагнер. «Тангейзер» операсына увертюра. 10.05 Документаль фильм: «Сталинградские мадонны». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Телегазета». 11.10 XX гасыр кадрда һәм кадр артында. 12.15, 17.20 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Кем ягы?» 17.50 Мультфильмнар. 18.15 Әдәби-публицистик цикл премьерасы: «Россия. Мәхәббәттә аңлашу». 18.45 «Мин — әйдәп баручы». 19.10 «Савва» фирмасы чакыра. 19.25 «Үз уены». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 Михаил Боярский доминосы. 22.05 «Тын йорт». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Кыска метражлы нәфис фильмнар.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Такмаклар». 11.15 «Аукцион». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.25 Мультфильм. 13.35 Телефильм: «М.Глинка. Романсы. Исполняет А.Ведерников». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.15 Бакчачыларга киңәшләр. 15.40, 17.05, 22.30 «Музыка мизгеле». 15.45 Д.Н.Мамин-Сибиряк. Видеофильм: «Под липой». 17.10 Мультфильм. 17.30 «Нәни йолдызчыклар». 18.00 Баскетбол. Россия чемпионаты. Суперлига. 18.40 А.Невскийның тууына 775 ел тулуга карата. 21.55 «Блеф-клуб». 22.15 Хатирәләребез җырлары. В.Баснер. 1 нче тапшыру. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 «Гыйбадәтханә». 23.40 Совет Армиясенең Үзәк академия театры спектакле: «Все о Еве». 2 нче серия.

Пәнҗешәмбе

7 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.20 Телефильм: «Волшебный журавль». 18.50 «ГАИ» мәгълүматлары. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Хөкүмәт сәгате». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «Шигърият». Зөлфәт. 20.30 «Бәйрәм» ансамбле концерты. 21.30 Киноның 100 еллыгына. Нәфис фильм: «Король Лир». 2 нче серия. 22.30 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Полигон», «Бюро находок». 1 нче кисәк. 7.30, 20.20, 23.30 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (6 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.10, 13.35 — «90х60х90». 9.25 Мультсериал: «Еноты». 9.50 Балалар сериалы: «Неоновый всадник». 3 нче серия. 11.00 «Юл патруле». 11.15 CNN. «Стиль». 11.40 «Даруханә». 11.55 «ПОСТ» — музыка яңалыклары». 12.15 Нәфис фильм: «Большая перемена». 3 нче серия. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. «Бизнес яңалыклары». 14.30 Петр Шепотинник «Кинескоп»ы. 15.05 «Ток-шоу». «Мин үзем». «Иремне бәлдерү буенча таптым». 16.05 Нәфис фильм: «Осенние свадьбы». 17.25 Детектив сериал: «Таггерт». 18.20 — «Эфирда — музыка». 18.30 Мультфильм: «Синяя птица». 19.20 «Ушуайя». 19.40 «Кыюлар һәм матурлар». 21.10 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә. 20.45 «Телеэкспресс». 21.05 «Коммерция әйләнмәсе». 21.30 Атна фильмы. Бурвиль «Рыболов» нәфис фильмында (Франция). 23.55 «Битлек-шоу».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.50 «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Җыр-95». 10.50 «Сәяхәтчеләр клубы». 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Место встречи изменить нельзя». 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 Мультитроллия. 16.20 «Золушкада балда». 16.40 «Тылсымлы дөнья, яки Синема». 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята». 17.30 «16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәкләр...» 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 «Лотто-миллион». 20.20 «Рус французы». Э.Рязановның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 «Мәскәү-Кремль». 22.15 Нәфис фильм: «Уик-энд в Зюйдкоте». 0.30 «Юрамалар».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 Клип-антракт. 9.00 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 Телегазета. 11.20 Безнең хәбәрчедән. «Тарихи элегияләр». 11.35 Е.Образцова җырлый. 11.50 Мультсериал: «Камень сновидений» (Бөекбритания). 12.15, 17.20 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Могҗизаларга ярты сәгать». 17.50 Мультсериал: «Камень сновидений». 18.15 «Беркем дә онытылмаган». 18.20 «Сезнең хокук». 18.35 «Безнең бакча». 19.05 «Сәяси олимпига». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Хроно». 22.05 «Гадәттән тыш канал». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 «Киношок-95». 0.30 Криминаль хәбәрләр экраны.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 10.15 «Төш юрау». 11.15 «Аукцион». 12.15 «Спартак». 12.40 «Кунак». 16.00 Телесериал: «Мануэла». 16.45 «Бакчачыларга киңәшләр». 16.55, 17.50 «Музыка мизгеле». 17.00 «Палитра» циклыннан телефильм: «Евфроний» (Франция). 17.30 Мультфильм. 17.55 «Бөтен Россия буйлап». 18.05 «А.Невскийның тууына 775 ел тулуга карата». 22.30 «Санкт-Петербург телевидениесе». 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 Хоккей. МХЛ чемпионаты. «Крылья Советов» (Мәскәү) — «Северосталь» (Череповец). 2 нче һәм 3 нче периодлар.

ҖОМГА. 8 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.00 Мультфильмнар. 18.40 «Архитектурага сәяхәтләр». Пушкин Казанда. 2 нче тапшыру. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Видеоспорт». 19.45 «Әлли-бәлли-бәү». 20.00 «Ислам чакыруы». 20.10 «Җомга кон кич белән». Альманах. 21.00 Р.Вәлиев. Телефильм премьерасы. «Яшисе килә». 1 нче бүлек. 22.15 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Бюро находок». 2 нче, 3 нче кисәкләр. 7.30, 20.20, 22.05 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 «Телеэкспресс» (7 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!». 9.25, 13.35 «90х60х60». 9.40 Мультсериал: «Еноты». 10.05 Балалар өчен сериал: «Неоновый всадник». 4 нче серия. 10.55, 18.20 Юл патруле. 11.10 «Атнага бер тапкыр» юмористик программасы. 11.40 «Дарухәнә». 11.55, 18.00 «ПОСТ — музыка яңалыклары». 12.15 «Большая перемена». 4 нче серия. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Нью-Йорк, Нью-Йорк». 15.05 Нәфис фильм: «Вооруженный отпор». 16.35 Рей Бредбери. «Гетицберг җиле». 17.05 Сериал: «Филипп Марлоу — частный детектив». 1 нче серия. 18.35 Эфирда — музыка. 18.40 «Суперспорт». 19.00 Сериал премьерасы: «Корабль любви». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 Телеэкспресс. 21.05 «Экология хәбәрчесе». 22.30 Джекки Чан «Крестный отец из Кантона» (Гонконг) нәфис фильмында. 0.15 Нәфис фильм: «Голубая лагуна».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.55 — Яңалыклар. 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Рус французы». Э.Рязановның авторлык программасы. 10.50 «Балачак бәйрәмнәре». 11.35 Телеуен: «Мине анла». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Место встречи изменить нельзя». 14.25 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде коне». 16.00 Балалар өчен телесериал: «Белый клык». 16.25 «Орфей йолдызлыгы». 16.35 «Яңа чыпбарлык». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 «Рок-дәрес». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Кыргый кыр». 19.25 «Кеше һәм закон». 19.55 «Могҗизалар кыры». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 А.Папанов һәм А.Миронов «12 стульев» телесериалында. 23.10 «Юрамалар». 23.30 «Караш». 0.25 Музыкаль күзәтү. 1.05 Волейбол. Россия чемпионаты. Ир-атлар. Русия һәм Чехия җыелма командалары.

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Хакыйкать мизгеле». 9.40 Клип-антракт. 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 «Телегазета». 11.20 «Топ мизгел». 11.30 Сәүдә йорты. 11.45 Мультфильм: «Электрический человек». 12.10 Клип-антракт. 12.15, 17.20 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Көнгерә». 16.50 «Ай тотучы». 17.50 Нәфис фильм: «Зорро». 18.45 Мульти-пульти. 18.55 «Русча караоке». 19.25 Вертикаль. «Хөкүмәтнең эш коннәре». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Борын». Юмористик программа. 22.05 «К-2» тәкъдим итә: «Европа телевидениесе осталары «Абзац» программасында. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 Нәфис фильм: «Неоткрытая страна».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 «Балалар өчен». 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Кумирлар». 10.45 «Такмаклар». 11.15 «Коллекционерлар». 12.10 Джаз. 12.40 «Купак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.30 Телефильм: «Сегодня в цирке». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телесериал: «Мануэла». 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.45, 17.05 «Музыка мизгеле». 15.50 Нәфис фильм: «Бабник». 17.10 ТВ мәгълүматлары. Европа калейдоскобы. 17.40 «Бәллүр ачкыч». Музыкаль клиплар фестивале. 22.20 В.Виноградов фильмнары: «Про то, про се». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 Нәфис фильм: «Вчера, сегодня, завтра» (Италия).

ШИМБӘ. 9 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «Татарстан». 19.30 Телефильм: «Мой голос для тебя». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 Р.Вәлиев. Телефильм премьерасы. «Яшисе килә». 2 нче бүлек. 21.15 Ял концерты. 21.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 Эфирда — музыка. 7.30 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (8 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.10 «Коммерция әйләнмәсе» (5 сентябрь көнендәге тапшыруны кабатлау). 8.35 «Автомобильдән саклан!» 8.45 «Казан автосалоны»: 9.15 «700 нче клуб». «Җаваплар». 9.50 Мультсериал: «Д Артаньган и три пса-мушкетера». 10.15 Нәфис фильм: «Выше радуги». 1 нче серия. 11.30 «Чаплиниада». «За кулисами экрана». 12.00 Хәрби телевидение. 12.30 «Спорт атнасы». 12.50 Мультфильм: «Следствие ведут знатоки». 14.05 Мюзикл «Ламбада» (АКШ). 15.40 «ПОСТ — музыка яңалыклары». 16.00 Юл патруле. 16.10 «Югарыда — йолдызлар гына». 16.45 Телесериал: «Тропическая жара». 17.40 Телесериал: «Детективы на полставки». 18.35 «Яшерен йомыш». 19.00 «Исәнмесез!». 21.00 «Мавыгулар доньясы». 21.30 Сериал: «Сирень» (АКШ). 22.30 Майкл Дуглас «Кордебалет» нәфис фильмында.

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 8.45 «Пастырь сүзе». Митрополит Кирилл. 9.00, 15.00, 1.35 Яңалыклар. 9.20 «Джунглилар чакыруы». 9.50 Балаларга фильм: «Секреты моего лета». 10.15 Мультфильм. 10.25 «Иртәнге почта». 11.00 «Татлы». 11.15 «Сәламәтлек». 11.45 Провинция. 12.15 «Бомонд». 12.40 Гойко Митич «Сыновья большой медведицы» фильмында. 14.25 «Көзге». 15.20 «Зур залда». 15.45 «Алтын калр». И.Андроников. 16.30 «Хайваннар доньясында». 17.05 «Бәхетле очрак». 18.10, 21.00 «Вакыт». 18.20 «Мәңгелек актер». Е.Капелян. 19.05 Джоди Фостер «Жена мистера О Хары» фильмында (АКШ). 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Телесериал: «Двенадцать стульев». 23.10 «Брейн-ринг». 23.55 «Ана кадәр һәм аннан соң». В.Молчанов алып бара. 0.50 Волейбол. Россия чемпионаты. Ир-атлар. Русия һәм Польша җыелма командалары.

«РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Шөрептән башлап». 8.45 «Озынайтылган көн». 9.00 Документаль фильм: «Великий русский праздник». 9.20 «Пилигрим». 10.05 Нәфис фильм: «Приключения Маленького Мука». 11.15 «Ничек яшәрбез?» Телевизор караучылар сорауларына Русия Федерациясе эчке эшләр министры А.С.Куликов һәм Эчке эшләр министрлыгы коллегиясе әгъзалары җавап бирә. 12.35 «Барлык кешеләр өчен музыка». 13.05 А.Гурнов. «Саф инглизчә репортаж». 13.15 «Без кем». Ватан калканы — аналар җыры. 14.20 «Де факто». 14.35 Нәфис фильм: «Неудача Мегрэ». 15.30 «Хайваннар доньясында». 16.25 «Америка йолдызлары». 16.55 Футбол. Россия чемпионаты. «Спартак» (Владикавказ) — «Торпедо» (Мәскәү). 18.55 «Сергей Есенин. Соңгы шагыйрь». 19.10 Хатын-кызлар арасында ирекле көрәш буенча доньмя чемпионаты. 20.25 Нәфис фильм: «Устрицы из Лозанны». 21.45 Киноафиша. 22.05 «Үтә яшерен». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «Киношок-95».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.30 «Христос — бөтен доньяда». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан-туры элемтә». 10.00 Мультфильмнар. 10.25 Нәфис фильм: «Не помню лица твоего». 11.50 О.Ерышев фильмнары. «Я вновь перед тобою стою очарован». 12.20 «Теледоктор». 12.40 «Рандеву». Дмитрий Маликов. 13.10 «Тарихи альманах». 13.40 Объектив. 14.00 Тест. 14.15 Нәфис фильм: «Я, бабушка, Илико и Илларион». 15.45 Юнгер моноспектакле: «Я была счастлива, счастлива, счастлива...» 16.50 Балалар өчен нәфис фильм: «Как Иванушка-дурачок за чудом ходил». 18.15 «Хыялпан» студиясе. 18.25 «Антре». Цирк программасы. 21.55 «Оранж-ТВ». «Теләмәсәң — карама». 22.40 ТВ мәгълүматлары. 23.05 Нәфис фильм: «Ночь с вампиром» (АКШ).

ЯКШӘМБЕ. 10 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан» информацион программасы. 17.05 Р.Батулла. «Салават күпере». Казан Дәүләт курчак театры спектакле. 17.50 Нәфис фильм: «Как поссорились Иван Иванович с Иваном Никифоровичем». 19.00 «ТОН» (атналык телекүзәтү). 19.35 «Автокалейдоскоп». 19.50 «Программа-2». 20.05 Телебуклет. Тапшырулар анонсы. 20.15 «Әлли-бәлли-бәү». 20.35 Телефильм: «Йортыбыз — Татарстан». 21.05 «Кич утырып сиңа җырлар яздым». Концерт. 22.05 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау). 8.35 «Коммерция әйләнмәсе» (7 сентябрь тапшыруын кабатлау). 9.00 «Поза». 9.30 Мультсериал: «Сказки братьев Гримм». 9.55 Нәфис фильм: «Выше радуги». 2 нче серия. 11.15 «Чаплиниада». «Реквизитор». 11.35 Кино музыкасы. 12.00 «Минем кино» Виктор Мережко белән. 12.25 Нәфис фильм: «Моя любовь». 13.45 Кино музыкасы: «Алтын коллекция». 14.10 «Нью-Йорк, Нью-Йорк». 14.45 Телесериал: «Подводная «Одиссея» команды Кусто»: «Последние сирены». 15.35 «Атна һәлакәтләре». 16.05 «Фитиль». 16.15 Нәфис фильм: «Новые приключения неуловимых». 17.35 Эфирда — музыка. 17.45 Телесериал: «Тропическая жара». 18.45 Телесериал: «Детективы на полставки». 19.45 «КиноМеню». 20.15 «Җирле вакыт». Информацион программа. 20.45 Стюарт Пол, Патрик Райт «Эманон» нәфис фильмында. 22.35 Юл патруле. 22.50 «Мәңге сакларга». 23.35 «Исәнмесез!» (8 сентябрь тапшыруын кабатлау).

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 9.00, 15.00, 1.50 Яңалыклар. 9.20 «Иртә таңнан». 9.50 Мультфильм. 10.10 «Бар да өйдә чакта». 10.45 «Иртәнге йолдыз». 11.30 «Россиягә хезмәт итәм». 12.00 Телесериал: «Лики Земли». 12.45 «Бөтен Россия». «Рус доньясы». 13.10 «Пи» билгесе астында. 13.50 Киноцирк-шоу. «Тулы көчендә». 15.20 Мариинскийда променад. 16.10 «Сәяхәтчеләр клубы». 17.05 «Америка М.Таратута белән». 17.35 Мультсериал: «Приключения капитана Врунгеля». 18.00 Вакыт. 18.20 «Кумирлар, кумирлар...» Раймонд Паулс. 19.10 «Күзгә-күз». А.Любимов алып бара. 19.40 Рейчел Уэлч «Принц и нищий» фильмында (АКШ). 22.00 «Якшәмбе». 22.50 «Спорт яңалыклары». 23.05 Телесериал: «Двенадцать стульев». 0.30 «Бер күрүдә ярату». 1.00 Волейбол. Россия чемпионаты. Ир-атлар. Русия һәм Румыния җыелма командалары.

«РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Беренче дубль». 8.45 «Алтын ачкыч». 9.00 Документаль фильм: «В старину и сейчас». 9.10 «Беренче нөсхә». 9.25 «Футболга чикләр юк». 10.10 «Хәерле иртә» 10.40 «Аты, баты...» 11.10 «Консолидация». 11.45 «Рус лотосы». 12.00 «Тапшырулар тартмасы». 12.15 Нәфис фильм: «Первая ласточка». 13.30 «Кайнар уңлык». 13.45 «Сезнең партнер». 14.20 «Кисеп бетерә алмаслык...» 14.35 Нәфис фильм: «Неудача Мегрэ». 15.30 К.Мажейка. «Параллели». 15.45 Клип-антракт. 15.55 «Хатирәләрем театры». В.Смехов программасы. 16.25 «Алтынчы сизенү». 16.55 «Формула-1» классында автоузышлар буенча доньмя чемпионаты. Италия Гран-прие. 19.05 Мультфильмнар: «Чокнутый», «Новые приключения Винни Пуха». 20.25 Нәфис фильм: «Мертв по прибытии». 22.15 «Ксюшада кунакта». 22.45 Өлкәннәр өчен мультфильм: «Мы — женщины». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Хатын-кызлар арасында ирекле көрәш буенча доньмя чемпионаты. 0.25 «Фалько Русиядә». Музыкаль программа.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Бу сезнең көнегез». 7.30 «Шифалы сүз». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан-туры элемтә». 10.00 Мультфильм. 10.10 Телефильм: «Удивительная кошка». 10.30 Нәфис фильм: «Лекарство против страха». 12.00 «Якшәмбе лабиринты». 13.10 Документаль фильм: «Гюстав Кайботт» (Франция). 14.15 «Страсти-мордасти». 14.45 «Классика-5». Кайту. С.Рахманинов. 15.30 Депутатларга сүз бирәбез. 16.00 «Алтын ачкыч». 16.15 «Сидоров-шоу». 22.25 «Адәм һәм Хава плюс». 22.55 Өлкәннәр өчен мультфильм. 23.15 ТВ мәгълүматлары. 23.40 Рок риваятьләре. «Кисс».

R

ДҮШӘМБЕ, 4 СЕНТЯБРЬ

6.00, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.00 Информацион-музыкаль программа. 7.45, 20.23 — Тапшырулар программасы. 8.00, 18.30, 20.30 — Радио-1. 17.45 «Язучылар — балаларга». Рушания Низамова хикәяләре. 18.15 «Дүшәмбедән — дүшәмбегә». 19.45 Һәвәскәр башкаручылар концерты.

СИШӘМБЕ, 5 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25 — Тапшырулар программасы. 8.00, 14.30, 18,30 20.45 — Радио-1. 12.25 -14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Башкортстан артистлары концерты. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Юллар чатында» информацион программасы. 13.45 «Турыдан-туры элемтә». Радиопостановка. 17.45 «Яшьлек» студиясе. 18.15 «Көн темаларына». Әңгәмәләр, аңлатмалар. 19.45 Татар композиторларының камера музыкасы.

ЧӘРШӘМБЕ, 6 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Татарстан дулкынында». 6.55, 7.58, 13.20, 20.53 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.53 — Тапшырулар программасы. 8.00, 13.25, 18.30, 21.00 — Радио-1. 12.30 Концерт. «Без Татарстан җирендә яшибез». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Тормыш барометры». 19.45 Сораулар буенча концерт.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 7 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 20.45 — Радио-1. 12.25 14.30 — «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 «Балалар җырлый». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Эфирда әңгәмә». 14.30 «А.Туишева һәм Ш.Әхмәтҗанов җырлый». Татарстан радиосы тапшыруы (Радио-1). 18.05 «Старт». 19.45 Опералардан арияләр.

ҖОМГА, 8 СЕНТЯБРЬ

6.00 «Балкыш». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.00, 13.05, 19.15 — «Соңгы хәбәрләр». 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 20.45 — Радио-1. 12.30 Р.Яхин. Фортепьяно һәм оркестр өчен концерт. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Чишмәләр» (чуваш телендә). 19.45 «Музыкаль Татарстан». Радиокүзәтү.

ШИМБӘ, 9 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 Авыл эшчәннәре өчен концерт. 6.58, 7.58, 14.30 — Һава торышы. 7.15 Концерт. 7.45, 14.30 — Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00, 11.00, 14.35 — Радио-1. 8.15 «Сезнең хатларыгыз». 8.40 «Көмеш кыңгырау». 9.00 «Моңлы бер җыр». Т.Миңнуллин белән очрашу. 9.30 «Драматургия горурлыгы». Т.Гыйззәтнең 100 еллыгы. 10.30 «Сәясәт һәм шәхес». 11.45 «Кардәшлеккә чикләр юк». 12.15 Татар халык көйләре. 13.10 Яңалыклар эстафетасы. 13.30 «Яшьлек» студиясе. 14.00 «Көзге».

ЯКШӘМБЕ, 10 СЕНТЯБРЬ

7.02, 7.58, 13.40 — Һава торышы. 7.04 «Хәерле иртә!» 7.45, 13.40 — Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00 «Идел белән Урал арасында». Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы. 9.00 «Чын күңелдән сөйләшүгә чакырабыз». 9.30 «Мирас». 10.15, 16.00 — Радио-1. 11.45 «Кредо». 12.15 «Бүгенге көндә хөкүмәт эшләре». 12.45 Ял концерты. 13.45 «Татарстан дулкынында». 14.25 Д.Салихов. «Бәйрәмгалинең сыер тышавы». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле.

РУСОФОБИЯ

XX гасыр урыс табышмаклары, мөгаен, кайчандагыга караганда да катлаулырак булырга охшый. Үзегез уйлап карагыз, гасыр башында шарып кына башланган урыс стачкасы урыс коммунизмының триумфаль җиңүе белән тәмамланды. Һәм дөньяның иң башлы философлары башка илләрдә көннәр яки айлар белән генә исәпләнгән коммунизмның Русиядә ныгып кала алуының серен ачу өчен гасыр буе баш ваттылар. Биредә сүз совет штыклары ярдәмендә яшәп килгән урыс коммунизмы турында бармый.

Дөнья сәясәтчеләре урыс табышмагын чишкән арада, XX гасыр азагында тагын бер табышмак пәйда булды. Бусы — какшамас Союзның таркалуы. Ул шулкадәр тиз һәм көтелмәгән булды ки, чит илләрнең күп кенә сәясәтчеләре миңрәп калдылар. Хәзер урыс атом-төш куркынычы чынбарлыкка әверелде. Шуның өчен дә америкалылар Советлар Союзының таркалуына юл куярга теләмәгәннәр иде. Алар хәтта бу таркалуны хәйрия ярдәме яки башка төрле ярдәм күрсәтү рәвешендә туктатырга тырыштылар. Әмма моның инде файдасы булмады: беркем дә, хәтта Тәңре үзе дә туктата алмаслык процесс булды бу. Ә менә Советлар иленең җитәкче катлавы, аларның күңел төшенкелеге кичерүе турында әйтергә була. Союз җитәкчеләре миңрәп кенә калмыйча, беркадәр генетик тайпылышка да дучар булдылар. Сигезенче каттан сикерү яки муенга элмәк кию җиңел эш түгел бит. Моның өчен әйтеп бетергесез зур тетрәнүләр кичерергә кирәк. Мондый коммунистлар гадәти совет халкы төшкән хәерчелек дәрәҗәсенә төшмәс өчен үлеп котылуны хуп күрделәр. Әгәр маршал Ахромеев Союз таркалачагын алданрак күрә алган булса, ул академик Сахаровка каршы әтәчләнгән съездда ук Горбачевны атып үтергән һәм икенче тапкыр Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган булыр иде. Әмма моны беркем дә алдан күрә алмады һәм Горбачевның косметик үзгәртеп коруын Үзәк Комитетның күп кенә Политбюро әгъзалары чираттагы демократия уены буларак кабул иттеләр. 1917 елда урыс революциясен килеп бастыру турында беркем дә җитди уйланмады.

Хәзер Союз яклылар нигездә Ельцинны, Кравчукны, Шушкевичны һәм аларга килеп кушылган Назарбаевны сүгәләр. Мондый хәл ничек килеп чыкты соң? Юкса, СССРның марксистик-ленинчыл нигезен атом-төш коралы белән дә җимереп булмас кебек иде бит. Әгәр аны кемдер бомба ярдәмендә җимерергә уйлаган булса, без барыбыз да советлар власте өчен һәлак булган булыр идек. Ә бу монолит кан коюсыз-нисез бер көн эчендә җимерелде дә төште. Мондый каршылыксыз һәм корбансыз җимерелгән империянең тарихта булганы юк. Союзның җимерелүе турында имза куйган бу кыю президентлар Нобель премиясенә лаек. Ләкин аларны бүләкләргә ашыкмагыз әле, чөнки Союз үзе җимерелде, ә кыюлар бу фактны документлаштырдылар гына. Моның өчен аларны ачуланырга да кирәк түгел, аларның гаебе юк. Хәтта алар, бик теләгән очракта да, бу кадәр зур илне җимерә алмаслар иде.

Шулай да атом-төш коралыннан да куәтлерәк көч каян килеп чыкты соң? Бу көч күптәннән яшәп килде һәм, никадәр генә гаҗәп тоелса да, аның чыганагы русофобия (фобия - - курку) булды. Күз алдына китерегез, СССРның урыс булмаган теләсә кайсы гражданы, кайсы тарафта гына яшәсә дә, азчылык милләт вәкиле, ягъни кече туган булып саналды. Азчылык милләтләр халыкта чучмек, чаплашка, карачутыр, кысык күз һәм башка исемдә йөрделәр. Алар хәтта үз милли республикаларында да азчылык милләт вәкилләре булып хисапланды. Аларның күбесе телен, язуын югалтты, ә инде милли горурлык турында әйтеп тә торасы юк. Милли горурлыксыз, телсез милләт тә юк. Кем әйтмешли, үзләре урыслар, үзләренең күзләре кысык.

Бервакыт телевизордан безнең чукчалар белән Америка чукчаларының очрашуын күрсәттеләр. Америка чукчаларының үз гореф-гадәтләре, исемнәре сакланган һәм алар туган телләрендә сөйләшәләр. Ә СССР чукчалары 70 ел эчендә Иванга һәм Марияга әверелделәр.

Русофобия, яшерен көч буларак, һәр азчылык милләт вәкиленең йөрәгендә сакланды һәм, мөмкинлек туу белән, барлык республикалар да әмерсез-нисез баш калкытты. Хәзер инде алар беркайчан да элекке СССРны торгызу ягында булмаячак. Кайбер милли патриотлар Союзны яңадан торгызу турында сөйләнсәләр дә, бу эшне тормышка ашыру инде мөмкин түгел. Вакланган магнитны кире ябыштырып карагыз әле - - берни дә килеп чыкмас. Чөнки вакланган магнитның һәр кисәгендә олы магнит үзенчәлекләренә ия булган ике полюслы яңа магнит кисәге барлыкка килә.

Русофобия патша вакытында да яшәп килде, әмма ул вакытта төбәкләр совет власте чорындагыга караганда мөстәкыйльрәк яшәде һәм үз өйләрендә милли азчылык булып хисапланмады. Әйе, үз өеңдә милли азчылык вәкиле булу бик рәхәт нәрсә түгел. Хәзер мөстәкыйль дәүләтләрдә калган урыслар үзләре бу нәрсәне җилкәләрендә татыйлар. Бервакыт мин поездда качаклар белән сөйләшеп барган идем. Үзбәкстанда кырык ел яшәгән урыс гаиләсе Русиягә кайтып бара. Әйтүләренә караганда, аларны аннан беркем дә кумаган, ләкин өлкән туган булып яшәргә күнеккән бу кешеләргә хәзер азчылык милләт вәкиле булу ошамый икән. Сүз уңаеннан шуны да әйтим, ярты гасырга якын үзбәк илендә яшәгән бу гаилә бер генә үзбәк сүзен дә өйрәнмәгән.

Җир шарының алтыдан бер өлешен уңдырышсыз туфракка әйләндергән, халыкларны рухи яктан гарипләндергән урыс коммунизмы Җир шарының барлык кыйтгаларын куркытып тотты. Тора-бара үзләрен туймас илбасарлар итеп таныткан урыслардан һәркайда курка башладылар. Шундый курку-өркү нәтиҗәсендә туган русофобия СССРны таркатуда төп рольне уйнады да.

Монда мин ике генә табышмакка җавап табарга тырыштым, әмма өченчесе дә бар бит әле. Анысын инде анализлыйсы килми. Шулай да бу табышмак турында берничә сүз әйтеп үтәргә кирәктер. Ни өчен без - - урыслар (гәрчә, урыс булмасам да, чит илдә мине барыбер урыс дип атыйлар) табигый ресурсларга чиксез бай булган шушы илдә кешечә яши алмыйбыз, көнкүреш дәрәҗәсе буенча дөньяда егерменче урынга гына булса да күтәрелә алмыйбыз. Бу табышмакка җавап табу өчен мин Русия парламентына, сынап карау өчен генә Курил утрауларының берәрсен японнарга биреп карарга (20 елдан соң түгел, хәзер -- без исән чакта нәтиҗәсен күрер өчен), һәм анда бернинди шарт куймыйча иң ярлы японнарны урнаштырырга тәкъдим итәр идем. Иманым камил, безнең мазутка буялып беткән бу ташлы утрау биш-алты елдан оҗмахка әвереләчәк.



Локман ЗАКИР.

Мөнәсәбәт

Мәскәү Кремлендә мәчет булырмы?

Күптән түгел матбугатта: Свияжскидагы чиркәүләрне эшләтә башлаячаклар, дигән бер хәбәр күренеп алган иде. Моңа каршы Татар иҗтимагый үзәге, бу бит «татар халкын колонияләштерү һәйкәлләрен яңарту», дип язып чыкты. Кремльдәге чиркәүне — Благовещен соборын - - дин тотучыларга тапшыру нияте дә халыкның ачуын кабартты. Татар иҗтимагый үзәге исә моны «милли хисләрне мыскыллау һәм мәсхәрәләү» дип бәяләде, чөнки бу чиркәү безнең борынгы бабаларыбыз сөякләре өстенә кабер ташларыннан салынган нигездә тора. Кремльнең бавырында урнашкан шушы чиркәүгә православиелеләр, чыннан да, гыйбадәт кылырга, чукынырга йөри башласа, нәрсә була инде бу?.. Әгәр дә әлеге хәл дөреслеккә туры килсә, бу кара гамәл Татарстанда моңарчы дус-тату яшәгән халыклар арасын болгату булмасмы? Әнә шундый борчулы сорау белән мин иң беренче нәүбәттә Татарстан Архитекторлар берлеге рәисе, республика иҗат берлекләре һәм җәмгыятьләренең координация шурасы рәисе Фәридә Мөхәммәт кызы ЗӘБИРОВАга мөрәҗәгать иттем. Ул миңа түбәндәгеләрне сөйләде:

— Мәгълүм булганча, «Казан. Кремль» дигән тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлык осштырылган иде. 1994 елда Министрлар Кабинеты тарафыннан «Казан Кремле комплексын өйрәнү, саклау һәм яңарту концепциясенең төп юнәлешләре» расланды. Аның нигезендә Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләрен тигезләү максаты ята. Икенче төрле әйткәндә, Кремль эчендәге татар ханнары чорыннан казып табылган археологик байлыкны барлау һәм консервацияләү, яңа мәчет, хан сарае, мавзолейлар салу күздә тотыла. Элек бит анда биш мәчет булган. Хәзер кызу темплар белән археологик казыну эшләре алып барыла. Кызыклы гына экспонатлар да табылды.

Салына торган яңа мәчеттә мөселманнар Ураза, Корбан гаете бәйрәмнәрен, урыслар Благовещен соборында Пасха, Рождество кебек зур бәйрәмнәрен үткәрәчәк.

Благовещен соборы сәнгать музееның иконография бүлеге буларак та файдаланылачак. Аның бинасы тыюлык карамагына бирелде. Бу бинадагы Татарстан Республикасы архивы башка урынга күчерелә, сәнгать музее аны арендага алып торачак.

Әлеге чиркәүне файдалануны Кремльдәге башка биналарны файдалану контекстыннан аерып карарга ярамый.

Кремль туфрагында алып барыла торган эшләрне Президент М.Шәймиев үзе күзәтүдә тота, һәм ул вакыты-вакыты белән бездән авторлар коллективы эшчәнлеге турында хисап таләп итә. Ике төрле мәдәният һәм конфессиянең бергә үрелеп баруы Татарстандагы сәяси тотрыклылыкны саклап калырга мөмкинлек бирәчәк.

Аннары шуны да әйтергә кирәк: Кремльне реставрацияләү концепциясе Президент фәрманы белән татар һәм урыс телләрендә матбугат битләрендә басылып чыкты. Аны тикшергәндә берәү дә, нишләп алай итәсез, дип әйтмәде дә, язып та чыкмады...

Әйдәгез, тагын кем нәрсә дип җавап бирер икән бу сорауга?

Сания ИБРАҺИМОВА.

Сәфәребез дәвамлы булсын

Мөхтәрәм җәмәгать, сез бүген «Мәдәни җомга»ның җиденче санын кулыгызга алдыгыз.

Безнең халыкта «7» изге саннардан исәпләнә. Димәк, без әһле исламның гомер тәҗрибәсендә билгеләнгән илаһи чикләрнең берсен үтеп барабыз. Башлаган сәфәребез, иншалла, дәвамлы булыр.

Бу җәһәттән шунысын да хәбәр итәбез: атналык газетаның 7 нче саны чыгар алдыннан Казандагы Матбугат йортына редакциябезнең шушы бинада урнашуын белдергән игълан-вывеска да беркетелде. Басмабызның гомере озын булсын, йорт диварындагы «таныклык»ларны кабат-кабат алыштырырга язмасын.



Кышка кергәч бетәр ул!

Быел җиләк-җимеш егылып уңса да, базарда бәяләр төшәргә уйламый. Бигрәк тә алманыкы ныклы. Димәк, базарда алма аз.

Ә менә Балык Бистәсенең «Масловка» хуҗалыгы шактый арзан бәягә алма сата. Тик бу турыда халык белми. Башка төрле җиләк-җимеш банкаларга кереп оялады инде, ә алма сәүдәгәрләрне дә, сәүдәгәр булмаганнарны да көтә әле.

Кышка кергәч, «Масловка»да да бетәр ул алмалар, алырга ашыгыгыз!

Кыз йолдызлыгы астында туганнар

КОТЛЫЙБЫЗ!

1 сентябрь

Перьнов Григорий Михайлович -- В.Качалов исемендәге Рус зур драма театры директоры, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

3 сентябрь

Әхмәдова Людмила Исхаковна — Казан дәүләт консерваториясенең өлкән укытучысы.

Лимонова Инна Валерьевна — шагыйрә.

Низамов Илдар Малик улы — язучы-публицист, Казан дәүләт университеты доценты.

4 сентябрь

Блинов Лоренс Иванович -- композитор.

Петров Анатолий Михайлович — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының балет солисты.

Сафин Ибраһим Абзал улы -- Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге физика-техника институты баш фәнни хезмәткәре, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы.

5 сентябрь

Зиятдинова Фирая Гали кызы -- шагыйрә.

Зөбәеров Диләвер Мирзаабдулла улы -- Казан медицина университетының кафедра мөдире, «Казанский медицинский журнал»ының баш мөхәррире, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе.

6 сентябрь

Гыйззәтуллина Флера Сабирҗан кызы -- шагыйрә.

Кузнецова Валентина Михайловна -- В.Качалов исемендәге Рус зур драма театры актеры.

Фәтхетдинов Зөфәр Мәгъсум улы -- язучы, юрист, профессор.

7 сентябрь

Заһидуллина Әлфия Гафият кызы -- Татарстан дәүләт филармониясе солисты, Татарстанның халык артисты.

Харисова (Муллина) Рәзилә Мирхәт кызы — Минзәлә Татар дәүләт драма театры артисты.

Ульбашев Петр Александрович — Минзәлә Татар дәүләт драма театры директоры урынбасары, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Ачыктан-ачык

Гимен кемгә кирәк — кызларгамы, егетләргәме?

Гимен — грек теленнән килеп кергән сүз. Ул кызлык пәрдәсе дигән мәгънәне аңлата. «Гимен — кызлык пәрдәсе, — диелә Зур Совет Энциклопедиясендә, -- ул — аналыкны каплаган элпә. Беренче җенси якынлыктан канап ертыла». Мәгълүм булганча, бу пәрдә кыз-кыркылганча, бу пәрдә кыз-кыркыга гомерлек шатлык та, хәсрәт тә алып килергә мөмкин. Кызлык пәрдәсен югалтудан хурланып үз-үзенә кул салган кызлар азмыни? Бер карашка, монда әллә ни зур фаҗига да юк кебек. Әмма борынгыдан килгән әхлак кануннары белән исәпләшкән очракта, бу чыннан да искиткеч зур фаҗига булып чыга инде. Ә менә Һиндстанның һәм Көньяк Американың кайбер төбәкләрендә әби-карчыклар кызларның бу пәрдәсен кече яшьтән үк «юып» чыгаралар.

Соңгы елларда байтак илләрдә куәтле сексуаль инкыйлаб башланды. БДБ илләрендә, мәсәлән, мәктәптә укучы кызларның 80-90 проценты җенси якынлык белән яшь икән һәм бер генә 5 нче сыйныф укучысы да җенси якынлыкны бозыклык дип санамый. Кайбер имеш-мимешләргә караганда, хәтта бездәге кайбер шәһәр җирләрендәге чүплекләрдә маугличлар -- адәмчә сөйләшә алмый, этләр белән бергә дүрт аяклап чабып йөри торган балалар табыла икән. Билгеле, болар барысы да кызлык намусы һәм хатын-кызның әхлак сафлыгы какшавыннан килеп чыга, дип уйларга кирәк.

Әүвәл заманнарда бездә, татарларда, зөфаф кичендә егет белән кыз йоклаган җәймәне коймага чыгарып элә торган булганнар. Әмма совет власте елларында бу «искелек калдыгы» тамырыннан корыды. Чыннан да шундый «искелекләр» белән гигант социалистик төзелешләрне башкарып чыгып булачак мыни? Ул чорда хатын-кызның җенси эмансипациясе шул дәрәҗәгә җитте ки, күпләрнең «табигать хатасы» -- кызлык намусын югалтулары исе дә китми башлады.

Соңгы елларда АКШта һәм Аурупа илләрендә хатын-кызның җенси азатлыгына чик куюга омтылыш сизелә. Бу илләрдә гимен реставраторлары дип исемләнгән табиблар бар. Алар берничә минут эчендә хәтта иң азау фахишәдән дә «кыз» ясый алалар. 1960 елда бары тик Аурупада гына да 35 мең хатын-кызга «кызлык пәрдәсе» куелган икән. Бу җенси азатлыкның бетүгә табан баруын һәм гөнаһлы хатыннарның «намуслы кыз» булып кияүгә чыгарга теләүләрен күрсәтә.

Русия Көнбатыштан якынча 20-30 ел артка калганга күрә, мондый «кызлар» бездә дә ишәер сыман. Бездә дә мондый белгечләр барлыкка килә калган очракта, мәктәпләрдә белем алучы Казан кызлары да озак җенси бозыклыклардан соң кызлыкларын кайтарырга дип гимен реставраторларына чират тора башламаслармы? Хәер, тора башладылар да бугай инде...

Тәфкил ЗАКИРОВ.

Криптограмма

«ИЛҺАМИЯТ»



Барлык сорауларга да дөрес җавап тапсагыз, Илһам Шакиров тарафыннан бик тә яратып башкарыла торган бер җырның исемен укый алырсыз.

1. Татарстаннан читтә татарлар тупланып яши торган төбәк. 2. Илһамның әтисе. 3. Татар халык язучысы. 4. Татар халык шагыйре. 5. Илһамның әнисе. 6. Композитор Р.Яхин әсәре. 7. Сарман районындагы авыл. 8. Җырчы, музыкант иҗаты өчен иң зур таләпләрнең берсе. 9. Татар халык җыры. 10. Танылган сүз остасы. 11. Сәнгать учагы. 12. Танылган җырчы. 13. Халык җыры. 14. Илһам Шакировның беренче гастроле узган шәһәр. 15. Моң чишмәсе. 16. Илһамның остазларыннан берсе. 17. Танылган баянчы. 18. Татарстандагы иң озын елга. 19. Танылган баянчы. 20. Илһам Шакиров иҗат иткән көй. 21. Халык җыры.

Җәүдәт ХӨСӘЕНОВ төзеде.
Казан.

Бу санда Эрот Зарипов, Нәҗип Нәккаш, Ринат Хәсәншин, Айдар Үтәгәнов рәсемнәре, Әсрар Шакирҗанов (1 нче бит), Наил Курамшин, Азат Ахунов, Василий Абросимов, Әкрәм Шәфигуллин төшергән һәм авторларның шәхси архивыннан алынган фотолар файдаланылды.

МӘДӘНИ ҖОМГА

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәррир урынбасарлары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары;
32-62-79 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге;
32-58-91, 32-68-22 — әдәбият бүлеге;
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге;
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге;
32-59-55 — халык тормышы, рухиятне яклау;
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-66-28, 32-59-22 — рәссамнар;
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакци[...] фикере белән муафыйк бул[...]маска да мөмкин

Хатлар, кульязмалар, фото[...]графияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кир[...] кайтарылмый

Газетада басылган язмалар[...]ны, фотографияләрне файда[...]ланганда, шулай ук өземтәләр китергәндә, «Мәдән[...] җомга»дан алынганлыгын кү[...]рсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен за[...]казлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүләрне[...] төгәллеге өчен реклама бирү[...]челәр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме кү[...]рсәтергә теләүчеләр өчен ре[...]дакциянең исәп-хисап счеты[...] 609403 МФО 265566 в Бауманском отд. ПСБ

Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 428 нче таныклык белән теркәлде

Индекс — 54129

Редакция адресы: 420503, Казан, Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән җ[...]бәрелгән сыйфат җитешсезл[...]кләре унаеннан 49-36-62 ном[...]рлы телефон буенча шалтыр[...]тырга

Газета редакциянең компь[...]тер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4455